Самарские татары

Самар татарлары

ЕЖЕКВАРТАЛЬНЫЙ ЖУРНАЛ О ЖИЗНИ САМАРСКИХ ТАТАР

№ 1 (38), ЯНВАРЬ–МАРТ, 2023

ВЫПУСКАЕТСЯ С 2012 ГОДА



ТАТАРЛАР НИШЛӘП КИМЕГӘН?



И ЖИЗНЬ ПРОЖИТЬ, И ПОЛЕ ПЕРЕЙТИ



ЯТИМНӘРНЕ КЕШЕ ИТЕП ЧЫГАРДЫЛАР



ПЕРВЫЙ ДОКТОР ФИЛОЛОГИЧЕСКИХ НАУК ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ



*Альбина Мәхмүтова*

# Милли хәрәкәт күгендә якты йолдыз булып янды ул!

6+

# ВАША РЕКЛАМА
# В ТАТАРСКИХ СМИ РЕГИОНА

По вопросам размещения обращаться по телефону 8-917-104-44-45

информационный медиапортал

Самарские татары
Самар татарлары

samtatnews.ru

Самарские татарские новости

Ждем ваших предложений по созданию самарского татарского интернет-телевидения.



**ЕЖЕКВАРТАЛЬНЫЙ ЖУРНАЛ О ЖИЗНИ САМАРСКИХ ТАТАР**

**ПРИОБРЕСТИ НОМЕРА ЖУРНАЛА «САМАР ТАТАРЛАРЫ» МОЖНО ПО СЛЕДУЮЩИМ АДРЕСАМ:**
Самара, ул. Революционная, д. 142
(магазин «Кулинария на Революционной»),
пр. Кирова, 206 (бывшее здание «ИПОЗЕМбанк»),
в Соборной мечети Самары.

Телефон для связи 8-917-104-44-45 **Сайфиев Данияр Ирекович**
Адреса электронной почты – **Samartatarlary@bk.ru, ilyas65@mail.ru**



Самара өлкәсе татарларының иҗтимагый-сәяси газетасына — 33 яшь!

Заманалар үзгәрә – Бердәмлек газетасы кала

- 33 ел буе газета өйләрегезгә котлаулар, мәкаләләр, очерклар, яңалыклар китереп тора
- "Бердәмлек"геройлары – сез үзегез, күршеләрегез һәм якташларыгыз!
- "Бердәмлек"не язучылар – сез үзегез, күршеләрегез һәм якташларыгыз!
- "Бердәмлек"– Самара татарлары арасында иң популяр газета!
- "Бердәмлек"кә ел әйләнәсендә почта бүлекләре, "Россия почтасы" сайтындагы онлайн-язылу һәм "Урал-пресс Поволжья" җәмгыяте аша язылырга була

Индексы П4778




**ЕЖЕГОДНЫЙ ТАТАРСКИЙ КАЛЕНДАРЬ**

рассказывает о значимых исторических датах в жизни татар Самары и России

# Хөрмәтле дуслар!

Сезнең кулыгызда “Самар татарлары” журналының быелгы беренче саны.

Басма чыгып килгән ун ел дәвамында без язгы саннарыбызда бары тик позитив мәкаләләр генә урнаштырырга тырышабыз. Әлбәттә инде, аларның күбесе гүзәл хатын-кызларыбызга багышланган була. Әлеге санга да лаеклы һәм хөрмәтле туташ-ханымнар турында күп язмалар әзерләдек. Әмма барыбер журналыбыз андый ук позитив булып чыкмады. Хәзер вакыты шундый бит... Күңелле чак түгел шул.

Журнал тышлыгында Альбина Мәхмүтованың зур һәм матур фотосурәте урнаштырылды. Арабыздан вакытсыз китеп барган Фәрхәт һәм Альбина Мәхмүтовларны искә алу йөзеннән бу. Кыска гомер кичерсәләр дә, алар татар милләте өчен бихисап эшләр башкарып калдырдылар. Мәхмүтовлар акча өчен дә, дан казаныр өчен дә эшләмәделәр, татар халкы үз телен, гореф-гадәтләрен белсен, үз тамырларын югалтмасын дип тырыштылар.

Кызганыч ки, андый кешеләр хәзер күп түгел. Гәрчә, соңгы җанисәп алу нәтиҗәләренә карасаң, татарларның саны да азая бара. Илебездә аларның саны 600 меңгә, ә Самар өлкәсендә 30 меңгә кимегән. Нигә алай килеп чыга соң? Бу сорауга җавапны бу сандагы мәкаләне укып белерсез.

Әлеге теманы дәвам итеп, татар телен, милләтебезне саклап калырга кирәклеге турында тагын берничә язма урнаштырдык. Бу – безнең даими темабыз. Хөрмәтле укучыларыбыз да шушы проблемаларга битараф калмасыннар иде.

Безнең белән бергә булыгыз! Илләребезгә тынычлык, барчабызга да иминлек теләп калам.



**Данияр СӘЙФИЕВ,**
*“Самар татарлары” журналы мөхәррире*

# Дорогие друзья!

В ваших руках – первый в этом году номер журнала «Самар татарлары». На протяжении десяти лет, что выходит издание, весенние номера мы старались наполнять позитивными публикациями, большая часть из которых, конечно же, была посвящена замечательным женщинам. В этот номер мы тоже подготовили немало статей о наших заслуженных и уважаемых землячках. Но сам журнал получился, к сожалению, не радостным. Время, видимо, сейчас такое. Не радостное.

На обложке размещена большая и красивая фотография Альбины Махмутовой. Это – дань нашей памяти и безмерной благодарности безвременно ушедшим от нас Альбине и Фархату. Много ли среди нас людей, успевших так много за свою недолгую жизнь сделать для татарского народа? Махмутовы работали не ради денег, не ради славы, а только для того, чтобы те, кто называет себя татарами, знали свои язык и культуру, не забывали свои корни. Увы, таких людей среди нас почти не остается. Что уж говорить, и самих татар, если верить данным последней переписи населения, катастрофически становится меньше. В стране – почти на 600 тысяч человек, в Самарской области – почти на 30 тысяч. Почему так произошло – ответ на этот вопрос вы найдете на страницах этого номера. В продолжение темы мы опубликовали серию материалов, общий посыл которых направлен на необходимость сохранения татар как нации. Эта тема для нас постоянная. Хотелось бы, чтобы и наши читатели не оставались к этому вопросу равнодушными.

Будьте с нами! Добра нам всем и скорейшего наступления мира!


РЕДАКЦИОННЫЙ СОВЕТ

**Шакуров Ильяс Гумерович** – президент СОТО «Туган тел»; председатель правления НКО «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области», член Общественной палаты г.о. Самара

**Хазиев Артур Ахатович** – председатель Центра Стратегических Исследований «Платформа XXI»

**Сайфиев Данияр Трекович** – гл. редактор журнала «Самар татарлары» («Самарские татары»)

**Нуретдинова Римма Равильевна** – главный редактор сайта samtatnews.ru

**Ваккасов Расих Ахметшамилович** имам-хатыб мечети «Булгарское наследие»

**Ибятова Ляйсян Замиловна** – член Совета СОТО «Туган тел»

**Надиров Азат Камилович** – член Совета СОТО «Туган тел»

**Сафин Иршат Халилович** – старший имам-хатыб Соборной мечети г. Самары

**Хузин Ривгат Туктарович** – председатель комиссии Общественного совета при ГУ МВД России по Самарской области

**Мифтахов Искандер Фуадович** – член Совета СОТО «Туган тел»

**Рамазанова Гюзяль Ибрагимовна** – директор СОТО «Туган тел»

**Юсупов Рамиль Закряриевич** – член Совета СОТО «Туган тел»

**Юсупов Фагим Ханифович** – член Совета СОТО «Туган тел»

РЕДАКЦИОННАЯ КОЛЛЕГИЯ

**Биктаев Наиль Данисович**
**Варфоломеева Эльмира Мугаммаровна**
**Галимов Шамиль Хайдарович**
**Мифтахов Искандер Фуадович**
**Файзуллов Рустам Ильясович**
**Салахова Лилия Акрямовна**
**Ширияздaнов Фарид Хамитович**
**Шарипов Руслан Кабирович**

# Содержание:


Татарлар нишләп кимегән? ..... 5
Иң матур чәчәгебез сула түгелме? ..... 7
Татарлар – үз заманында бөтен төрки халыкларга үрнәк булып яшәгән халык ..... 9
Сохраним вместе духовное богатство народа! ..... 21
Борынгы болгарлар – дөнья күләмендә мәгърифәтле булып танылган халык ..... 25
Алар герой булып киттеләр ..... 29
Война народная ..... 31
Россия – родина сионизма ..... 35
И жизнь прожить, и поле перейти ..... 43
Первый доктор филологических наук по татарскому языку ..... 51
Милли хәрәкәт күгендә якты йолдыз булып янды ул! ..... 62
Ятимнәрне кеше итеп чыгардылар ..... 67
Алар тормышында милләтебезнең асылы ачык күренә ..... 70
Сыйныфташлар – гомерлек дуслар ..... 79
Алар - яңа, бәхетле тормышка нигез салучы патриот-педагоглар ..... 83
“Күрәселәрне күрдем инде” ..... 86
Күңеле тулы нур, йөрәге тулы мәрхәмәт ..... 88
“Хатыным белән бүлешеп түгел, бер-беребезгә булышып гомер иттек” 91
“Балаларны иманлы, инсафлы итеп тәрбияләүдә Ислам диненең әһәмияте искиткеч зур” ..... 94
Ихтыяр көче һәм тырышлык – уңыш нигезе ..... 98
Татарларның табын әдәбе ..... 100
Дамир Йосыпов: «Хыялыма тугры булдым» ..... 103
Путешествие одного этнического названия ..... 105
Вкусная кухня ..... 108
Заяц в традиционной культуре ..... 112





13 АЙГӨЛ ӘХМӘТГАЛИЕВА: «ТУГАН ТЕЛ – ӘМАНӘТ УЛ»





23 «СЕРЕБРЯНЫЕ БУЛГАРЫ» И ХАН КОТРАГ





37 НӘРСӘ УЛ - ТОРМЫШ? НӘРСӘ УЛ - ЯШӘҮ?






73 ЕГО ДЖАЛИЛЬ БЛАГОСЛОВИЛ


## Уважаемые друзья!

***Приобрести журнал «Самар татарлары» можно по следующим адресам:***

- **Самара, ул. Революционная, д. 142 (магазин «Кулинария на Революционной»)**
- **Самара, пр. Кирова, 206 (бывшее здание «ИПОЗЕМбанк»),**
- **Самара, ул. Стара Загора, 54 (в магазине внутри Соборной мечети).**

**Стоимость текущего номера с доставкой – 300 рублей, стоимость номеров за 2021 год – 300 рублей, все предыдущие номера – по 700 рублей.**

**Доставка журналов по Самаре – тел.: 8-937-64-044-77.**


Издатель «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области», адрес: 443087, Самарская область, г. Самара, пр. Кирова, 206, оф. 28

**Главный редактор:** САЙФИЕВ Данияр Ирекович
**Корреспонденты:** Миляуша ГАЗИМОВА, Фарид ШИРИЯЗДАНОВ, Шамиль ГАЛИМОВ, Рашид ШАКИРОВ, Нурсина ХАКИМОВА
**Дизайн-макет, верстка:** Александр ГОРБАЧЕВ, Юрий ШВЕЦ
**Фото:** Миляуша ГАЗИМОВА, Аняс МИНГАЛЕЕВ
**Корректоры:** Миляуша ГАЗИМОВА, Вадим ОЛЕНИН

**Адрес редакции:**
443087, Самарская область, г. Самара, пр. Кирова, 206, оф. 28
**Телефон редакции:** 8-917-104-44-45
**Электронная почта:** samartatarlary@bk.ru
**www.samtatnews.ru**

**Отпечатано в ООО «СЛОВО»,**
443070, Самарская область, г. Самара, ул. Песчаная, 1, офис 310, тел. (846) 267-36-82

**Журнал «Самар татарлары»** («Самарские татары»), № 1 (38), январь–март, 2023 г.
**Учредитель:** «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области»
Журнал зарегистрирован Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций по Самарской области. Свидетельство о регистрации СМИ: ПИ №ТУ63 – 00628 от 15.10.2013 г.
Дата выхода 28 марта 2023 г.
Тираж 1250 экз. Цена свободная



# ПОМОЩЬ ОТ САМАРСКИХ МУСУЛЬМАН

Председатель Регионального духовного управления мусульман Самарской области, муфтий Талип хазрат Яруллин, и имам Самарской исторической мечети Наиль хазрат Биктаев посетили Генеральное консульство Турецкой Республики в Казани.

На встрече с Генеральным консулом Исметом Эриканом представители самарского мусульманского духовенства выразили слова сочувствия и поддержки турецкому народу в связи с постигшим республику стихийным бедствием и передали документы, подтверждающие перевод 1 миллиона рублей в пользу пострадавших от землетрясения.

15 февраля Централизованная религиозная организация «Региональное духовное управление мусульман Самарской области в составе Центрального духовного управления мусульман России» объявила сбор гуманитарной помощи народам Сирии и Турции, пострадавшим от землетрясения. На просьбу откликнулись мечети Самарской области, предприятия и организации, а также неравнодушные жители региона. Всего на расчетный счет поступил 1 миллион 360 тысяч рублей. Также были собраны одежда, продуктовые наборы и предметы первой необходимости для пострадавших.

Напомним, что в ночь на 6 февраля в Турции произошло землетрясение магнитудой 7,7, которое привело к серьезным разрушениям и жертвам как в самой Турции, так и соседней Сирии.

# XIII ВСЕРОССИЙСКИЙ СЕЛЬСКИЙ САБАНТУЙ ПРОЙДЕТ В АСТРАХАНСКОЙ ОБЛАСТИ

В Астрахани прошло заседание организационного комитета по подготовке и проведению в Астраханской области XIII Всероссийского сельского Сабантуя.

*tatar-congress.org*



В заседании оргкомитета приняли участие заместитель премьер-министра Республики Татарстан, председатель Национального Совета Всемирного конгресса татар Василь Шайхразиев, губернатор Астраханской области Игорь Бабушкин, представители министерств, руководство города и др. Вместе с проведением Сабантуя планируется реализация проекта «Этнодеревня», который предполагает проведение этномероприятий на различных площадках. В регионе уже дважды – в 2008 и в 2017 годах – проводили Федеральный Сабантуй. В этом году он состоится 27 мая и станет стартовым мероприятием, презентующим этнодеревню как одну из локаций этнотуристического маршрута в регионе.

# ПОСВЯЩЕНА ИСТОРИЧЕСКОЙ МЕЧЕТИ

Увидела свет книга «Самарская Историческая мечеть: из века в век (1891–2022 гг.), написанная известным самарским журналистом, историком и краеведом Шамилем Галимовым. Заказчиком данной работы выступило Региональное духовное управления мусульман Самарской области при финансовой поддержке регионального правительства.




Как уже видно из названия, книга посвящена старейшей самарской мечети, носящее имя Исторической, и приурочена к ее открытию после масштабной реконструкции. Кроме центральной заявленной темы, в ней рассматриваются также основные вопросы истории Самарского края, татарской мусульманской общины города Самары и государственно-исламских отношений дореволюционного, советского и постсоветского периодов.

Книга адресована широкому кругу читателей, а то, что она вышла тиражом всего 500 экземпляров, уже с момента издания относит ее к разряду библиографических редкостей.

# ФИЛЬМ «ИБН ФАДЛАН» ВЫШЕЛ В ШИРОКИЙ ПРОКАТ

2 марта в широкий прокат вышел документально-художественный фильм «Ибн Фадлан», снятый Издательским домом «Хузур» Духовного управления мусульман Татарстана к 1100-летию принятия ислама в Волжской Булгарии. Кинокартина получила прокатное удостоверение в Министерстве культуры РФ.

*tatar-congress.org*

В основу фильма «Ибн Фадлан» легли путевые заметки арабского дипломата Ахмеда ибн Фадлана. Его путешествие в составе Багдадского посольства было связано с принятием ислама Волжской Булгарией в 922 году в качестве официальной религии. В картине чередуется документальное и художественно-постановочное повествование. В документальной части представлены интервью и комментарии экспертов. Консультантами фильма выступили директор Государственного Эрмитажа Михаил Пиотровский, директор Института востоковедения РАН Аликбер Аликберов, директор Института истории им. Ш. Марджани Радик Салихов, старший научный сотрудник Института истории материальной культуры РАН Вячеслав Кулешов и другие.

## «ТАТАР-КЫЗЫ – ДЕТИ» В ТОЛЬЯТТИ



18 февраля в Тольятти прошел ежегодный конкурс «Татар-Кызы – дети». Конкурс красоты и таланта нацелен на возрождение и развитие традиций, обычаев и языка татарского народа, сохранение богатого культурного наследия, а также воспитание чувства любви к традициям и обычаям родного края. В этом году в конкурсе талантов подрастающего поколения принятие участие 12 девочек и двое юношей. Всем им предстояло выдержать целый ряд испытаний – сначала содержательно и креативно представить себя на родном языке жюри и гостям, а потом – угостить собравшихся любимым татарским блюдом собственного приготовления. Далее следовал творческий конкурс: дети пели песни на родном языке, исполняли народные танцы, соревновались в акробатических номерах. Обязательной частью программы стало умение с достоинством представить татарский национальный костюм. А завершило соревнования финальное дефиле в светском образе.

«Мисс Татарочкой – 2023» жюри была выбрана Алия Ильясова (11 лет), I вице-мисс – Азалия Насырова (9 лет) и II вице-мисс – Амина Бесаева (8 лет). Все участницы и участники конкурса получили памятные дипломы и ценные подарки от Городской национально-культурной автономии татар г. Тольятти.



## ЗАРЯД ЭНЕРГИИ ОТ «БОЗ ОЗАТУ»

*Samddn.ru*

5 марта на лыжной базе «Чайка» прошел татарский национальный зимний праздник «Боз озату» («День здоровья»). Гости и его участники смогли принять участие в лыжных гонках, биатлоне, спортивных эстафетах, армрестлинге и многочисленных зимних забавах. Все желающие смогли отведать блюда татарской национальной кухни.

Праздник проводится в Самаре с 2013 года. Его организаторами традиционно выступили татарская школа «Яктылык» и Самарская региональная творческая общественная организация «Дуслык».

## МЕЖДУНАРОДНЫЙ ФЕСТИВАЛЬ «МИРАС» ПРОЙДЕТ В САМАРЕ

С 28 по 30 апреля 2023 года в Самаре пройдет IV Международный фестиваль – конкурс татарской культуры «Мирас» («Наследие»), приуроченный к Году педагога и наставника.




Традиционно в нем примут учащиеся образовательных организаций Самарской области, регионов России и стран зарубежья. Организаторами фестиваля являются Самарская областная татарская национально-культурная автономия, СОТО «Туган Тел». Самарская региональная творческая общественная организация «Дуслык» («Дружба»), Татарская национально-культурная автономия г. Самары, Культурно-исторический фонд «Булгарское наследие». Фестиваль проводится при поддержке Министерства культуры Российской Федерации, Администрации городского округа Самара, Министерства культуры Самарской области, Министерства образования и науки Самарской области, Департамента образования Администрации городского округа Самара, Министерства культуры РТ, Всемирного конгресса татар и Государственного бюджетного учреждения Самарской области Дома дружбы народов. Конкурсные выступления и церемония награждения состоятся 28–30 апреля 2023 года в ДК «Чайка» по адресу: г. Самара, пос. Управленческий, ул. Сергея Лазо, 21.



## ПРАЗДНИК ТАТАРСКОЙ КУЛЬТУРЫ

*Samddn.ru*

Городская национально-культурная автономия татар г. о. Тольятти при поддержке Дома дружбы народов Самарской области провела традиционное весеннее мероприятие «Кичке уен» («Вечерка»). В концерте приняли участие артисты ансамбля татарской песни «Идель» – солисты детского и взрослого состава хора ансамбля, музыканты и танцоры. Целью таких творческих вечеров является поддержка талантливых детей и молодежи, развитие их творческого потенциала, исполнительского мастерства и сценической культуры. Маленькие и взрослые артисты постарались донести до аудитории всю красоту родной культуры




# Татарлар нишләп кимегән?

***Халык санын исәпкә алу нәтиҗәләре уйланырга мәҗбүр итә.***

***2020 елгы Бөтенроссия халык санын исәпкә алуның төп этабы 2021 елның 15 октябреннән 14 ноябренә кадәр үтте. Башта ул 2020 елның октябрендә булырга тиеш иде, ләкин коронавирус пандемиясе аркасында аны - 2021 елның апреленә, аннары - сентябрьгә, соңрак октябрьгә күчерделәр. Ә якынча нәтиҗәләре 2022 елның апрелендә билгеле булды, төгәл мәгълүматлар гыйнварда басылып чыкты.***

***Эльмира СӘЙФУЛЛИНА***

Соңгы җанисәп нәтиҗәләре буенча ун ел элек тупланган күрсәткечләрнең нык үзгәрүе күренә. 2010 елда беренче урында - руслар, икенче урында - татарлар, өченче урында украиннар булса, соңгы мәгълүматларга караганда, рус һәм татарлардан соң өченче урынны чеченнар били. Аларның саны 200 мең кешегә арткан. Ә менә татарлар, икенче урынны саклап калсалар да, 597 000 кешегә кимегәннәр.




2020 елгы җанисәп нәтиҗәләре буенча, илдә 4 713 669 татар яши. Шулай ук татар телен белүчеләр саны да кимегән - 3 261 155 кеше генә. 2010 елда бу күрсәткеч 4 280 718 булган, ягъни татар телен белүчеләр саны, 10 ел элек китерелгән мәгълүматлар белән чагыштырганда, бер миллион кешегә кимегән.

Әйе, бик күңелсез картина.

Самар өлкәсендә дә хәлләр мөшкел. Губернада, яңа мәгълүматлар буенча, 94 мең кеше генә үзен татар дип яздырган. Кызганычка, татарлар саны башка өлкәләрдә дә шактый кимегән. Мондый хәл килеп чыгуның төрле сәбәпләрен атыйлар. Җанисәпкә җитди карамаучылар саны шактый - коронавирус аяк чалган, техник җайланмалар начар эшләгән, бөтен мәгълүматларны да исәпкә алмаганнар, дип акланабыз.

Халык санын алу нәтиҗәләре иҗтимагый оешмалар, хакимият башлыклары, тел белгечләре, этнологлар һәм гади халык арасында бик кискен рәвештә фикер алышуларга китерде. Кампанияне оештыручылар аларның мәгълүматларына ышанырга кирәк, ә этнологлар төбәк хакимиятләре үзләренә сораулар бирергә тиеш, дип ышандыралар.

«Әгәр чеченнар чечен булырга, ә руслар рус булырга оялмый икән, нигә башка милләтләрдә бу проблема бар? Бәлки, нәрсәдер тиешенчә эшләнмәгәндер», - дип фикер йөртә Миклухо-Маклай исемендәге этнология һәм антропология институты директоры Дмитрий Функ. Дәүләт

Думасының Милләтләр эшләре буенча комитет утырышында Татарстаннан депутат Илдар Гыйльметдинов пандемиягә зарланды, ә комитет башлыгы Геннадий Семигин SOS кычкырырга һәм милли тиңдәшлеген билгели алмаган яшьләр белән эшләргә чакырды. Росстат ведомство җитәкчесе урынбасары Сергей Окладников милләт һәм туган телгә кагылышлы сорауларга ни өчен җаваплар




булмавын аңлатты. «Урбанизация, миграция, цифрлаштыру, һичшиксез, нәтиҗәләргә, аларның структур характеристикаларына йогынты ясады. Бу йогынты халыкның милли һәм тел составы буенча мәгълүматында аеруча ачык күзәтелә», - дип билгели Окладников.

Росстат башлыгы урынбасары милли тартым турындагы сорауга җавап бирмәүчеләрнең кискен артуын ассызыклады.

«Сәбәпләре шул ук. Әлбәттә, тирәнрәк анализларга кирәк. Чынлыкта исә, эшкәртү процессында без электрон биттә туган тел (родной язык) турында мәгълүмат тутырылган, ә милли тартым (национальность ) турындагы мәгълүмат күрсәтелмәгән. Халык, туган телне күрсәткәч, милләте дә автомат рәвештә күрсәтелә, дип уйлап, бланкның ул юлын буш калдырган. Менә мондый бланклар саны 3 миллионга җитте», - дип аңлата Окладников. Аның сүзләренчә, электрон форматта җанисәп узарга җыенган халык яртылаш тутырылган бланк булыр дип көткән, ә анда һәр мәгълүматны кулдан тутырырга кирәк.

“Шулай итеп, бәлки, күпчелеге анкеталарны тулысынча тутырырга иренгән. Нәтиҗәне үзегез күрәсез», - дип фаразлый Росстат башлыгы урынбасары.

«Халык санын алу нәтиҗәләре буенча ачыкланган тагын бер үзенчәлек - этник уртаклыкларның кискен артуы. Аның сүзләренчә, яшьләр арасында этник тиңдәшлеккә кагылыш-




лы сорау авырсыну тудыра. Алар үзләрен тәгаен билгели алмыйлар. Аларга үзләренниндидер гражданлык критерийлары, территориаль критерийлар белән чагыштыру җиңелрәк. Ә милләткә кагылышлы сорау, чыннан да, кыенлыклар тудыра, - ди Сергей Окладников. - Шулай ук туган телендә иркен сөйләшмәгән кешеләр үз милләтләрен билгеләүдә кыенсыналар.

Бәлки, «югалган» 590 мең татар нәкъ менә шушы мин атап үткән группалардадыр”.

Росстат 2026 елдан да соңга калмыйча микроперепись үткәрергә ниятли. Шул исәптән, Россиягә кушылган яңа территорияләрдә барысын да яңадан язарга җыеналар. Ә киләсе Бөтенроссия халык санын алу 2030 елга планлаштырылган. Бу вакытта мәгълүматларны халык турында федераль мәгълүмат регистрыннан алачаклар. Ул 2025 елда эшли башларга тиеш. Җитмәгән мәгълүматларны традицион ысул - халыкны сораштыру ярдәмендә җыячаклар.

Ә ныклабрак уйлап карасаң, барысы да үзебездән тора. Татар авылларында балалар рус телендә сөйләшә. Яшьләрдә туган телгә карата мәхәббәт тәрбияләмибез, гореф-гадәтләребезне сакламыйбыз, милли ядкәрләребезне кадерләмибез, бала тапмыйбыз. Шулай булгач, кимибез инде. Яшьләрдә милли үзаң юк, бик күпләре, зур шәһәрләргә киткәч, татар телен кирәксенми башлыйлар. Яши-яши аңлыйлар инде алар: шәһәрдә күркә булып күперенеп йөрсәң дә, татар тавыгы икәнеңне барысы да беләә, күркәләр көтүеннән сине барыбер куып чыгарачаклар.

Рус телендә сөйләшсәң дә, туган телеңне дә онытмаска, буыннан-буынга күчереп барырыга кирәк, дип фикерлибез. Ә сез ничек уйлыйсыз, кадерле укучыларыбыз? Һәрхәлдә, әлеге вазгыятьнең сәбәбен ачыкласак, киләчәктә күрсәткечләрне уңай якка үзгәрту мөмкинлеген дә табар идек.

# ИҢ МАТУР ЧӘЧӘГЕБЕЗ СУЛА ТҮГЕЛМЕ?

## Иҗтимагый җәмгыятьләрнең тырышлыгы гына аз, эшне гаиләдән башларга кирәк

***21 нче февраль – Халыкара туган тел көне. Рус педагогы, язучы Константин Ушинский: «Халыкның теле - рухи тормышының иң яхшы, беркайчан да шиңми, мәңге яшәреп тора торган иң матур чәчәге ул. Туган телдә бөтен халык һәм аның Ватаны гәүдәләнә, рухи тормышының тарихы чагыла», - дигән.***

*Эльмира СӘЙФУЛЛИНА*

Кызганыч, тик татар теле соңгы елларда уңдырышсыз җирдә үскән һәм сусаган гөлне хәтерләтә. Татарстан да, төрле өлкәләрдә эшләп килүче татар оешмалары да, туган телебезне саклап калу өчен, бик күп көч куялар. Ә нәтиҗә барыбер куандырырлык түгел әлегә. Чипчиста татар авылларына барып кергәч тә, балаларның үзара гел русча яки ике сүзнең берсен рус сүзләре кушып сөйләшкәннәрен ишетергә туры килә. Бик аяныч хәл...

Бу проблема кайчан килеп чыкты һәм аны ничек итеп уңай якка үзгәртергә, дигән сорау белән Похвистнево районының Гали авылы урта мәктәбендә кырык елдан артык укытучы булып эшләгән Гөлия Мингазизовна Мәхмүтовага мөрәҗәгать иттек.

Гөлия ханым Гали авылы урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Алабуга педагогика институтында рус, татар телләре һәм әдәбияты белгечлегенә укый. Диплом алгач, туган авылына кайта һәм гомерен яраткан хезмәтенә багышлый. Үзе укытып чыгарган Гүзәл Гозәерова да, укытучы һөнәрен үзләштереп, туган авылына кайткач, 2021 - 2022 уку елында Гөлия Мингазизовна лаеклы ялга китә. Әмма, укытучылар җитмәгәнлектән, быел аңа янә эшкә чыгарга туры килә. Тик бу юлы инде татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак.

«Быелгы уку елыннан башлап, башлангыч сыйныфларда татар теле факультатив рәвешендә генә, ә 5 - 11 сыйныфларда – атнага бер сәгать кенә укытыла. Ә татар әдәбияты факультатив дәрес булып калды. Әле болар да мәктәп директоры тырышлыгы белән генә сакланды. Татар теле дәресләре бөтенләй тукталмасын дип, бөтен көчебезне куябыз. Башка районнарда, өлкәләрдә, хәтта Татарстанда да татар теле дәресләрен тукталткан очраклар шактый икән», - дип авыр сулый мөгаллимә. Ә моннан ун еллар чамасы элек татар теле һәм әдәбияты биредә атнасына 3 – 4 сәгать укытылган. Хәтта ата-аналар мәктәп җитәкчелегенә рус теле дәресләрен арттыруны сорап та мөрәҗәгать иткәннәр. Янәсе, балалар туган телләрен болай да яхшы беләләр, татарча сөйләшәләр, ә шәһәргә киткәч, аларга рус теле кирәк булачак. Ә бүген бу сәясәтнең уңышын җыябыз, балаларыбыз ана телен белми, дип, чаң сугарга калды.



- Татар телен укыта башлагач, әлеге проблеманың никадәр кискен икәнлеген күреп, шаккатым. Башка сыймаслык хәл – татар авылында туып-үскән, шунда яшәгән балалар туган телләрендә сөйләшмиләр! Алай гына да түгел, кайберләре инде татарча аңламый да башлаганнар. Без беренче мәлләрдә бу хәлне балалар бакчасы күрше Рысайкино авылында булу белән бәйли идек. Хәзер инде үзебезнең балалар бакчасы да бар. Ләкин барыбер рус теле хөкем сөрә. Әлеге хәл бөтен авыл халкын нык борчый, без бу проблеманы бергәләп, мәдрәсәне дә җәлеп итеп, хәл итәргә булдык. Җыелышлар, туган телне белүнең мөһимлеген яшь буынга җиткерү өчен, төрле чаралар уздырабыз. Шулай сөйләшә-уйлаша торгач, монда балалар бакчасының катнашы булса да - бик аз, ә телне белмәү гаиләдән килә, дигән нәтиҗәгә килдек. Нужа куабыз, иртәдән кичкә кадәр эштә, аннан соң бакча, теплицалар, маллар...Ә балаларны гаджетлар тәрбияли. Алар көннәр буе русча мультфильмнар, роликлар карыйлар. «Әни, әти», дип әйтергә өйрәнмәгән балалар иң элек башка тел белән танышалар, туган телгә вакыт та калмый, кызыксыну да юк. Балаларыбызның татар телен туган тел дип санамаган көнгә килеп җиткәнебезне сизми дә калдык. Иң кызганычы шул: кая таба тәгәрәгәнебезне аңламаганбыз.

Хәзер инде татар теле дәресләрен ике телдә алып барыр-

га туры килә. Теманы татарча атыйм да бераз русча аңлатам. Кагыйдәләрне элек русчасын искә алабыз, аннан соң татарчага тәрҗемә итеп бирәм. Татар теле кагыйдәләре бик авыр, аларны ятлау гына аз, аңларга кирәк. Эшләргә бик кыен, күзләрен тутырып карап торган татар балаларының татарча аңламавын күрү йөрәкне телгәли, моны кабул итүе бик авыр. Дөрес, араларында бик матур итеп татарча сөйләшүчеләре дә бар, бөтенләй юк түгел. Аларның әтиәнисе дә татарча сөйләшә. Берничә укучым, мәктәпне тәмамлагач, Казанга китәргә ниятли. Шуңа күрә алар, миннән китаплар алып, үзләре өстәмә шөгыльләнәләр. Әмма, кызганыч, күпчелеге туган телне белми, шуңа күрә әдәбият дәресләрен дә тиешле рәвештә уздырып булмый. Яхшы иттереп татарча аңламаган бала матур әдәбиятны ничек аңласын ди инде?! Аннан соң дәреслекләр җитмәү проблемасы да бар. Бәлки,



Татарстан бераз ярдәм итәр, дип көтәбез әле менә, - дип авыр сулый Гөлия ханым.

Ниһаять, Гали авылында балалар бакчасы эшли, хәзер малайлар, кызлар күрше авылга йөрмиләр. Туган телебезне саклап калуны өлкән буын үз өстенә алган икән. Нәтиҗәсе булыр, дип ышанабыз. Җирле «Ак калфак» татар хатынкызлары оешмасы җитәкчесе Кәүсәр апа Шәйхетдинова һәм гомере буе татар теле укытучысы булып эшләгән Зөлфия ханым Асылгәрәева, атна саен балалар бакчасына барып, нәниләр белән татарча сөйләшеп, аралашу өчен кирәкле сүзләрне өйрәтәләр, милли уеннар, йолалар белән таныштыралар, татар җырларын һәм биюләрен өйрәтәләр. Быел, алдагы еллардагыча, «Татар кызы, татар малае» конкурсы уздырырга планлаштыралар. Ата-аналар белән дә актив эш алып барыла. Аларның үз хаталарын аңлавы, өйдә үзара гел татарча сөйләшергә әзер булулары, аз булса да, уңышка якынайта кебек.

Гөлия ханым белән әңгәмәгә йомгак ясап, эшне гаиләдән, атаанадан башларга кирәк, дигән нәтиҗәгә килдек. Моны дәлилләү өчен, ул улының гаиләсен мисал итеп китерде. Күптән Самарда яшәүче гаилә ике малай үстерә. Шәһәрдә яшәп, рус мәктәбендә укуларына карамастан, Гөлия ханымның ике оныгы да саф татар телендә сөйләшәләр. Чөнки әти-әниләре үзара да, балалары белән дә гел туган телдә генә аралашалар икән.

Өлкәбезнең башка районнарында да туган телебезне өйрәнү проблемасы бар. Мәсәлән, Похвистнево районындагы Яңа Мансур авылы мәктәбендә дә татар теле 1 - 8 сыйныфларда класстан тыш (внеурочный) дәресләр буларак атнага ике сәгать укытыла. Шулай булуга карамастан, укучыларның татар теле буенча олимпиадада катнашмыйча калганнары юк. «Безнең мәктәптә күрше Сосновка авылы балалары да укый. Сыйныфтагы 6 - 7 укучының зур өлеше - башка милләт балалары. Авылда яшьләр аз, буш йортларны рус һәм башка милләт кешеләре сатып ала. Бераздан авыз тутырып татарча сөйләшергә кеше булмас инде, дип кайгырабыз», - ди татар теле һәм әдәбияты укытучысы Лилия Нуртдинова.

Камышлы районының Яңа Усман авылы урта мәктәбендә 200 бала укый. Шул исәптән рус, чуваш һәм башка милләт балалары да. Башлангыч сыйныфларда татар теле дәресләре уздырылмый, ә 5 - 11 сыйныфларда туган тел атнага бер сәгать кенә укытыла.

«Иске Ярмәк авылы мәктәбендә беренче сыйныф укучылары атнага бер тапкыр татар теле түгәрәгендә шөгыльләнәләр, 2 - 4 сыйныфлар татар телен класстан тыш дәресләрдә өйрәнәләр, ә 5 - 11 сыйныфларга татар теле атнасына бер сәгать керә. Шунысын да билгеләп үтәсем килә: 6 сыйныфларда татар теле атнага бер сәгать һәм өстәмә бер сәгать факультатив рәвештә укытыла», - дип аңлатты мәктәп директоры Равилә Хәйдәровна Гыймадиева. Аллаһыга шөкер, бөтенләй бетмәгән икән әле татар теле дәресләре. Шулай да, ана телен өйрәнүгә бирелгән сәгатьләрнең елдан-ел кимүе күзгә бәрелеп тора. Өйдә дә, мәктәптә дә туган телдә аралашу булмаса, татар теле бөтенләй онытылмый нишләсен?

Ә менә Удмуртиядә атнага ике сәгать татар теле һәм ике сәгать әдәбият укытыла икән, Свердловск өлкәсендә туган тел атнага өч сәгать керә, ди. Ни өчен безнең өлкәдә мондый хәл?

Халыкара туган тел көне - ЮНЕСКО Генераль конференциясе тарафыннан игълан ителгән, бөтен дөньядагы туган телләрне, аеруча аз санлы халыкларның телләрен саклауга, үстерүгә булышлык итү максатыннан билгеләнгән көн. 2000 елның февраленнән башлап, ел саен тел һәм мәдәниятнең төрлелегенә ярдәм итү максатыннан дөньякүләм билгеләп үтелә. Ә, минемчә, туган телне ЮНЕСКО гына түгел, башка мөһимрәк оешмалар сакларга тырышса да, үзебезнең теләк һәм тырышлык булмаса, туган телебез, һичшиксез, юкка чыгачак.

# “Татарлар – үз заманында бөтен төрки халыкларга үрнәк булып яшәгән халык”

*Кеше тәрбиясенең иң үтемлесе - ана тәрбиясе. Шуңа да Ана образы әкиятләрдә, риваятьләрдә һәм башка халык авыз иҗатында изгеләштерелгән.*

***Фәрид Шириязданов***

«Тел югалса – халык югала!» – дигән сүзләрне, телнең әһәмияте, аны саклауның кирәклеге турындагы лаф оруларны без хәзер еш ишетәбез. Тик ана телебезнең хәлләре генә торган саен мөшкелләнә бара.

Бу проблеманы хәл итү өчен, эшне ата-бабаларыбызның ничек итеп ана телен, динен, милли үзаңын гасырлар буена саклап килү серләренә төшенүдән башларга кирәктер.

Бу хакта танылган язучы, драматург, публицист, Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый исемендәге премияләр лауреаты һәм үз милләте язмышын тирәнтен кайгыртып яшәүче Рабит ага Батулланың уй-фикерләрен дә белергә тырыштык.




***– Халкыбызның милли үзаңы зәгыйфьләнүе, телебезнең, гореф-гадәтләребезнең югалу юлында булуы турында хәзер күп сөйләнә. Тик шулай да, бу проблемалар әлегәчә сакланып килә. Бу хакта ниләр уйлыйсыз?***

– Безнең милли йолаларыбыз, гореф-гадәтләребез һәм бәйрәмнәребез әлегәчә халкыбызның җанына сеңеп, аның телендә, әдәбиятында сакланып килделәр. Меңнәрчә еллар дәвамында алар татар халкының тормыш нигезе булып хезмәт иттеләр. Ни кызганыч, тик озак вакыт басым астында булганга, аларга шактый зур зыян килде.

Хәзерге көндә безнең алдыбызда торган иң бөек максат – ул ата-бабаларыбыз саклап килгән рухи мирасыбызны яхшылап үзләштереп, аны халкыбызга да җиткерү. Тик шунда гына, буыннар арасындагы бәйләнеш югалмыйча, безнең халык бөек милләт булып яшәвен дәвам итәчәк.

Милләт үзенең язмышына, мәгарифенә, диненә, теленә, тарихына үзе баш булырга тиеш. Узган гасырның утызынчы елларына кадәр татар халкы үз язмышын үзе кайгыртып яшәде. Мәктәпләр байлар хисабына төзелде, һәм мәчетләрне дә халык үзе төзи иде.

Хөкүмәт бюджетыннан акча алмыйча, татарлар үз яшьләрен Франциягә, Бейрутка, Берлинга һәм башка җирләргә җибәреп укыта иде. Милләт хәлен, аның киләчәген кайгырту менә шундый булырга тиеш.

Безнең интеллигенция алты тел белгән. Ә без русча белсәк – татарча сөйләшмибез, татарча белсәк – русчабыз юк. Татар халкы – үз хисабына югары мәктәпләр тоткан халык. Мәсәлән, Иж-Бубый, «Галия» кебек мәдрәсәләр югары уку йорты булып исәпләнгән бит!

Ә бүгенге көндә без урта мәктәпләребезне генә түгел, башлангыч мәктәпләребезне дә ябабыз. Хәзер инде ана телебезгә кизәнәбез. Ә тел – ул милләтнең җаны бит. Кеше җанында үз милләтенә, аның үткән тарихына, рухи казанышларына хөрмәт яшәгәндә генә, телгә карата да хөрмәт яши. Тел яшәсә – халык яши, яшәмәсә – ул ассимиляцияләнә һәм башка халыклар арасында эреп югала.

Моңа күп мисаллар китереп була. Мәсәлән, хәзерге вакытта Финляндиядә 300 мең швед яши. Анда икенче дәүләт теле – швед теле. Швед, кибеткә кереп, үз телендә сүз катса, аңа шведча җавап бирәләр. Гаризаларын да алар үз телләрендә язалар, судлары да швед телендә үтә.

Финляндиядә яшәгән ун мең саоми халкы да башлангыч белемне үз телләрендә ала. Ә башлангыч белемне үз телендә алган кеше туган телен беркайчан да онытмый.

***– Телебезне һәм халкыбызның милли казанышларын саклау өчен, нинди юллар бар? Боларны гамәлгә ашыру өчен, киләчәктә ниләр эшләргә?***

– Моның өчен, артка карап, халкыбызның үткәннәреннән гыйбрәт ала белергә кирәк. Элгәре

Россиядәге татарлар яшәгән бар җирдә дә үз мәктәпләре бар иде. Шулай ук Мәскәү, Санкт-Петербург, Оренбург, Самар, Әстерханда, Кырым, Баку кебек башка зур шәһәрләрдә дә милли мәгариф татар халкына хезмәт иткән.

Шуңа күрә татар язучылары Казанга да төрле яклардан килә иде. Хәзер башка өлкәләрдән милли каләм осталары килми. Алар бары тик Башкортостаннан гына килә. Чөнки күп авыллардагы мәктәпләрдә татар теле атнага берике сәгать кенә укытыла. Әле ул да факультатив рәвешендә генә. Ә күп татар авылларындагы мәктәпләр бөтенләй ябылган.

Элгәре эшкуарлар, зыялы катлам кешеләре мәктәпләр эшчәнлеге, халкыбызның киләчәге турында кайгыртканнар. Парламент утырышларында Максудилар, Акчуралар, милләт файдасын кайгыртып, аяк терәп сөйләшкәннәр. Ә хәзер ни күрәбез?! Сүзләр күп сөйләнә, ә телебез хәле, халыктагы милли үзаң дәрәҗәсе торган саен зәгыйфьләнә бара. Менә шуннан чамаларга була инде безнең хәлне.

Кеше күңелендә үз милләтенә хөрмәт яшәсен өчен, һәркем үз халкының бай тарихын, аның күркәм гореф-гадәтләрен өйрәнеп, аның казанышлары белән горурланып яшәргә тиеш.

Татар кешесенә Зәки Вәлидинең хатирәләрен генә булса да белергә кирәк. Бик зур тарихчы бит ул. Ләкин аны дөрес аңлый белергә генә кирәк. Ул бит Ибн Фадланның юлъязмасын беренче булып тапкан һәм бөтен төрки халыклар файдасына эшләгән тарихчы, чын интеллигент! Ә интеллигент – ул зыялы дигән сүз бит!

1905 елгы түнтәрелештән соң татарда зыялылар катламы гына түгел, зыялылар сыйныфы барлыкка килә. Болар: Зәки Вәлиди, Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Йосыф Акчура, Заһидә Тинчурина, Муса Бигиев һәм башка даһи шәхесләребез.

Зыялылар – милләтебез нигезе. Ни кызганыч, тик җәмгыятебездәге зыялылык – хәзер инде бик зәгыйфь күренеш. Ә без, татарлар, заманында бөтен төркиләргә үрнәк булып яшәгән халык бит! Казакълар, үзбәкләр, чуашлар безгә, таууга караган кебек, карыйлар иде. Ә хәзер без үзебез аларга шулай карыйбыз.

Урыннар алышынды. Без бит, казакълар укый-яза белмәгәндә, аларга кино төшереп, театр корып биргәнбез. Ә хәзер мин аларга карап көнләшәм. Төрле фестивальләрдә очрашканда алар чатнатып инглизчә, төрекчә һәм башка телләрдә сөйләшәләр. Ә без аңгыралардай утырабыз.

Гаяз Исхакыйның әйткәне юш килде – алар безне уздылар. Чуашларны гына карагыз. Беренчедән, алар таралмаган. Телләре бер, үзләре – эшчән халык. Элек чуашлар үз милләтен яшерәләр иде. Хәзер үзләрендә кимсенү хисе бетеп бара. Аларның күбесе инде: «Мин – чуаш!» – дип, горурланып яши!

Менә күрәсезме, халыктагы милли үзаң уяна икән, димәк, милләт җанланып яшәвен дәвам итә һәм яңа үрләр яулый. Чуашлар әле музыка өлкәсендә дә алга китте һәм аларның әдәбияты да үсеш юлында.

Мәсәлән, француз поэзиясен бүгенге көндә алар турыдан-туры үз телләренә тәрҗемә итәләр, ә чуаш шигырьләрен – француз теленә. Инглиз теле белән дә шулай ук. Бу зыялылык түгелмени соң?! Ә бездә мондый бер тәрҗемәче дә юк.

Үз милләтеңнә хөрмәт итү өчен, тагын бер нәрсәне белү кирәк – илебездә яшәүче татарларның һәр кавеме үз җирендә төпләнгән, үзләренең туган туфрагында утыралар. Уралда, Себердә булсынмы, Идел буендамы – безнең бабаларыбыз борынгыдан яшәгән бит бу җирләрдә. Без бирдә килмешәк халык түгел!

Халкының милли рухы көчле булган авылларда татарлар гөрләтеп яши. Мәсәлән, Пенза өлкәсендәге, Чуашстандагы унберәр мәчетле мишәр авыллары, йолаларны, динне, телне саклап, бай яшиләр. Аларга хәтта күрше рус авыллары көнләшәләр!

Ни кызганыч, тик әле күп татар авыллары хәзер авыр хәлдә, югалу юлында торалар. Чөнки аларда татарлык рухы сүнгән. Хәтта әдипләребезнең туган авыллары да бетеп бара бит! Мәсәлән, Рөстәм Мингалимнең Самар өлкәсендәге Йолдыз авылы юк хәзер. Такташның Сыркыдысында да инде татарчаны аңлаучы калмый. Тинчуринның Таракан авылы да шундый ук хәлдә. Менә бит фаҗига кайда!

***– Авыллар югалмасын, аларда халкыбыз яшәсен өчен, нәрсә эшләргә кирәк?***

– Бу – зур проблема. Моның өчен халыктагы күңел байлыгын кайгырту кирәк. Менә Казанда – җитмешләп, ә Татарстанда мең ярымлап мәчет бар. Ләкин мәчет корып кына динне кайтарып булмый шул. Муллалар гафу итсеннәр, аларның күбесе хәзер тиешле белем алмаган хәлдә. Безгә хәзер зыялы муллалар кирәк. Мулла – ул галим дигән сүз бит! Мөллә-хафиз борынгыдан гыйлемле, зур дәрәҗә иясе булып саналган. Имам – ул һәрьяклап үрнәкле, халыкны ияртә алырлык, абруйлы һәм укымышлы, гыйлем иясе булырга тиеш. Хәзерге бөтен дөнья ялганга, комсызлыкка корылган, һәркем үз мәнфәгатен генә кайгыртып яшәгән дәвердә бу – аеруча мөһим мәсьәлә.

Мәнфәгать – ул кеше малына, башкалар кулындагы байлыкка кызыгу рәвеше. Ни өчен хәзер гарәп илләрендә тоташ сугыш бара соң?! Әфган, Гыйрак, Иран, Мисыр, Сүрия һәм башка мөселман илләре – бүген ут эчендә. Бар җирдә нефть, байлык өчен сугышалар. Аллаһы Тәгаләнең мөселманнар яшәгән җир астына нефть салуы – ул үзе бер авыр сынау бит! Монда йөзә белсәң – йөзеп чыгасың, белмәсәң – тончыгачаксың дигән кебек хәл.

***– Үз халкының хакыйкый тарихын, ата-бабаларының тормыш батырлыгын, милли йолаларын белмәгән һәм белергә дә теләмәгән кешедә үз милләтенә карата хөрмәт яши аламы?***

– Татар кешесенең милли үзаңы борынгыдан ана теле аркылы һәм тарихыбызның чишмә башында

торган әкиятләр, риваятьләрдәге серле күренешләр тәэсирендә тупланган. Үз милләтенә, ана теленә хөрмәт аңа кечкенәдән бишек җырлары аша, ана сөте белән җанына сеңдерелгән.

Халкыбызның асылы аның әкиятләрендә, халык авыз иҗатында ачык күренә. Бар булган татар әкиятләре – тирән тарих чыганаклары бит. Әкиятләрдә тасвирланган образлар, вакыйгалар йә булган, йә булачак фәлсәфи күренешләр.

Аларда халкыбызның борынгыдан килгән дөньяга карашы, тормыш фәлсәфәсе тупланган. Мәсәлән, Ак бүре образы – ул табигать сакчысы. Төркиләрдә ул – иң уңай һәм изге образ. Чөнки төрки халыклар чыгышы белән бүре нәселеннән, дип санала.

Без әкиятләребездә тупланган серләрне һәм аларның кадерен әле белеп тә бетермибез. Мәсәлән, «Сак-сок» бәете – асылда әкият. Ул – безнең иң борынгы, моннан меңнәрчә еллар элек барлыкка килгән музыкаль әсәребез. Ул исламга кадәр үк язылган, чөнки монда «Аллаһ» сүзе, Аллаһка карата мактау да юк. Аның эчтәлеге, Ана канунына нигезләнеп, матриархат чорында барлыкка килүенә ишарә ясый. Менә кайларга барып тоташа бит безнең борынгы тарихыбыз! Мондый борынгы әсәр бер халыкта да юк. Моның нигезендә фәнни ачышлар ясап, фильмнар төшерергә була бит!

***– Хәзерге замандагы әхлак һәм әдәп хәлләре хакында ниләр әйтә аласыз?***

– Бу – бик әрнүле мәсьәлә, бигрәк тә хатын-кызларга кагылганда. Ни өчендер алар үзләрен гарипләндерә башлады. Күкрәк, ирен кабарталар – гариплек бит бу. Дөнья артыгын кылануга әйләнде шул хәзер. Зәвык үзгәрде. Сәнгатьтә дә шул ук хәл.

Ямьсезлек хәзер матурлыкны каплап китте. Бу дөнья яңадан үз хәленә кайтыр әле, дип ышанам мин. Чөнки безнең халыкның эчтәлеге, үзкыйммәте бик бай.

***– Татар тарихы бик тирән. Алар Россия киңлекләрендәге бар җирдә дә күзгә бәрелеп тора. Тик әле шуларның күбесенә тиешле рәвештә әһәмият бирелми. Алар хакында нинди фикер йөртәсез?***

– Чикмән кигән, янбашына кылыч таккан гранит, мәрмәр яисә тау ташыннан ясалган сыннар белән унбер мең чакрым Евразия җирләре тулган!



Ерак Көнчыгышта, Урта Азиядә, Украина, Кырым далалары уртасында бихисап таш балбаллар басып тора. Болар бит – борынгы татар кешесе сурәте! Аларга очрый калганда, татарлар, баш иеп, әбибабаларының, әти-әниләренең рухына дога кылганнар.

Меңләгән балбаллар арасында хатын-кызлар сыннарының күбрәк булуы күпне аңлата һәм уйландыра. Бу бит – аналарга куелган һәйкәлләр, дигән сүз! Алар, гаилә учагын сүндермичә, газиз телне, токымны саклаучы һәм аны тәрбия кылучы аналар сыны була түгелме соң?!

Бу сыннарда келәм сугучы, җәйге челләдә бозылмаслык ризык әзерләүче, барлык тормыш авырлыкларын үз җилкәләрендә күтәрүчеләр – аналар сурәтләнгән. Токымның дәвамы анада булганга, бу сыннар бөек Ана хөрмәтенә бастырылган!

Ә янбашына кылыч аскан, тустаган тоткан балбал – кем? Ул – борынгы ир-ат! Ватанын, гаиләсен, балаларын, токымын саклап, яуларда һәлак булып, дала туфрагына башын салган баһадир ул!

Бу сыннар – асыл татар-төрк угыл-кызлары хөрмәтенә калыккан мәңгелек һәйкәлләр.

***– Халкыбызның йолалары арасында Сабан туен бәйрәм итү аеруча зур урын алып тора, һәм ул бүгенге көнгәчә үз төсен, сыйфатын һәм әһәмиятен югалтмаган кебек. Аның килеп чыгышы нинди?***

– Сабан туе – бик борынгыдан килгән бәйрәм, дип сөйләнә. Аның Олимпия уеннары белән дә охшашлыгы бар. Дөрес, Олимпия уеннары дүрт елга бер уздырылса, Сабан туе әлегәчә һәр ел саен үткәрелә.

Кытай чыганакларында Сабан туена охшаш мәртәбәле чараны сурәтләгән язма бар. Анда бу бәйрәмне һәр елны каршылаганда татар дәүләтенең башлыгы Җания оештыруы турында язылган. Җания – ул җаннар иясе, дигән сүз. Әле каһаннар хакимияте барлыкка килгәнче үк, бик борынгы заманнарда Җания татар халкының дәүләт башлыгы булган. Дини, хәрби якны һәм тормыш итү тәртибен үл үзе җитәкләгән. Ул – җиргә төрки халыклар белән идарә итү өчен Тәңре тарафыннан җибәрелгән изге зат, дип саналган.

Ахырдагы чорларда төрле җирләрдә яшәгән төрки-татарларда бу бәйрәм Җыен, Корылтай, Тупланыш дип тә аталган. Без үскәндә дә әле Җыен һәм Сабан туе аерым бәйрәм ителә иде. Соңыннан гына аларның икесен бергә кушты-лар. Җыен, аксакалларның үзара киңәшмәсе булып, анда төрле мәсьәләләр яисә карарлар уртага салып хәл ителә иде. Бу йола тәңречелек заманыннан килгән. Анда башта җыен (киңәшмә, фикер алышу) уздырылган, хөкем чыгарылган, аннан соң бәйрәм ясаганнар.

Борынгы бабаларыбыз Күккә (Тәңрегә, Кояшка), Җиргә, аннары әрвахларга багышлап корбан чалганнар. Корбан итеннән бөтен халык (будун) авыз иткән. Аннан соң ат узышлары, дөя ярышлары башланган. Узышларны Җания үзе күзәткән һәм, үзе нәтиҗә ясап, карар чыгарган.

Җания идарә иткән елларда җинаять кылыну бик сирәк күренеш булган. Бу чарада җыелган

халык алдында җинаятьләрне фаш иткәннәр, нинди җәза бирү турында киңәш-табыш корганнар. Хөкемне дә Җания оештырган. Гаепсез кешегә һөҗүм итеп, аны җәберләү борынгылардан иң зур җинаять саналган. Андый кешенең җинаяте расланса – аны үлемгә хөкем иткәннәр. Яисә җинаятьченең гаиләсе каршы якка аның салган зыянын кайтарып биргәнче, ул кол булып торган.

Җания – бик борынгы идарәче образы. Каханнар (ханнарның ханы) турында тарихи чыганакларда моннан ике мең еллар элек булган вакыйгалар сурәтләнә. Ә Җанияләр тарихы күпкә борынгырак булган. Алар турындагы мәгълүматлар хәтта әкияти заманнарга барып тоташа. Бу хәл тагын бер кат безнең тарихыбызның никадәр тирән икәнлеген раслый бит!

***– Безнең борынгы тарихыбыз хәзерге көндә дә томан артында сыман. Анда әле бик күп серләр саклана, шулаймы?***

– Борынгылар табигать, галәм серләрен белергә омтылганда, аларның күзәтүләре нигезендә халык сынамышлары барлыкка килгән. Болар яңгыр, кар явуы, күк күкрәве һәм табигатьтәге башка күренешләрнең серен белергә тырышу белән бәйләнгән. Мәҗүсилек вакытында барлыкка килгән халык сынамышлары соңрак ислам һәм христиан (керәшеннәрдә) дини карашлар белән аралашалар. Нәтиҗәдә алар мәкаль-әйтемнәр, ышанулар, арбаулар, келәүләр рәвешендә календарь йолаларына килеп керәләр. Әле Болгар чорында да безнең ата-бабаларыбыз һәр унике елның үз «иясе» (хуҗасы) бар, дип инанганнар. Ахырда бу ышанулар, халык календарена кереп, йола иҗатына әверелгәннәр. Бу караш буенча, унике ел бер мөсәл (цикл) барлыкка китерә, һәм ул түбәндәгечә күзаллана: Тычкан, Сыер, Барыс, Куян, Ләү (кәлтә балык), Елан, Елкы, Куй, Мичин (маймыл), Тавык, Эт һәм Дуңгыз еллары.

Календарь иҗатында шулай ук келәүләр (теләүләр) дә шактый үзенчәлекле урын билиләр. Алар



әле күп йолаларда да зур чагылыш табалар. Мәсәлән, карга келәве (карга боткасы яки карга туе), балык келәве (балыкның күп булуын сорап үткәрелгән бәйрәм), кыр келәве (яңгыр боткасы яки яңгыр бәйрәме), ызба келәве (яңа өй котлау мәҗлесе) һәм башкалар.

Билгеле булганча, Россиядә Петр I тарафыннан кертелгән календарь системасы татарларда бары тик XIX йөз урталарында гына ныклап урнаша. Ә аңа кадәр алар Зодиак йолдызлыгына нигезләнгән язма календарь белән эш итәләр.

***– Тарих – үтемле тәрбия чарасы һәм көчле сәяси корал. Тик халкыбызның милли үзаңы һәм теле авыр хәлдә калганда да, бу мөмкинлек әле бөтенләй кулланылмый диярлек. Бигрәк тә Татарстаннан читтәге төбәкләрдә. Моның сәбәбе нидә?***

– Югарыда бирелгән кыскача мәгълүматлардан да милләтебез тарихының никадәр серле, бай һәм тирән булганлыгы аңлашыла. Аны өйрәнеп белгән вакытта, һичшиксез, һәр аңлы кешедә татар милләтенә хөрмәт уяначак.

Дөрес, хәзерге вакытта татар тарихын үстерү зур адымнар белән алга бара. Ни кызганыч, тик бу алгарыш әле галимнәр арасыннан халыкка җитешә алмый. Аларны күпләрнең сүрелгән аңына җиткереп, үз милләтенең хакыйкый тарихына, теленә һәм рухи мирасына хөрмәт уяту өчен, бик зур эшләр башкарып, алдагы кыенлыкларны җиңәсе бар.

Телгә битарафлык хәзер балаларда гына түгел, аларның ата-аналарында, хәтта әби-бабаларында да ныклап төпләнгән. Ә уйлап карасаң, үз теленнән язган, үз милләтеннән читләшкән кеше – ул мескен кеше. Аның матди байлыгы никадәр күп булса да – рухы ярлы. Ул мескен һәм көтүдән адашкан сарыктай күренә», – диде Рабит абый Батулла.

Милли үзаңы зәгыйфь кешенең кыйбласы да адашкан. Ни кызганыч, тик мондыйларның саны арткан саен милләтебезнең киләчәге хакында ямансу уйлар туа.

Ана телен өйрәнүгә кешене мәҗбүр итү – файдасыз эш. Күңеленә ялган тарих сеңдерелгән кешедә, иң элек, үз халкының үткәннәрен, тарихын, телен белүгә омтылыш тудырырга кирәк.

Бу очракта ата-бабаларыбыз үткән данлыклы тормыш юлын, алардагы күкрәп торган чын татарлык сыйфатларын ачыклап күрсәтә алганда гына, уңай нәтиҗәләргә ирешеп булыр иде.

Татар тарихы бай һәм гыйбрәтле. Татар инде үлде, бетте, дигәндә дә, аның бер кабиләсе яисә төркеме калкып, бөтен төркиләр дөньясын хәрәкәткә китергән һәм аның данын тиешле югарылыкка күтәргән. Артык тирәнгә кермәсәк тә, без моны 18–19 гасырлардагы һәм 20 гасыр башындагы хәлләрне күзәткәндә ачык күрәбез.

# Айгөл Әхмәтгалиева: «ТУГАН ТЕЛ – ӘМАНӘТ УЛ»

***Язучы Айгөл Әхмәтгалиева беренче күрүдә үк үзенең эчкерсезлеге, тыйнаклыгы, әдәплелеге белән җәлеп итә. Авыл китапханәсендә укучылар белән очрашканда да, журналистлар, күренекле шәхесләр белән әңгәмә корганда да ул үзен бик табигый тота. Әңгәмәдәшенең кем булуына карамастан, зур ихтирам белән, бөтен игътибарын юнәлтеп сөйләшә. Һәр сүзе урынлы, мәгънәле, сайлап алынган. Аның белән аралашу – үзенә күрә бер тәрбия дәресе, тел байлыгын үстерү мөмкинлеге.***

***Нигә Айгөл ханым үзен ялкау язучы, дип атый һәм ни сәбәпле ул «Хәния» китабын бикләнеп язган? Халыкка аңлаешлы булсын өчен, урам телендә сөйләшергә кирәк, дигән фикер дөресме? Яшьләр татар театрына йөриме? Шушы һәм башка сорауларга җавапны Аяз Гыйләҗев исемендәге Яр Чаллы татар дәүләт драма театрының әдәби бүлек җитәкчесе Айгөл Әхмәтгалиева бирде.***

***Гөлназ Таипова.***



*Айгөл Габдулла кызы Әхмәтгалиева - язучы, драматург, киносценарист. Татарстанның журналистлар һәм язучылар берлекләре әгъзасы, Сажидә Сөләйманова, Илдар Юзеев исемендәге әдәби премияләр, Мәхмүт Кашгарый исемендәге халыкара премия лауреаты. 2014 елны халыкара бәйгедә катнаша. Әлеге конкурсның беренче туры төрки телле дәүләтләрдә үткәрелә, җиңүчеләрнең әсәрләре төрек теленә тәрҗемә ителә һәм халыкара бәйгедә катнаша. Айгөл Әхмәтгалиева Татарстанда – беренче, дәүләтара бәйгедә – икенче урынны яулый.*

– Кисәк кенә сорасалар, барлыгы ничә китап язганымны тиз генә әйтеп бирә алмыйм. Үз биографиямне мәктәпләрдә, китапханәләрдә очрашуларда ишетеп, хәтеремдә яңартып кайтам, – ди Айгөл Әхмәтгалиева көлеп. – Күптән түгел характеристика сораганнар иде, шуны язганда санадым: унөч китабым бар. Шулардан үзем өчен иң затлылары – «Туташ» белән «Таллыкүлдә былбыл бар». Сәхнә әсәрләрен дә өзеп кенә әйтә алмыйм. Дәүләт театрларында минем пьесалар буенча унбер спектакль куелган, ә халык театрларындагыларын төгәл белмим. Күп очракта театр коллективлары үзләре миңа чыгалар, ә кайчак әйтеп тә тормыйлар, спектакль чыгып, кайтавазлар ишетелә башлагач кына беләм.

Мәхмүт Кашгарый исемендәге бәйгедә Айгөл Әхмәтгалиева «Капка» хикәясе белән катнаша. 2021 елны бу хикәя буенча пьеса яза, ул Чаллы татар драма театры һәм Оренбург театрында сәхнәләштерелә. Хикәянең бер генә сүзен дә үзгәртергә теләмәгән автор режиссер күзаллавы белән башта килешми, бәхәсләшә. Ләкин бүген ул: «Мин режиссерга тулысынча ышандым һәм ялгышмадым. Бик зәвыклы, затлы тамаша килеп чыкты», – ди.

## Драматург булдым, дип әйтмәс идем

– Хикәя спектакль буларак сәхнәгә менгәч, нык үзгәрә, башка форматка әйләнә. Башта мин кайбер үзгәрешләргә риза булмадым, режиссер Олег Кинҗәгулов белән бәхәсләштем, – дип аңлата Айгөл Әхмәтгалиева. – Ләкин ул ышандыра торган дәлилләр китерде. Сәхнәнең үз законнары, тамашачыга тәэсир итү өчен үз юллары бар. Мин Олег Мадиярович белән килештем. Һәр кеше үз эшендә оста. Сәхнә хуҗасы барыбер үзенчә аңлый, үзенчә тоя, күрә.

«Иң яхшысы шушы, әгәр моны киссәң я өстәсәң, начар булачак»,



*«Мәхмүт Кашгарый исемендәге премия минем өчен бик якын, бик кадерле», – ди Айгөл Әхмәтгалиева.*

Театрның әдәби бүлек җитәкчесе буларак, Айгөл Әхмәтгалиева гел эзләнүдә. Нинди чара үтемлерәк, яшьләрне нәрсә белән кызыксындырып була? Театр яңа бинага күчкәч, «Театраль педагогика» дигән яңа проект гамәлгә куела. Аның кысаларында танылган язучылар турында өлкәннәр һәм мәктәп балалары өчен спектакльләр сериясе әзерләнә. Моннан тыш, поэтик перформанслар үткәрелә. Бу да - Чаллы театры өчен яңа формат. Перформансларның беренче максаты – Чаллы әдипләренә игътибар итү, икенчесе – зәвыклы, мәгънәле шигырьләрне тамашачыга җиткерү. Перформанс сәхнәдә

– дип, үзеңне дә, режиссерны да ышандыра аласың икән, ул чагында үз әйбереңөчен калкандай торып буладыр. «Капка»ны хикәя буларак бик яхшы яклый алам. «Бер генә җөмләсен дә үзгәртмисез, бер генә геройга да тимисез», – дип, мин аңа түшем белән ятып кагылдырмас идем. Ә пьеса итеп сәхнәгә куйганда, безнең яшь буын тамашачыларын да җәлеп итә торган алымнар куллангач, мин, киресенчә, бик сөенеп ризалаштым.

Сәхнә әсәрен язу бик авыр, – дип ассызыклый Айгөл ханым. – Күз алдына китерегез: 200 битлек повесть һәм сәхнә өчен 25 битлек пьеса язып була. Ләкин 25 битлек пьесаны язу, повесть язуга караганда, бик күп көч түгүне таләп итә. Сәхнә кануннарын белергә кирәк. Драматургия жанры буенча һәр реплика астында синең нindидер фикер ятарга тиеш. Уен хәрәкәтләрен белү, күздә тоту кирәк. Сөйләү генә түгел, хәрәкәт кирәк, режиссерлар да, актерлар да хәрәкәт булуны сорыйлар. Менә шуны тотып тору, чәч үргән кебек, үреп бару зур осталык таләп итә. Драматург исеме белән атыйлар мине, ләкин мин әле үземне драматург булдым, дип әйтмәс идем. Бик зур җаваплылык. Аның өчен еллар һәм тәҗрибә кирәктер. Мин әле иплән кенә өйрәнеп киләм.



*Айгөл Әхмәтгалиева Чаллы театрында «Капка» спектаклендә катнашучы артистлар белән.*

## Яшь буын – бөтенләй башка тамашачы

2020 елдан Чаллы дәүләт татар драма театры яңа бинада эшли башлады. Яңа бинада яңа мөмкинлекләр дә барлыкка килде. Урын җитәрлек. Коворкинг-зона, Кече зал, Яшьләр үзәге бар. Соңгы елларда театрга яшьләр дә бик теләп йөри. Бер килгән тамашачы үзе белән бернichә тамашачы алып килә. Билетлар алына. Еш кына театрның социаль челтәрләрендә «билетлар калмады» дигән язу чыга. Бу театр коллективы өчен - сөенеч, ә тамашачылар өчен - көенеч, дисәң дә була.

бер генә тапкыр күрсәтелә, кабатланмый.

– Хәзер театрга бөтенләй башка тамашачы – күп очракта яшь буын йөри, – ди Айгөл Әхмәтгалиева. – Алар татарча аңлап бетермәсә дә, колакчын (наушниклар) белән тыңлап утырса да, без сөенәбез.

*Бер караганда, фаҗига – татар баласы татарча спектакльне колакчын киеп карый. Икенче яктан, шул рәвешле булса да, ул татар әдәбиятына, татар театрына якыная.*

«Театраль педагогика» проекты кысаларында театрга мәктәп балалары килә, спектакль ка-

рыйлар. Балаларга күренекле татар шәхесләренең язмышы, иҗат үзенчәлекләре театр теле аша җиткерелә. Соңыннан еш кына фикер алышу үткәрелә.

әйтергә теләгән, нигә бу сүзне монда кулланган, нинди мәгънә ята бу сүздә. Артистларыбыз да яшь, режиссер ролен үз өстенә алган кызыбыз да яшь иде, – дип уртаклаша



*«Хәл бу ки... Хәсән Туфан» спектакленнән соң.*

– Мәктәптә, дәрес барышында, Хәсән Туфанның иҗатын өйрәнгәндә аның «Кайсыгызның кулы җылы?» шигырен укырга мөмкиннәр. Ләкин аның язылу тарихы, әсәрнең мәгънәсе нидән гыйбарәт – балалар бу хакта айһай уйланып тора микән? Ә шул ук бала театрга килә, Х. Туфан язмышы турында спектакльне карый һәм шигырьнең җанын аңлый. Шуңа күрә мин бу проектны бик файдалы, кирәкле, дип саныйм. «Хәл бу ки» дигән серияне 2022 елның көзеннән башладык. Фатих Кәримгә, Хәсән Туфанга багышланган спектакльләр күрсәтелде. Өченче серия Һади Такташка багышланыр дип көтелә. Алар безнең репертуарга кергән, даими баралар, – дип аңлата Айгөл ханым.

Перформанслар үткәрү – яңа тәҗрибә туплау, сынап карау, эзләнү. Аның өчен тирән мәгънәле, зәвыклы шигырьләр сайлап алына. Перформанслар Чаллы язучылары Сирень Якупова һәм Лилия Гыйбадуллина әсәрләре буенча әзерләнде.

– Артистларыбыз шигырьләрне яттан өйрәнә. Һәр әсәрне сүтепҗыеп әзерләнәбез: автор нәрсә

Айгөл Әхмәтгалиева. – Лилия Гыйбадуллина иҗаты буенча «Сөрән» дигән перформанста алдан тавыш белән яздырып куйган шигырьләр кулланды. Форматы – артистлар картинадан картинага күчеп йөри. Максаты – тамашачыга шигырь белән генә түгел, картиналар аша да тәэсир итү. Әлеге перформанс өчен рәссам-каллиграф Айзат Минһаҗевның рәсемнәре алынды. Шул ук вакытта бию телен дә кулландык. Лилия Гыйбадуллина шигырьләре Айзат Минһаҗев иҗаты белән туры килде, махсус сайлап куйган кебек, бик уңышлы үрелгән, бер-берсен тулыландыра.

Яшьләр театрга тартыла, яшь артистларыбыз да бар. Сәнгать җитәкчесе сүзләренә таянып әйтә алам: Казан театр училищесы, Алабуга мәдәният-агарту училищесы студентлары арасында безнең театрга килергә теләүчеләр бар. Шөкер, без иплә кенә үсү юлында.

### Язучылар буа буарлык

Бүгенге көндә сәхнәләштерү өчен әсәрләр табу кыен, язучылар аз, дип зарланучылар бар. Ләкин Айгөл Әхмәтгалиева бу фикер белән килешми.

– Язып тәкъдим итүчеләр буа буарлык, әсәрләрне укып барабыз. Режиссерлар таләбе – һәр драма әсәрендә сәнгатьчә бөтенлек, эзлеклелек булу. Сүз боткасы түгел, сәхнә таләпләренә туры килергә тиеш. Кайсы гына гасырда язылса да, хәзер дә актуаль булып калган әсәрләр күп. Камал театрында Ә. Еникинең «Рәшә»се сәхнәгә менде. Кайчан язылган әсәр бит инде ул! Шуннан яшь режиссер бүгенге көнгә аваздаш булган темаларны тартып чыгарган һәм шулхәтле заманча, бүгенге тамашачыга аңлашыла торган, аның авырткан җирен чагылдыра торган спектакль килеп чыккан.

Бездә Фәтхи Бурнашның «Яшь йөрәкләр»е чыкты. Бер гасыр элек язылган бит! Әйтерсең, ул безнең бүгенге көнебез турында сөйли. Гаҗәп хәлләр бар. Сайлап алганда алай ук булыр, дип уйламасак та, сәхнәгә менеп, күпмедер вакыт үткәннән соң, без үзебез дә шаккатып карап торабыз. Нindидер могҗиза. Классик язучы һәм искерми торган темалар – янәшә яши торган атамалар шул.

### «Хәния»не бикләнеп яздым

– Вакыт – иң кыйммәтле, иң җитмәгән әйбер. Иң кызыгы – миндә генә түгел, башка кешегә дә шулайдыр – кайда да булса чиратта торганда вакыт үтми интектерә, килеп терәлгән кебек. Ун минутлык чиратта торганда вакыт үтми, дибез. Нәрсә беләндер мәшгуль булганда ун минут түгел, ун сәгать тә күз ачып йомган арада үтә дә китә, бер нәрсәгә җитешмисең. Бер яктан бәхет инде ул, – ди Айгөл ханым.

- Мин - бик ялкау язучы, – дип бәя бирә ул үзенә. – Язарга бик аз вакыт бирәм, эш арасында гына язам, дисәм, алдамамдыр. Өйгә кайткач, мәсәлән, ашарга пешерәсең, тегесе-монысы... Шулай да, илһам килгән мизгел булса, тиз генә компьютер янына утырам да язам. Рәхәтләнеп, җәелеп, бикләнеп «Хәния»не яздым. Сәбәбе бар иде: май аенда китап чыга, әсәр мартта язылып бетәргә

тиеш. Минем ике ай вакытым бар иде. Вәгъдә бирдем. Биргәч, аны үтәр өчен, башымны күтәрмичә, ул елның кышын күрмичә, көннәр буе яздым.

Башны ял иттерер өчен, бөтен кеше йокларга ятканда, тәрәзәләрдә утлар сүнгәндә, сәгать унберләрдә, чаңгыларны кыстырып, ирем белән урамга чыга идек. Безнең янда гына бик әйбәт мәктәп стадионы бар, бераз арырак китсәң – урман. Урманга барып җитәргә рәт калмаса, мәктәп стадионында чаңгы шуып керә идек. «Хәния» белән шулай бик тыгыз, үземне бәйләп куйгандай эшләгәнемне хәтерлим.

«Туташ»ны да шулай ук вәгъдә биргән вакытка өлгертергә кирәк иде. Күренекле шәхесләргә багышланган әсәрләрне язу – бик җаваплы эш, зур игътибар таләп итә. Китап язганда, С. Гыйззәтуллина-Волжская эзе буйлап, Ижауга, Уфага, Чувашиягә, Татарстанның төрле районнарына бардым. Әгерҗе районы Иж-Бубый авылындагы өйләрне, музейны карап йөрдем. Эзләнүләргә, архивларда утыруга, материалларны өйрәнүгә бик күп вакыт сарыф ителде. Мисал өчен, шул ук Сәхибҗамал соңгы көннәрен үткәргән Чистай психоневрологик интернатына барып кайту өчен генә дә кимендә тулы бер көн кирәк. Барган бер көнеңнән син китапка ике-өч җөмлә кертергә мөмкинсең. Шулай булса да, эзләнү этабы – бик кызыклы, рәхәт вакыт.



Дәрт – ул үз героеңны ярату, аның күңеленә үтеп кереп, «ни өчен, нигә?» дигән сорауларга җавап табарга тырышу, дип саный Айгөл Әхмәтгалиева.

– Мәсәлән, Хәния Фәрхи эзләре буйлап йөргәндә, аның туган авылында булдым. Ул хәзер ташландык авыл, кырыйда тайга урманы күлгә авардай булып басып тора, агач күләгәләре суда йөзә, бәрәңге бакчалары да күлгә терәлеп тора. Бакча янында каен җиләге үсеп утыра. «Без, самавыр кайнаган арада тиз генә чыгып, каен җиләге җыеп керәбез дә чәйгә утырта идек», – дип сөйли Хәниянең сеңелесе. Һәр өйнең капка төбендә шомырт агачы үсә. Монда туган һәр кеше йә шагыйрь, йә җырчы буладыр. Табигать матурлыгы башны әйләндерә торган, аны кәгазьгә төшереп булмый. Һәм шул матурлыктан алган тәэсирләр аша геройга якынаясың. Гомумән, иҗатның кызык, катлаулы, үзе рәхәт, үзе газаплы мизгелләре күп инде.

### Сәер бер гадәт

Айгөл Әхмәтгалиева киносценарист буларак та билгеле. Ул – «Ак чәчәкләр», «Мәхәббәт хакына», «Җылы эзли җаннар», «Синең күзләр», «Кунак ашы кара-каршы» фильмнарының сценарий авторы.

– Минем сәер бер гадәтем бар, – дип елмая ул, – эшли белмим дип тормыйм. Берәр тәкъдим булса, кемнәрдер эшли бит, ә мин эшли алам микән дип тотынам. Ничек килеп чыгар икән, дим дә ризалашам. Бер елны ТНВдан Миләүшә Айтуганова (ул чакта генераль директор урынбасары иде), «Г.Әпсәләмовның “Ак чәчәкләр” романы буенча 10 серияле кино төшермәкче булабыз, сценарий кирәк иде, язарга алынасыңмы?» – дип шалтыратты. Мин әз генә уйланып тордым. Бер дә эшләп караган эш түгел, телевидение өчен сценарий язган юк иде. Ләкин кеше эшләгәнне эшли алырмын әле, дидем дә сценарийга тотындым. Ул шактый уңышлы булды, татар тамашачысы бик яратып карады. Фильмны әзерләгәндә, аның башында да, ахырында да берәр җыр яңгырап торсын иде, дип тәкъдим иттем. Җырның сүзләрен үзем яздым, көй язарга Миләүшә Ләбибовна аны Вил Усмановка бирде. Шул рәвешле җыр барлыкка килде, ул үзе дә, озын гомерле булып, әлегәчә халык телендә.

Шул фильмнан соң үземә дә ышанычым артты. Нурания Җамали – безнең бик талантлы шәхесебез, татар фильмнары белән тамашачыларны «тотып торган» режиссер. Аның тәкъдиме белән башка сценарийлар язылды, «Җылы эзли җаннар» дигән фильм әзерләнде, ул инде яшьләрне җәлеп итте. Максатыбыз да шул иде: яшь геройлар аша татар фильмнарына татар яшьләрен тарту, – дип аңлата Айгөл ханым.

### «Өстәл артына» утырып

Сер түгел, милләттәшләребез арасында татар телен начар белүчеләр, рус сүзләрен кушып, рус теленнән калька (сүзмә-сүз, туры тәрҗемә) ясап сөйләшүчеләр күп. Мәсәлән, «кибеткә сөткә барам» диясе урынга, «сөт артыннан» («за молоком»), дибез. Вата-җимерә, татарча сөйләшүдән оялып, рус телен генә кулланучылар да бар. «Я понимаю татарский, только разговаривать не умею» дигәнне еш ишетергә туры килә. Айгөл Әхмәтгалиева фикеренчә, туган телеңне начар белсәң дә, оялмаска, булдыра алганча аралашырга кирәк. Сөйләм телен үстерү өчен, татарча фильмнар, спектакльләр карарга. Хәтта аңлап бетермәсәң дә, сүзнең яңгырашын ишетәсең, аның мәгънәсенә төшенәсең. Аңлап ук бетермәсәң дә, татарча китаплар укырга була – күз хәтере дигән әйбер бар, укыган саен сүзнең язылышы исеңдә кала, телеңне баетасың.

– Мин Актаныш ягыннан, унберенче классны бетереп, Казанга киткәнче, бер генә дә урыс кешесен күргән, русча сөйләшкәнне

ишеткән кеше түгел. Булса, шул авылга әллә нигә бер чегәннәр әйбер сатарга килгәндә, безгә кереп кунган чакта ишеткән булгандыр, – дип уртаклаша Айгөл ханым. – Безнең проблема, киресенчә, рус



*Оренбургта «Капка» спектакленнән соң.*

телен тиешенчә белмәү иде. Мин Казан дәүләт университетында укыдым һәм хөрмәтле укытучыбыз Сәгадәт Ибраһимовка бик рәхмәтле. Бүгенге сөйләшү аңа дога булып ирешсен. Сәгадәт абый, мисаллар китерә-китерә, безгә калькаларны аңлатты.

Ул әйтә иде: *«Нинди әсәр өстендә эшлисең?” – дип сорыйлар русчадан калька ясап. Кайсы язучы әсәрнең өстенә менеп эшли икән? “Кунаклар өстәл артына утырды”, – дисез. Кайда ул өстәлнең арты, кайда аның алды? Нигә рәхәтләнеп “өстәл янына утырдык”, – дип әйтмисез?».*

Әлбәттә, рус теленең йогынтысы көчле, ләкин үзебездә дә гаеп бар бит. Мәсәлән, кибеткә килеп кергәч, ни өчен әле кибетчегә: «Здравствуйте», – дип дәшәргә? – «Исәнмесез», – дип әйтсәк, нәрсә була? Кайсыдыр бинага керсәк, әле кешенең исем-фамилиясен белмәстән, русча исәнләшәбез. Телефон шалтыраса яисә үзебез шалтыратсак, алабыз да, иң беренче, «здравствуйте», дибез. Әйтерсең, үз телебездә эндәшсәк, авызыбызга кемдер суга. Тамчыдан күл җыела. Менә шундый вак-вак әйберләрдән олы төеннәр барлыкка килә, – ди Айгөл Габдулла кызы.

## Урам теле һәм әдәби тел

– Телнең сафлыгын саклау өчен, хәзер соңга калып бармыйбызмы икән, дигән шик бар, – дип борчыла ул. – «Халык әдәби телне, матур, аһәңле итеп сөйләшкәнне аңламый, халыкка аңлаешлы булсын өчен, аныңча, “урам теле” белән сөйләшегез», – дип, бик үк дөрес булмаган сәясәт алып барылды, минемчә. Ә ни өчен «урам теле» һәм «әдәби тел» дигән аерма яшәп килә? Ни өчен «әдәбият», «мәдәният» дигән төшенчәләр бар? Шул театр сәхнәсен алсаң да, без «сәхнә тамаша залыннан бер баскычка югарырак тора», дип әйтергә яратабыз. Ни өчен, халыкка аңлаешлы булсын дип, түбәнгә төшеп барырга, тел матурлыгын югалтырга тиешбез? Безнең әдәбиятыбыз да юкка чыгачак бит. Мөхәммәт Мәһдиев теле, Әмирхан Еники теле юкка чыгачак.

Мәктәпләргә очрашуларга барасың, татар балаларына алты-җиде сүздән торган җөмлә әйтсәң, аңламыйча, күзләрен түгәрәкләндереп карап торалар. Ике сүздән торган җөмлә белән сөйләшәләр. «Исемең ничек? Ничәнче класста укыйсың?» кебек гади сорауларга гына җавап бирә алалар. Әйтергә кирәк, бу бит трагедия, – ди Айгөл Әхмәтгалиева.

## Бөтен кеше җаваплы

Бала туган телен белсен өчен, беренче чиратта, ата-ана җаваплы, икенче чиратта, мәгариф системасы, мәктәпләр. Бу аерым бер тема булып, аерым сөйләшү таләп итә, дип саный Айгөл ханым.

– Дәүләт имтиханнарының рус телендә булуы, фәннәрнең рус телендә укытылуы, имтиханнар белән бәйле рәвештә ата-ананың куркуы – болар бөтенесе, бер йомгак булып, әлегәчә чуарланганнан-чуарлана бара торган проблема. Җитди аерым сөйләшү һәм зур даирәләрдә сөйләшүне таләп итә. Әлбәттә, бу мәсьәләне чишеп була. Моның өчен ата-аналарның үз балаларының киләчәге, әманәт булган тел турында уйлануы һәм аларның мәгариф системасы җитәкчеләре белән дискуссиягә әзер булуы кирәк. Үз таләпләрен әйтеп, дәлилләр китерә белүе. Гомумән, бу проблеманың җитдилеген аңлап, чаң сугу. Бөтен кеше җаваплы, – дип ассызыклый ул. – Әдәбият, мәдәният өлкәсендә эшләүчеләрдә дә җаваплылык зур. Язучылык каләме дә – миссия бит инде ул, «әкият яздым да гонорар алдым, максатым шул», дигән сүз түгел.

*Аллаһы Тәгалә язучылык миссиясе биргән икән, аны үтәү бурычы шушы кеше җилкәсенә төшә, дигән сүз. Шигырь, драма әсәре, поэма булсынмы – ул көндәлек ихтыяҗ турында түгел, милли аң турында.*

Айгөл Габдулла кызы күзаллавынча, татар дигән халык үзенең бай тарихлы икәнен, беренчедән, үзе белергә, икенчедән, яңа буынга җиткерергә тиеш.

– Безнең бурыч – үткән тарих белән мактанып утырмыйча, бүген дә шул ук татарның

дәвамчылары икәнебезне онытмау. Бабаларыбызның телен, гореф-гадәтләрен бүгенгәчә алып килгән буын без. Ә ни өчен без үткән белән генә мактанырга тиеш? Үзебезнең мактана торган әйберебез юкмы? Шундый сорауларны күтәрергә кирәк, дип әйтәбез дә, менә хәзер үзем дә куркып куям. Кулыма каләм тоткан кеше буларак, әлбәттә, минем дә уемда бар андый сораулар, – була. Ләкин шуның янәшәсендә камил итеп татарча сөйләш. Синең авызыңа беркем дә сукмый, нинди телдә сөйләшсәң дә. Үз телеңне белмәү оят түгел микән, дип уйлыйм мин. Бәлки, примитив фикер йөртәмдер, ләкин русча сөйләшмәгән русны яисә немецча сөйләшмәгән немецны күз алдына китереп буламы? Аларның үз телләрендә сөйләшүе гайре табигый булып күренми, шулай бит. Ә



*Актанышта, сәләтле балалар өчен гимназиядә очрашу*

дип ачыктан-ачык таный язучы. – Чынлап та, мин аны укучыга барып җитәрлек итеп, шул дәрәҗәдә күтәрә алам микән, дип торып-торып уйланам. Бу бит кулыңа каләм алдың да туп-туры лозунг формасында яздың, дигән сүз түгел. Шигырьме, хикәяме, повестьмы, балалар өчен кыска гына әсәр булсынмы – укучыга сәнгатьчә алымнар белән баетып бирә белү дә кирәк. Менә шуңа без ни дәрәҗәдә ирешәбез икән? Бу - бик тирән, фәлсәфи сораулар, ләкин алар һәркемне борчырга тиеш.

*«Без авылдан чыктык, русча белмәдек, кыен булды», – дип, үз балаларын югарырак дәрәҗәләрдә күрәсе килеп, әти-әниләр балаларын рус телендә укыта.* Ләкин бит бишлелек итеп рус телен дә, татар телен дә өйрәтеп була. Өйрән, бер кеше дә каршы килми, теләсәң – әллә ничә тел өйрәнеп татар баласы үз телен белми икән, без аңа түгел, киресенчә, саф, камил сөйләшкән балага шаккатып карыйбыз. «Карале, ничек матур итеп татарча сөйләшә!» – дибез.

### «Китап алып акча әрәм иткәнче, колбаса алыр идем... »

Бу мәсьәләнең икенче ягы да бар, дип билгели Айгөл Әхмәтгалиева һәм үзе белән булган бер очракны мисалга китерә.

– Бервакыт Казаннан кайтып килә, юлымда танышым очрады. Кайдан кайтасың, нәрсә алдың – гадәти сүз алышу. Мин сумканы ачып күрсәттем. Үземнең балаларым үскән иде, сеңелемнең балаларына китаплар алган идем. «Менә китаплар алдым», – дип күрсәтәм. Танышым әйтә: «Мин бала-чагага китап алып акча әрәм иткәнче, фәлән кило колбаса алыр идем». Бу чагыштыру терелэй суйган кебек булды. Еш кына, кызганычка, матди байлык, ашау дигән әйберне тәлинкәгә салып куялар да, рухи байлык күп кешеләр өчен кирәксез булып күренә. Иң кызыгы: балалар өчен юньле китап юк, дип әйтергә телиләр бит әле. Нишләп булмасын? Шәүкәт Галиев, Зәкия Туфайлова, Әминә Бикчәнтаева, Ләбибә Ихсанова, Бари Рәхмәт, Роберт Миңнуллин, Факил Сафин, Рәшит Бәшәр китапларын карагыз. Укып карамаган килеш, «балалар өчен китап юк», дип тамга сугу дөрес түгел. Һич тә килешәсем килми бу фикер белән. Мондый сүзне ишетсәм, кызыл төс күргән күркә сыман кабарына башлыйм.

Үз балаларың белән мактанырга ярамаганын беләм, дөнья бит бу, кемнең нәрсә күрсәтәсен белеп булмый. Минем ике балам да башта рус мәктәбендә укыды, аннан татар гимназиясенә күчтеләр. Безнең өйдә «балалар татар телен онытмас микән?» дигән сорауның гомумән беркайчан да туганы булмады. Андый проблеманың ни сәбәпле килеп туганын анализлап, кемнедер гаепләп әйтәсем дә килми, белеп тә бетермим. Балаларым ничә тел өйрәнделәр, ләкин һаман актанышча «нәмә-нәмәкәй», дип авыз тутырып сөйләшәләр. Әлегәчә балаларым белән иң зур мактанычым шул, – ди Айгөл ханым.

### Бездә кайбер татар балалары татарча сөйләшкәнне аңламый

– Ни кызганыч, милли үзаң дигән төшенчәдән без елдан-ел ерагая барабыз. Читтә булган татарлар белән аралашкач, аңлыйсың: аларда милли үзаң көчлерәк, – дип билгели Айгөл Әхмәтгалиева. – Без бер елны кызым янына кунакка бардык, Алманиягә. Кызым бер татар гаиләсенә кунакка алып барды. Бу гаилә озак еллар бирегә яши, кызлары Азизә шунда туган, ул алман балалар бакчасына йөри, анда бит инде берәү дә татарча сөйләшми. Шул кыз, ялгышмасам, алты яшь иде аңа, бер генә рус сүзе кыстырмыйча, шулхәтле

камил итеп, чип-чиста татарча сөйләшә.

Сәбәбе нидә дисез? Әнисе Казанга кайткан саен Татарстан китап нәшриятында чыккан балалар китапларын алып кайта. Күз явын алырлык булып, китап киштәләрендә татар китаплары балкып утыра. Элеккеләр дә, бүгенге язучыларныкы да, әкиятләр дә – нәрсә генә юк! Баланы татар китаплары белән тәрбияли, аңа татарча укый – ана кеше үз җилкәсенә шундый йөкне алган. «Минем балаларым бу чит илдә, чит халык арасында яшәп, үз телен онытмасын», дип яши. Гаиләдә әниләре «ана теле» дигән төшенчәгә менә шундый мөнәсәбәттә, ана телен югал-




тырга ярамый дигәнне аңлый. Мин бик сокланып кайткан идем. Алар үзләре дә көлделәр инде. «Без Казанга кайтабыз, андагы туганнарыбызның шундый ук татар балалары безнең Азизә сөйләгәнне аңлап бетермиләр, аларга русча әйтергә кирәк», – дип сөйләделәр.

### Һәр милләткә үз теле Аллаһы Тәгаләдән әманәт итеп бирелгән

Әлеге күренешләр, бер яктан, аптырауга сала, икенче яктан, шомландырып та куя, – ди Айгөл ханым. – Өченче яктан, бөтен җәмгыятьне дер селкетеп әйтәсе дә килә: «Без кая барабыз?». Һәр милләткә, һәр кавемгә үз теле Аллаһы Тәгаләдән әманәт итеп бирелгән. Һәм, әманәт булгач, аны саклау, киләсе буынга тапшыру бурычы куелган. Мөгаен, гаилә, мәгариф системасы, җитәкчеләр, гомумән, бөтен кеше кулга кул тотынып эшләсә, телне саклау мәсьәләсе кутәрелмәс иде, андый проблема бөтенләй булмас иде. Бәлки, бу утопиядер...

### Өйдә иң зур байлык – китап

– Мин укымыйча тора алмыйм, – ди Айгөл Габдулла кызы. – Күреп торасың бит, мондагы китапларны, – дип ул театр бүлмәсендәге китап тулы шкафларга күрсәтә. – «Казан утлары» – өстәл журналы. Артка калып барам, әле күзгә айларны гына укыдым. Иң соңгы укыганым – Зөлфәт Хәкимнең «Бер сәгатьтә ничә мизгел бар» дигән романы. Лилия Гыйбадуллинаның Гали Рәхим турындагы поэмасын яңа гына укып чыктым.

Өйдә дә иң зур байлык – китап. Әти-әни дә шулай булды. Шкаф тулы китап иде.

Кайда гына барсалар да, өйгә китап алып кайталар. Авыл кешеләре китапханәдә мәгълүмат таба алмаса, безнең әнигә (әнинең исеме Гөлзәлифә) киләләр.

*Әти-әнием – бүген дә минем иң беренче укучыларым, минем китапларымны күтәп торучы, өф-өфләп җыеп баручылар. Алар – минем бәләкәй генә уңышымны да иң зур итеп кабул итә, сөенә белүчеләр.*

«Карап чык әле», – дип, язганнарымны иң беренче әнигә җибәрәм. Әнием – башта китапханәче, аннан укытучы булып эшләгән кеше. Без барыбыз да китап белән “чирле”. Әти-әнием дә – укытучы, ике сеңелем дә педагогик белем алдылар, уртанчы сеңелем бүгенгәчә укытучы булып эшли.

### Тел матурлыгына өйрәним, дисәң...

Әдәбиятны югары һәм түбән сыйфатлы булуына сылтап калдыру белән килешми Айгөл Әхмәтгалиева.

– Кеше алдында максат, бурыч бар икән, аңа ирешү өчен, сайлау мөмкинлеге дә бар, – дип ассызыклый ул. – Тел матурлыгына өйрәним, дисәң, безнең таянып җирлегебез бар. – Үзем гомер бакый Әмирхан Еники иҗатына гашыйк булдым. Бәләкәй чактан ук, мәктәп елларыннан ук. Андагы моң аңлап бетерә торган түгел. Бәләкәй генә, бөдрә-бөдрә җөмләләргә шулхәтле матурлык, әйтеп бетергесез тел аһәңе сыйган. Тел ягыннан Хәсән Сарьян әсәрләре искиткеч матур, Фатих Хөснинең повестьлары, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев әсәрләре...

Хәзерге заман авторларына килгәндә, аерып әйтергә кыен. Озак еллар «Мәйдан», «Казан утлары» журналларында эшләдем, нигездә – хәзерге авторлар белән. Редактор буларак укыганда, салкын акыл белән укыйсың, бу бик нык комачаулый. М.Кәбиров, Р.Габделхакова, З.Хәким әсәрләрен тәкъдим итеп була. Санап китсәң, күп инде, кайберәүләр «мине әйтмәде», дип үпкәләргә мөмкин...








### Татар әдәбияты әле көчен җуймаган

Чит төбәкләр, дигәндә, Башкортостан Республикасы белән тыгыз элемтәдә эшлибез. «Мәйдан», «Казан утлары» журналларында эшләгәндә, мин Башкортостандагы татар язучылары белән очрашуларда бик яратып катнаштым. Анда «Тулпар» журналы чыга, проза бүлеген бик талантлы шагыйрә, язучы Дилбәр Булатова җитәкли. Ул безгә Башкортостандагы татар язучыларының әсәрләрен җибәреп торды. Шул сәбәпле әлеге төбәк язучыларының иҗат җимешләре әледән-әле дөнья күрде. Беренче элемтәләр шулай башланды.

Икенчесе – «Хәния» китабы басылып чыкканнан соң. Хәния Фәрхи тумышы белән Башкортостаннан булгач, аның иҗаты белән горурланучылар бик күп. Китап чыкканнан соң, алар белән очрашулар шактый булды. Башкортостанны аркылыга-буйга гизеп чыктык. Андагы авылларда булып, шаккатып кайткан идем. «Бүген китап укымыйлар», дигән сүзнең бөтенләй ялган икәнлегенә инанып кайттым. Кайда гына булсак та, татар китапларын укырга, яңа чыккан әсәрләрне алырга дип атлыгып торалар. Әлбәттә, урта буын кешеләре. Менә бит әле укучылар бар, татар әдәбияты әле көчен җуймаган, гомере бар икән, дип сөенәсең. Чөнки еш кына аянычлы уйлар да килә.

*«Яшь буын бөтенләй татар теленнән аерылса, берничә елдан соң безнең язганнарыбыз, татар җыры, татар китабы кемгә кирәк булыр?» дигән аянычлы уйлар да килә кайчак.*

Төркиядә яшәүче төрек кызы белән аралашабыз, ул университетта укыта, бик күп башкорт язучыларын төрек теленә тәрҗемә иткән. Аның бер студенты минем «Күз нурларым» пьесасын төрекчәгә тәрҗемә иткән, – ди Айгөл Әхмәтгалиева. – Төркиядә Аяз Гыйләҗевның әсәрләре төрек телендә басылып чыкты. Хәзер Казанда яшәүче төрек галиме Фатих Кутлу хезмәте нәтиҗәсендә күптән түгел Төркиядә татар шагыйрьләренең шигырьләре җыентык булып басылып чыкты, татар хикәяләреннән тупланган китап дөнья күрде. Минем хикәяләрем, тәрҗемә ителеп, шул җыентыкларда урын алган. Әлфия Ситдыйкованың китабы төрек теленә тәрҗемә ителде. Әдәби мохитта татар әдәбиятының бар икәнен башка халыкларга җиткерү, таныту юнәлешендә хәрәкәт бар.

Китап сөючеләр, Айгөл Әхмәтгалиеваны социаль челтәрләрдә табып, аңа язалар, китапларын соратып алалар.

– «Хәния» китабын Самарга почта аша бик күп сорап алдылар, байтак кешегә җибәрдем. «Ак читек», «Кичке таң» китапларын Самар, Ульяновск калаларыннан күпләр соратып алды, – ди ул. – Томск, Омск, Ульяновск өлкәләренә, Пермь, Екатеринбург, Санкт-Петербург шәһәрләренә китаплар җибәрдем. Китап сорап, Россиянең барлык төбәкләреннән мөраҗәгать итәләр, кирәксенгән кеше таба.

Журнал март санында чыгасын әйтеп, хатын-кызны нәрсә бәхетле итә, дигән сорауны да бирдем Айгөл Габдулла кызына.

– Хатын-кызны җан тынычлыгы бәхетле итәдер. Аңа бөтен әйбер кирәк, барысын да сыйдырып була: үзең, якыннарың сәламәт булу, эти-әниең, балаларың кайгы күрсәтмәү, өеңдә дә, эшеңдә дә тигезлек, гармония булу. Балаларның шәхес буларак үсүен күрү, аларның кешеләргә, җәмгыятькә кирәкле булуын тою. Дөньяларның тыныч, имин булуы, – дип җавап бирде ул.

Фотолар Айгөл Әхмәтгалиеваның архивыннан.



# СОХРАНИМ ВМЕСТЕ ДУХОВНОЕ БОГАТСТВО НАРОДА!

***Мечети во все времена являлись духовными центрами для мусульман. И речь не только об Ибадате (богослужении). Часто они выполняли еще и образовательную функцию, так как многие из них обладали библиотеками и хранилищами исламской литературы, в которых среди старинных книг и сегодня можно найти настоящие фолианты.***

***Библиотекарь Рустам Файзуллов***

Люди всегда понимали и ценили роль библиотек, так как именно книги являются показателем развития народа, в них накоплено его духовное богатство. Пожалуй, самый яркий пример, который мы можем здесь привести, это библиотека иранского города Мешхед, где в 1923 году была обнаружена рукопись Ибн-Фадлана о путешествии в Волжскую Булгарию и принятии в 922 году жителями этого древнего государства ислама. Эти события были описаны и в других источниках, тем не менее найденный документ еще раз сумел подтвердить эти сведения.

Для самарских мусульман духовно-просветительским центром можно назвать и Историческую мечеть. В самом начале ее реконструкции в 2007 году было принято решение о создании в ней библиотеки. Сегодня здесь собраны сотни книг по исламской тематике: Кораны, тафсиры, сборники хадисов, жизнеописания пророков, история ислама, фикхи (религиозно-правовое учение), учебники по арабскому языку. Также здесь представлены дореволюционные книги на арабском алфавите, документы, открытки, фотографии, старинные газеты и журналы, в т. ч. выходивший в Самаре экономический журнал «Икътисад». Итоги этой большой изыскательской и научно-исследовательской работы должны послужить созданию условий для учебы имамам, улемам (мусульманским богословам), шакирдам и ученым, поможет возродить и сохранить духовное богатство нации. Ведь при переходе мусульман с арабской графики на латинский алфавит в 1929 году, а затем на кириллицу в 1936 году была утеряна связь поколений. Наша задача – восстановить ее. Наряду со сбором современных религиозных изданий ведется работа по поиску дореволюционных книг и рукописей на арабском и татарском языках и их последующая реставрация. Многие книги лишены своих обложек и вложены в обложки советских учебников, так как в



свое время они были под запретом. Это – отголосок трагических событий нашей советской истории, кода религиозные издания считались вне закона.

После революции 1905 года, когда в стране начались первые проблески свободы слова и печати, появилось большое количество наименований книг, газет и журналов по религиозной и светской тематикам на татарском, арабском и персидском языках. Кроме типографских изданий татары пользовались и старыми рукописными источниками. В городах и татарских селах при мечетях шло обучение детей, работали медресе. Татары и башкиры обучались в Бухаре, Турции, Египте, в Западной Европе. Всё это способствовало росту грамотности. По данным дореволюционной статистики, татары считались самым грамотным народом в своей языковой сфере. В городах открывались татарско-русские школы. В мусульманских медресе преподавались естественно-научные предметы. В Самаре при Исторической мечети, наряду с медресе, также действовала татарско-русская школа.

В настоящее время составляются книжные каталоги, переводятся на русский и современный татарский языки названия и титульные листы дореволюционных книг, ставятся штемпели и присваиваются номера. Не секрет, что старинные книги и рукописи часто хранятся в неотапливаемых сырых помещениях и теряют свой вид. Некоторые старые книги приходится спасать от плесени и грибков. Да и должной общественной пользы, находясь дома, они не приносят. Поэтому мы считаем, что им место в библиотеке Самарской Исторической мечети. Сегодня здесь ведется работа по оснащению новой библиотечной мебелью для книг, газет и журналов, которых со временем, мы надеемся, будет значительно больше. Ведь библиотеку могут пополнить для общего пользования и ради довольства Всевышнего Аллаха все желающие. Возродить из небытия старые фолианты и сохранить их в надлежащем виде для наших потомков – задача общая. Будем рады, если вы поделитесь с нашей библиотекой имеющимися у вас старинными книгами, журналами, рукописями, документами, дореволюционными открытками, фотографиями, фотопленками и негативами. Всё это можно принести в Историческую мечеть по адресу: г. Самара, ул. Алексея Толстого, д. 61, где документы будут отсканированы. В свою очередь, в честь наших щедрых дарителей мы готовы организовать отдельные экспозиции с указанием их имен и фамилий.

Дополнительно о работе нашей библиотеки вы можете прочитать на сайте *www.tarihi-mechet.ru* и в социальных сетях.











# «Серебряные булгары» и хан Котраг

## Кому и за что поставили памятник в Ширяеве?

***Случилось это 12 января сего года – скульптуру установили на средства и по инициативе культурно-исторического фонда «Булгарское наследие». Хотя от самого хана Котрага в истории фактически осталась всего одна фраза в «Хронографии» Феофана Исповедника: «Котраг, перешедший за Танаис, поселился насупротив старшего брата». Причем не факт, что это имя не образовано «искусственно-фольклорно» от названия племени – кутригуры. Так чем же знаменит этот человек и за что ему спустя полторы тысячи лет поставлен памятник?***

*Дмитрий ГРЕКОВ*



### А может быть, болгары...

Историки до сих пор спорят о происхождении древних болгар (или булгар): по одним теориям, их предки – тюрки, по другим – иранцы, по третьим – гунны (которые сами тоже – не пойми кто). Впервые «вулгары» были упомянуты в 354 году в анонимном латинском хронографе среди народов, обитающих между Черным и Каспийским морями. Затем они появились на Дунае и в 479 году заключили союз с Византией: «Два Теодориха снова приводили в смятение дела ромеев и опустошали города близ Фракии, вынудив Зенона в первый раз склониться к союзу с так называемыми булгарами» («Хроника» Иоанна Антиохийского).

В 502 году булгары совершают набег на Фракию, а в 530 году Марцеллин Комит пишет об их поражении от византийцев. Вскоре булгары стали нападать на империю в союзе со славянскими племенами. В 539—540 годах кочевники проводят рейды по Фракии к эгейскому побережью и по Иллирии до Адриатического моря. В это же время значительное число их поступает на службу к императору. Например, в 537 году отряд булгар принимает участие в оказании помощи византийскому гарнизону, осажденному готами в Риме.

В те времена булгары делились на два больших племени – утигуры и кутригуры (позже к ним прибавились еще и оногуры). Около 558 года кутригуры под предводительством своего вождя Заберганa вторгаются во Фракию и Македонию, подходят к стенам самого Константинополя.

И только ценой больших усилий византийцам удается отбросить их назад. Причиной ухода булгар служат известия о появлении к востоку от Дона неизвестной воинственной орды. Это были авары, возглавляемые каганом Баяном. Первыми подвергаются нападению утигуры (560 год), затем авары пересекают Дон и вторгаются в земли кутригуров. Хан Заберган становится вассалом кагана Баяна.

Затем появляются новые завоеватели – около 566 года передовые отряды тюрков достигают берегов Черного моря в районе устья Кубани. Утигуры признали над собой сюзеренитет правителя западной части Тюркского каганата Истеми и уже в составе его войска участвовали в захвате древней крепости Боспор на берегу Керченского пролива, а в 581 году появились под стенами Херсонеса.

### Кубрат и сыновья

Где-то в 620-х годах некий Кубрат (Кробат, Курбат, Курт, Коврат, Кроват, Хубраат, Худбадр или Кетрадес), племянник вождя племени оногуров Орхана (Органа, Бу-Юргана или Куернака), оказался в Константинополе в числе большого посольства (во главе с его дядей) и был крещен. Он остался при дворе и получил воспитание, а император Ираклий I даже даровал ему титул патрикия (знатного придворного).

Следующее появление Кубрата в истории – уже на родине, среди булгар. В 632–640 годах он добивается независимости от Аварского каганата и объединяет утигуров, кутригуров и оногуров в союз, получивший название Великая Болгария (или Булгария).



*Личная монограмма хана Кубрата*

Более о жизни и деятельности хана Кубрата мы ничего не знаем – разве что до конца своих дней ему как-то удавалось отбиваться от натиска стремившихся в междуречье Дона и Днепра, а также на Северный Кавказ (примерное место существования Великой Болгарии) хазаров. Куда больше известно о его сыновьях, между которыми, согласно традициям, была разделена власть, имущество и народ булгар. Сыновей было пятеро, и «каждый пошел своим путем».

Старший Батбаян (Бат Баян, Баян, Боян, Безмер) остался на Дону и подчинился хазарам: «соблюдая завещание отца поныне остался в земле своих предков... Хазары, великий народ,... овладел всею Запонтийскою Болгариею до самого Понта, и сделавши данником старшего брата Ватвайя, начальника первой Болгарии, поныне получает от него подати» (Феофан Исповедник). Этот народ, названный «черными булгарами», упоминается в Причерноморье источниками до X века.

Третий брат Аспарух эмигрировал с утигурами на Дунай и стал там основателем Болгарского ханства – прямого предка нынешней Болгарии.

Четвертый брат Кувер (или Кубер), спасаясь от власти хазар, ушел в Паннонию, а оттуда – в Македонию, где он и его люди стали данниками императора Византии, смешавшись с местным населением.

Пятый брат Альцек совершил самое длинное и удивительное путешествие – он дошел до Италии, где поступил на службу к королю лангобардов, поселившему болгар в княжестве Беневенто, в центре Апеннинского полуострова, где их потомки проживают до сих пор, полностью ассимилированные, но «хранящие смутные предания старины».

## Выбирая свободу

Котраг был вторым сыном Кубрата, и ему досталась власть над племенем кутригуров, или, как они стали весьма скоро называться, «серебряными болгарами». Или попросту «белыми» (ак булгар) – скорее всего, это прозвище появилось именно тогда, когда Котраг «перешедший за Танаис, поселился насупротив старшего брата», отделившись от «черных булгар». Переселенцы двинулись из Приазовья в район слияния рек Волги и Камы, где постепенно подчинили себе местные финно-угорские и тюркские племена – баладжар, барсил, савир, эсегелей, билер и пр.

Так и появился сначала племенной союз, а потом и государство, называвшееся историками Серебряной, Волжской или Волжско-Камской Булгарией. Правители булгар, носившие титул йылтывар, постепенно подчинили своей власти и соседние народы Поволжья – буртасов, мурому и пр.

Но из-за ухода в «лесную глушь», недоступную взорам западных и восточных летописцев, первые достоверные сведения о Волжской Булгарии появляются лишь в X веке, когда туда прибыло посольство из Багдада, чтобы помочь переходу населения в ислам – об этом читатели журнала уже знают из статьи «Как булгары ислам принимали», опубликованной в одном из предыдущих номеров.



*Реконструкция жилища древних булгар*

Все это случилось уже через 300 лет после хана Котрага – но именно он основал государство, преемником исторических традиций которого является нынешний Татарстан. И потому навсегда остался в истории...



# БОРЫНГЫ БОЛГАРЛАР – ДӨНЬЯ КҮЛӘМЕНДӘ МӘГЪРИФӘТЛЕ БУЛЫП ТАНЫЛГАН ХАЛЫК

***Болгарлар фән һәм мәгърифәт өлкәсендә югары үсеш алган һәм галимнәре фәннең төрле тармакларында ачышлар ясаган өчен, аларның илен «Светочь Востока», «Царство разума», «Золотой трон Востока», дип атаганнар.***

***Фәрид ШИРИЯЗДАНОВ***

Тик шулай да, әле утыз-кырык еллар элек тә мондый хәбәрләр уйдырмалар, дип кабул ителә иде. Чөнки үз дәүләтчелеген югалткач, татар-болгар тарихы озак еллар басым астында булды. Шуңа да безне Чыңгыз хан гаскәрләре белән килгән, түбән культуралы дала халыкларының дәвамчылары, дип санап килделәр.

Кинофильмнарда, әдәби әсәрләрдә, тарих дәреслекләрендә дә моны күреп, ишетеп үскәнгә, чынбарлык тарихыбыз белән кызыксынучылар да хәзер инде азчылык санда. Бигрәк тә Татарстаннан читтәге төбәкләрдә.

Туган телебезнең югалуы, халыкның милли үзаңы зәгыйфьләнүе турында хәзер күп сөйләнә. Тик үз халкының данлыклы тарихын белмичә, башына сеңгән ялганнар тәэсирендә яши икән – ул кешедә туган теленә, үз милләтенә хөрмәт беркайчан да уянмаячак.

Чынбарлык тарихыбызны ачыклау юлында хәзер күп фәнни хезмәтләр языла, зур ачышлар ясала. Ни кызганыч, тик алар халыкка гына барып җитә алмыйлар.

Бай һәм тирән тарихыбызны яңабаштан үзләштерү – ул шактый кыен һәм катлаулы эш. Чөнки болгар-татар тарихы әкияти заманнарга, кешелек яралган чорларга ук барып тоташа.

Мәсәлән, тарих галиме Фәрди улы Рафаэль Мөхәметдинов үзенең «Тюрки в истории мировой цивилизации» исемле хезмәтендә болгар-татарларның тирән тарихын, төрки телләрнең төзелешен өйрәнүгә таянып, фән нигезендә ачыклый.

Лингвистик анализ нәтиҗәсендә ул шумер, этрусклар һәм Америка индеецларының тел төзелеше аерылгысыз рәвештә төрки халыклар теле белән бәйләнгән булуын да исбатлый.

Ул әле Египет, Грек, Рим, Гарәп, Француз цивилизацияләре дәверендә яшәгән халыкларның телләре дә төркиләрнең тел системасына ияргән икәнен ачыклый. Менә нинди тирән икән бит безнең борынгы тарихыбыз!

Ата-бабаларыбыз гасырлар дәвамында басым астында яшәсәләр дә, халкыбыздагы гыйлемгә, мәгърифәткә карата хөрмәт сүрелмәгән, гел сакланып килгән.

Бу хәл көндәлек тормышыбызда да ачык күренә иде. Мәсәлән, язулы кәгазьләрне кадерсезләгән

вакытта әби-бабайлар: «Анда күз нурлары иңгән, кыйммәтле фикерләр язылган», – дип орышыналар иде. Язулы әйбергә карата хөрмәт аларның каннарына сеңгән булуын аңлата түгелме соң бу?!

Төрки татар-болгарлардагы борынгыдан килгән «Таш язуының» (руналарның) халык арасында киң таралган булганлыгы да – хәзер инде фәнни расланган факт.

Һәр җирдә очраган язулар төркиләрне туганнан алып, каберенә кадәр озата барганнар. Ул язулар сугышчылар шлемында, кылычында, беләзекләрдә, бөтиләрдә, кабер ташларында, савыт-сабада һәм тормышта кулланыла торган башка әйберләрдә, биналарда, ишек һәм капка башларында да язылган.

Бу язуларны, яуда җиңү, тормышта уңышлар һәм исәнлек теләп, җен-перилардән, сихердән саклау, уңыш алу, мал үрчеме артуын һәм башка теләкләрен язганнар. Уку-язуны белү иң мактаулы гамәлләрдән саналган.

Бу борынгы язуның барлыкка килүе шулай ук кешелек яралган чорларга барып тоташа. Элгәредән һәр нәселнең, гаиләнең үз тамгасы аның кашыгыннан алып, сабанына кадәр куелган. Шулай ук аның малына, товарларына, җир ызанына һәм башка әйберләргә куелган. Мондый тамганы бозу кеше үтерүгә тиң җинаять булып саналган.

Авазларны һәм сүзләрне символлар (руналар) белән язарга өйрәнгәч, кешеләрнең аң дәрәҗәсе, культурасы һәм тормышка карашы үсеш алып, фикерләү офыгы киңәйгән. Бу ачыш гыйлемгә дә киң юл ачкан һәм, кеше хәтерен көчәйтеп, төрле вакыйгаларны теркәп, бай тарихны теркәп барырга да мөмкинлек биргән.

Руналар халыкны билгесезлектән, исемсезлектән һәм чиксезлектән коткарган. Тора-бара алар төрле башка халыкларның да язу графикасы нигезенә ята. Шул исәптән латиница, кириллица кебек язуларның һәм борынгы грек, хәтта финикия язулары нигезендә дә руналар тәэсире сизелә.



Таш язуы тора-бара башка халыкларда да киң таралгач, аны руналар, дип атап йөртәләр. Скандинавлар телендә ул «Сер», «Серле» дигән мәгънәне аңлата.

Төркиләр руналарда бөек көч һәм тирән серләр тупланган, дип уйлаганнар. Алар – күрелмәгәнне күрергә, ишетелмәгәнне ишетергә мөмкинлек бирүче серле билгеләр, дип санаганнар.

Урта гасырларда христиан дин әһелләре руналар куллануны тыялар. Тик 1908 елда гына немец галиме Гвидо фон Листның «Руналар сере» дигән китабы басыла. Шуннан соң алар белән мавыгу дөньяга киң тарала.

«Руналар табигатьтәге яшерен көчләр белән идарә итәргә мөкинлек бирә», – дип исәпләүчеләр әле үзләренең яшерен оешмаларын да төзиләр. Руналарны белем туплауда, шулай ук күрәзәчелектә һәм галәм серләренә үтеп керү өчен дә кулланa башлыйлар.

Кытайларның иероглифлары һәм уйгурларның алфавиты да руналарга нигезләнә. Ә гарәп алфавиты, үз чиратында, уйгур алфавиты нигезендә барлыкка килә.

Төркиләр руналарның төрле серләргә, сихри көчкә ия булуына һәм кеше җанына көчле тәэсир итә алуына ышанганнар. Моны алар кеше тәрбияләгәндә һәм милләтне берләштерүдә оста кулланганнар.

Унтугызынчы гасыр ахырында телләр белгече, Дания галиме Петер Томсен, Россия далаларындагы курганнарда табылган руна язуларын өйрәнеп, утыз сигез хәрефтән торган төрки алфавиты төзи.

Нәтиҗәдә борынгы төркиләрнең меңнәрчә еллар буена яшеренеп яткан тарих серләре ачыклана. Күлтиген, Тоньякук, Билге кебек төрки каганнарының серләрен саклаган борынгы ташлар да телгә киләләр.

Танылган тюрколог, академик В. Радлов беренче тапкыр ташларга язылган орхоно-енисей язуларын укый һәм аларны бастырып чыгара.

Ниһаять, руна символлары аша борынгы төркиләрнең тел төзелешен, тарихи үсеш юлын һәм төрки сүзләрнең килеп чыгышын өйрәнү фәнни нигезгә салына.

Мәсәлән, татар сүзе кешелек тарихында барлыкка килгән иң борынгы сүзләрнең берсе булса да, аны ничек кенә мәсхәрләп аңлатырга тырышмадылар: «кыргый кеше», «тәмуг кешесе» һәм башкалар. Боларны бит әле дәреслекләргә керттеләр!

Ә хакыйкатьтә руна символлары буенча татар сүзе өч төшенчәдән тора:

Т – корал, АТ – ат һәм АР – күк кешесе (сын неба). Бу ат өстендәге кораллы күк кешесе мәгънәсендә.

Тарихи чыганакларда японнар тимер эретү мичен – татара (татар

миче), дип атаганнар. Ә борынгы сәяхәтче Марко Поло, татар телен белүе белән горурланып, «Татар» сүзенең дөнья күләмендә нинди зур әһәмияткә һәм хөрмәткә ия булуын исбатлап, болай дигән:

«В этом слове заключён магический смысл. В нём зашифрована вся сущность народа, а также история происхождения не только татар, но и всех тюркских народов!»

Чынлап та, революциягә кадәр үзбәкләр, казахлар, кыргызлар, төрекмәннәр, азәрбайҗаннар һәм башка Кавказ төркиләрен татарлар, дип атаганнар бит.

Төрки халыкларның барысы да, руналарны изгеләштереп, аларны Күктән иңдерелгән серле билгеләр, дип санаганнар. Моның өстенә, Коръәндә (шулай ук башка диннәрнең изге язмаларында):

«Аллаһы Тәгалә Җир белән Күкне һәм кешене яралтканга кадәр үк, иң элек, «Сүз»не яралткан. Ул кеше затына бирелгән «Сүз» белән аның кодрәтен билгеләгән. Шуның белән Аллаһы Тәгалә кешене үзенең бөтен җан иягәреннән дә өстен итеп яралтканын белдергән!» – диелгән.

Тормыш күрсәткәнчә, һәр сүздә, һәр хәрефтә тупланган кодрәтнең серләре аңлап бетергесез. Моның хакында әкиятләрдә, риваятьләрдә, мәкальләрдә, әйтемнәрдә һәм фәнни хезмәтләрдә дә күп әйтелгән.

«Сүз белән кешене үтереп тә, терелтеп тә була!» – дигән сүзләрнең хаклыгы – билгеле хәл.

Безнең борынгы бабаларыбыз, мәгърифәтле халык буларак,



сүзнең кадерен белеп, табигать һәм галәм серләрен ачыкларга тырышып яшәгәннәр. Алар әле, төрле фән юнәлешләрен барлыкка китереп, зур ачышлар ясаганнар һәм бөтен дөньяга гыйлем таратырга тырышканнар.

Руналарның төркиләр арасында киң таралуы алар иленең кискен үсеш алуына сәбәпче була. Моңа бәйләнгән мәгърифәт һәм мәдәният үсеше дә гадәти бер күренешкә әверелә.

Бар җирдәге гыйбрәтле язулар, материальләшеп, төрки халыклар



тормышының барлык тармагына да үтеп керәләр. Алар һәр җирдә күзгә бәрелеп торганга һәм даими кулланышта булганга, укый-яза белмәүчеләр бөтенләй дә булмый диярлек.

Борынгы төркиләрнең кабер ташларында, мавзолейларында һәм монументаль корылмаларындагы таш язуларында киләчәк буыннарга рухи тәрбия, киңәшмәслихәт, шулай ук әхлак һәм әдәп нормаларын үтәүне васыять итеп язганнар.

Бу таш язулары төрки халыкларның борынгы поэзиясенә дә һәйкәл булып торалар. Бу язуларда Күк түркләр иленең Тәңре тарафыннан яралтылган «Мәңгелек ил» булуы, аның тарихы һәм халкы да изге булуы турында языла.

Бу «таш китаплар», борынгы Күк түркләр культурасының дөнья күләмендә зур әһәмияткә ия булуын танытып, аларның бөеклегенә илаһи һәйкәл булып торалар. Үзләрендәге сүз кодрәте, рухи бөеклек әле хәзерге вакытта да һәркемне таң калдырырлык бөек көчкә ия булып торалар.

Ул тарихи һәйкәлләрдә Күктән иңгән гайрәт, гыйлем һәм яшәеш серләре тупланган сыман. Боларда канлы сугышлар шау-шуы да, шулай ук тынычлык булдыруга, изгелекләр эшләргә өндәүләр дә язылган. Аларда һәлак булган каһарманнарга мәдхия укулар, бөтен төрки халыкларны берләшергә өндәүләр һәм башка күп нәрсәләр дә бар.

Орхон-Енисей таш язмалары – Күк түркләр тарихының ачык китабы.

Андагы акыл тупламасы төрки халыкларның меңнәрчә еллар кулланышта булган һәм үз алфавитлары белән киләчәк буыннарга атап язган васыять булып та хезмәт итә.

Борынгы болгар галиме Имам Бахши да үзенең «Болгар тарихы» исемле китабында Идел буе Болгарстанының фән һәм мәгърифәт өлкәсендә ирешкән уңышлары турында искиткеч хәбәрләр язган.

Мәсәлән, ул 1080 елда Биләр шәһәрендә «Мөхәммәд Бакирия» исемле беренче болгар университ-

теты ачылуы турында яза. Аның ректоры – тарих галиме, сәед Якуб ибн Ногман булган (Әхмәт ибн Фадланның оныгы).

Ул чакта болгар галимнәренең даны бөтен дөньяга таралгач, аларның илендә фән, мәгърифәт, мәдәният, икътисад өлкәләре дә югары үсеш алган. Болгарда бердәнбер галиҗәнәпләр мәктәбе («Школа принцев») эшләгән.



Анда дөньядагы бөтен илләрдән килгән принцлар – булачак корольләр, патшалар, солтаннар белем алганнар. Аларга төрле фәннәр һәм сугыш стратегиясен өйрәнү буенча фундаменталь белем бирелгән.

Тәҗрибә туплар өчен, үзләрен, гаскәр башлыклары итеп, төрле хәрби походларга җибәргәннәр. Андыйлар киләчәктә ил башлыклары яисә төрле фәннәргә нигез салган данлыклы галимнәр, шагыйрьләр дә булып танылганнар (Шота Руставели – шуларның берсе).

Гомумән, Идел буе Болгар дәүләте дөньяда иң югары дәрәҗәдәге фән, мәгърифәт үзәге булып танылган. «Нариман тарихы» исемле китапта данлыклы болгар галимнәренең дөнья күләмендә танылган 250 фәнни әсәре турында язылган. Ул хезмәтләр әле дә үз актуальлеген югалтмаган.

Менә шуларның тик кайберләре:

1. Мөхәммәд Гали ибн Мирхуҗа әл-Болгари (Кол Гали), «Кыйссаи Йосыф».

2. Шәех хуҗа әл-Болгари – данлыклы юрист. 1253 елда «Әл-Болгария» мәдрәсәсе ректоры, «Законнарны танып белү» (Познание законов) китабы 500 ел хокук белеме буенча дөньяда төп уку әсбабы итеп кулланыла.

3. Шәехҗуҗа Ногман әл-Болгари (Үзбәк хан киңәшчесе), «Югары дәрәҗәдәге мәрхәмәтлелек" (Возвышенное сострадание) – әхлакый тәрбия буенча төп дәреслек.

4. Шәех Әхмәт әл-Болгари – бөек Мәхмүт Газневиның укытучысы (Төньяк Индия һәм Әфганстанда көчле империя төзегән кодрәтле солтан) хезмәтләре.

5. Борханетдин ибн Юныс әл-Болгари – дин галиме, табиб, «Гади дарулар энциклопедиясе», «Борханетдин фәнни язмалары».

6. Шәмсетдин Мөхәммәд ибн Әшраф әл-Хәсәни, «Бәхәс алып бару тәртибе һәм культурасы турындагы трактат».

7. Тәҗетдин ибн Юныс әл-Болгари, «Ат-тирияк әл Кәбир» (Большое противоядие).

Болгар иленең төрле өлкәләрендә югары уңышларга ирешүе халыктагы Ватанга карата булган көчле патриотизмга да бәйләнгән. Ә бу бик тирәннән, меңнәрчә еллар катламыннан калкып килә. Иң борынгы Болгар дәүләтен төзүче Болгар-Батыр Карт Җиам үзенең халыкка мөрәҗәгатендә:

«Безнең дәүләттә үз илен хөрмәт итүче, аның бәйсезлеге өчен үзен корбан итәргә гел әзер булган халык яшәргә тиеш. Үз илебезгә карата булган мәхәббәтне, ватанпәрвәрлекне законнар гаделлеге, йөрәкләргә үтеп керерлек вәгазьләр, эчтәлекле китаплар, үрнәкле риваятьләр, шәхси үрнәкләр һәм тиңдәшсез батырлыклар нигезендә тәрбияләргә кирәк.

Барлык түрәләр, имамнар тарихыбыз, гореф-гадәтләребез һәм тәрбия алымнарын куллана белүләре хакында, ел саен имтихан биреп, бу эшкә үзләренең яраклылыгын исбатларга тиеш!

Әгәр дә Болгар иленә авырлык килә икән – әмир дә, сәүдәгәрләр дә, галиҗәнәпләр дә хөр сөрергә, күңел ачып яшәргә тиеш түгел!

Әгәр дә илдә бәрәкәт булса, халыкта үз иленә карата мәхәббәт һәм горурлык күкрәп тора икән – шатланыгыз, барабаннар кагыгыз, җырлагыз-биегез һәм, илебез байрагын югары тотып, горур булып яшәгез!

Мохтаҗларга ярдәм итегез, тоткындагы болгар кардәшләрегезне азат итегез!» – дигән.

Борынгы болгар бабаларыбызның тарихын, аларның яшәү рәвешен һәм идеологиясен кайсы яклап карасак та – анда безнең өчен шулкадәр матур үрнәк, гыйбрәт тупланган бит!

Ни кызганыч, тик әле балалар гына түгел, хәзер аларның ата-аналары һәм күбесенең әбибабалары да, бу хакта күп нәрсәне белмичә, шулар белән горурланудан да мәхрүм булып яшиләр.




# АЛАР ГЕРОЙ БУЛЫП КИТТЕЛӘР

***24 февральдә махсус операция башлануга бер ел тулды. Аның максатлары — хәзерге һәм үсеп килүче буыннар өчен куркынычсыз киләчәк булдыру. Самар өлкәсендә туып-үскән егетләр, тиңсез батырлык күрсәтеп, үзләренең хәрби бурычларын үтиләр. Алар - чын патриотлар, батырлык һәм намус үрнәге. Кызганычка, аларның күбесе орден-медальләр белән һәлак булганнан соң гына бүләкләнәләр. Һәр төбәктә, шәһәрдә һәм авылда андый геройлар бар, алар турында онытырга һич ярамый!***

***Эльмира СӘЙФУЛЛИНА***



*Илнур Ганиевны җирлиләр.*

11 ноябрьдә Камышлы районының Яңа Усман авылында Украинадагы махсус операциядә һәлак булган якташыбызны – ***Илнур Мирсалих улы Ганиевне*** алып кайтып җирләделәр.

1990 елда туган Илнур Мирсалих улы танкларга каршы тору батареясы командиры булып хезмәт иткән. Алгы сызыкта үз-үзен аямыйча оборона тоткан вакытта аның батареясы янында дошман ракетасы шартлый, һәм сержант Илнур Ганиев яралана. Ярасы авыр булып чыга: өч атна үлем белән көрәшә егет, ләкин җиңә алмый, 2022 елның 6 ноябрендә вафат була. Ул Россия президенты тарафыннан “Батырлык ордены” белән бүләкләнүчеләр исемлегенә кертелә.

* * *

22 ноябрьдә махсус хәрби операциягә Тольяттидан алынып, һәлак булган сержант ***Руслан Усмановны*** соңгы юлга озаттылар. Ул да хәрби бурычын үтәгәндә геройларча һәлак булган. Руслан Марс улын соңгы юлга озатырга туганнары, якын дуслары, хезмәттәшләре, ветеран оешмалары вәкилләре килде.

Русланны туганнары һәм хезмәттәшләре шат күңелле, ярдәмчел һәм ышанычлы кеше



***Руслан Усманов***

итеп искә алалар. Авыр минутларда ул һәрвакыт ярдәмгә килергә, сугышчан иптәшләренә иңбашларын куярга әзер иде. Руслан Усмановның әлеге адымы замандашлар һәм киләчәк буыннар өчен патриотизм үрнәге булачак. Ул батыр булып китте һәм безнең йөрәкләрдә мәңгегә шундый булып калачак.

* * *

2023 елның беренче көнендә Донецкидан ерак булмаган Макеевка шәһәренең ПТУ бинасында урнаштырылган солдатларыбыз өстенә Украина кораллы көчләре, дүрт Himers ракетасы җибәреп, һәлакәткә китерделәр. Нәтиҗәдә бинадагы сугышчыларның бер өлеше плитәләр астында калып имгәнә, бер өлеше снаряд кыйпылчыкларыннан һәлак була.



*Ирек Насыйров*

Алар арасында Елховка районының Мулла авылы мәчете имамы булып хезмәт иткән һәм мобилизация буенча махсус операциягә алынган ***Ирек Насыйров*** та бар. 26 яшьлек Ирек Илдар улы, Самарның "Нур" мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, армиядә хезмәт итеп кайткан һәм Мулла авылы мәчете имамы булып эшли башлаган. Читтән торып Казанда ислам дине буенча югары белем дә ала булган, ләкин чыгарылыш имтиханнарын биреп өлгерә алмаган, туган иле өчен сугышка киткән. Солдат башта Тольятти гарнизоннарының берсендә канцелярия эшләре белән шөгыльләнгән, соңрак аны Донецкига җибәргәннәр. Шулай ул Макеевкага барып эләккән. Киткәндә туганнарына: "Кайгырмагыз, мин кайтырмын", - дип, күтәренке күңел белән хушлашкан. Ирек "Батырлык ордены" белән бүләкләнгән.

Ул балачактан тарих фәнен яраткан, журналист булырга хыялланган. Авылдашлары сөйләвенчә, Ирек хәзрәтнең вәгазьләре искиткеч эчтәлекле булган. "Ул тарихны бик яхшы белә иде", - дип сөйлиләр алар.

* * *

13 февральдә Челно-Вершины районының Хөсәен авылында махсус хәрби операциядә һәлак булган ЧВК «Вагнер» сугышчысы ***Илһам Габделбәр улы Аксенов***ны соңгы юлга озаттылар. Мәрхүмнең туганнары һәм танышлары аның турында: «Аңа нибары 32 яшь иде, ул гади һәм ярдәмчел егет иде», - дип сөйлиләр. Туганы мобилизацияләнгәч, ул да үз теләге белән сугышка киткән. Илһамны җирләү мөрәсименә туганнары, якыннары, дуслары, район хакимияте һәм авыл җирлеге вәкилләре килде. Илһамны әтисе янында җирләделәр.

* * *



27 февральдә Камышлы районының Иске Ярмәк авылы егете, 39 яшьлек ***Илья Абдуллин***ны туган җире куенына куйдылар. Ул да - Украинада барган махсус операция корбаны, Артемовск тирәсендә 20 гыйнварда һәлак булган. Армиядә Хабаровскида танкист булып хезмәт иткән.

Ә 1 мартта шул ук авылда Фәһим абый белән Миңсылу апа Шәфиковларның тәрбиягә алган уллары - 27 яшьлек ***Михаил Конаков***ны җирләделәр. Аңа ***Марат*** дип исем кушкан булганнар. Ул да Украинада, Артемовскида геройларча һәлак булган.



*Илья Абдуллин*



*Михаил (Марат) Конаков*

- Без аны 7 яшендә тәрбиягә алган идек. Безнең гаиләгә бик тиз ияләште, саф татар телендә сөйләшә иде, матур итеп шигырьләр сөйли иде, әбисенә китаптан догалар укый иде. Бик уңган, өйдәге бөтен эштә дә булыша иде. Шук булды, әмма бик ягымлы, йомшак күңелле иде балакаем, - дип елый Миңсылу апа. - Балачагынан хәрби булырга хыялланды. Махсус хәрби операциягә киткәч, бик озак хәбәре булмыйча торды. Телевизордан күргән һәрбер солдатны улыбыз Маратка охшата башладык. Чыдар хәл калмагач, военкоматка мөрәҗәгать иттек. Ә берничә көннән Маратыбыз 29 декабрьдә һәлак булган, дигән хәбәр килде, - ди кара кайгыга баткан ана.

Барыбызны да Аллаһы бар иткән һәм аңа кайтачакбыз да. Аллаһы Тәгалә диндәшләребезнең рухын кабул итсен, гөнаһлары булса, ярлыкасын һәм Җәннәт бакчаларына кертсен иде. Туганнарына чиксез сабырлык телибез...

# Война народная

*(Окончание.
Начало — в предыдущем номере)*

## Восстание Пугачева стало мощным национальным движением тюркских народов Поволжья



*Памятник Салавату Юлаеву*

***На Сибирской дороге с ноября 1773 года действовал Салават Юлаев. Его отряд состоял из 800 воинов — башкир, татар, марийцев и чувашей. В середине января он прибыл под Кунгур с тремя тысячами воинов. У Салавата были пушки, и с их помощью 23 января он ворвался в предместье, но был отбит гарнизоном. 24 января состоялся новый неудачный штурм. А вскоре крепость была деблокирована отрядом правительственных войск под командованием секунд-майора Дмитрия Гагрина, который вынудил повстанцев отступить.***

*Дмитрий ГРЕКОВ*

### Татары и башкиры — опора Пугачева

30 января под Ордынским острожком Гагрин нанес поражение повстанцам. 19 февраля они снова были разбиты под Красноуфимском. Под деревней Бугалыш стычка между правительственными войсками секунд-майора Александра Папавы и восставшими Салавата Юлаева закончилась вничью.

Блокадой Челябинска занимался Базаргул Юнаев. Восставшие овладели Саткинским, Симским, Златоустовским заводами. Также в регионе действовали отряды Юламана Кушаева, Исая Токтагулова, Муртазы Юртаумова, Базаргула Юнаева. В Исетском районе восстали до 10 тысяч башкирских конников.

> После ряда поражений у самого Пугачева осталось пять сотен воинов. Кинзя Арсланов обещал ему собрать через некоторое время отряд в 10–15 тысяч башкир. Самозванец шел на Ногайскую дорогу, и его войско возрастало.

Бектимур Мутаев и Кинзябулат Алкашев собрали отряд в 700 воинов. Из Кубелякской волости Абзан-тархан собирался идти к вождю с сотней всадников. Мрадым Саитмамбетов собрал 500 человек в Меркит-Минской волости. Санчей, Кутлугул и Каскын Самаров набрали значительный отряд.

В мае у Пугачева уже было около трех тысяч русских и около четырех тысяч башкир. К концу мая его главное войско насчитывало уже 10–12 тысяч человек. Однако после ряда поражений от подполковника Ивана Михельсона и генерал-поручика Йоханна Клапье де Колонга (Ивана Деколонга) русская часть армии повстанцев снова значительно сократилась, так что его сила теперь была только в башкирах.

Вместе с тремя тысячами воинов Салавата Юлаева самозванец двинулся к Осе, затем на Казань. По пути следования к нему примкнули Кинзя Арсланов, Идеркай Баймеков, Кутлугильда Абдарахманов, Сляусин Кинзин. К Казани Пугачев пришел уже с войском в 20 тысяч из башкир, татар, русских. После штурма Казани большинство их были отпущены. За Волгу последовали только отряды Идеркая Баймекова и Кинзи Арсланова.



*Иван Михельсон*

### Начало конца

Неудачи под Мензелинском, Кунгуром, Уфой и Оренбургом вызвали колебания у многих башкирских и мишарских старейшин, и они отошли от восстания. Ямансары Яппаров даже отправил отряды своих сыновей на преследование Пугачева. Алибай Мурзагулов принес повинную властям. Кидряс Мулакаев также перешел на сторону правительственных сил.

Каскын Самаров сохранял верность Пугачеву, во главе отряда из нескольких сотен воинов он действовал под Уфой и распространял в мае 1774 года воззвания к башкирским и татарским старейшинам. Каранай Муратов действовал в бассейне реки Демы и около Стерлитамака. Вместе с ним идти походом на Уфу собирались Кусяпкул Азятев и Мурадым Абдурахманов.

На севере Башкирии остались отряды Илятая Илимбаева и Бахтийара Канкаева, уроженца Сибирской дороги. Он вместе с Салаватом Юлаевым штурмовал Кунгур. Писарем Бахтийара был Абубакир Тилячев, который распространял в своих посланиях дезинформацию, например, известиям о взятии пугачевцами Оренбурга.

На Осинской дороге действовал Мукаш Сутеев. Башкиры из племени гайне взяли Осу в блокаду. 5 июня 1774 года на реке Ашкадар повстанцы Алибая Мурзагулова, Каип Зиямбетев, Ибрагим Мрясев вместе с главным войском Пугачева дали бой корпусу генерал-поручика Петра Голицына. В Башкирию были отправлены отряды регулярной армии, которые высвободились после заключения мира с турками и были переброшены из Крыма.

> Но борьба продолжалась. Из-под Осы на соединение с главным войском Пугачева двинулись Салават Юлаев и Канзафар Усаев.

Однако к осени 1774 года большинство башкир вернулись в русское подданство, и лишь Каскын Самаров, Каранай Муратов, Муйнак Сулейманов и Кутлугильда Абдрахманов продолжали сопротивление. В ноябре 1774 года 22 башкирских старейшины во главе с Алибаем Мурзагуловым принесли присягу императрице.

### В итоге всего

Во второй половине 1774 года активное сопротивление башкир на Осинской дороге прекратилось. В конце лета того же года повстанцы вернулись с Казанской и Осинской дорог на Ногайскую дорогу. Они осаждали некоторые крепости региона, сражались с командой полковника Василия Долгорукова, разгромили отряд Ямансары Яппарова. В центре и на севере Ногайской дороги действовали отряды Караная Муратова и Каскына Самарова. Каранай совершил рейд на запад Башкирии, где соединился с главным войском Пугачева. Каскын сразился с командой Рылеева, взял несколько сел и Стерлитамакскую пристань.

Осенью башкиры Ногайской дороги отошли от восстания и в ноябре — декабре 1774 года прекратили сопротивление. Долго продолжалось восстание в Зауралье — тут башкир Юламан Кушаев и татарин Мухамет Сафаров распространяли слухи, что Пугачев уже находится в этом краю. Вместе с ними в регионе действовали Базаргул Юнаев и Сара Абдуллин.

> Большое значение имели действия Салавата Юлаева. С ним были связаны отряды повстанцев в районах Осы, Красноуфимска, Кунгура. В августе 1774 года, отступив от Уфы, Юлаев перенес боевые действия в северную Башкирию.

30 августа отряд правительственных войск премьер-майора Ивана Штерича столкнулся с отрядами Ярмухамета Кадырметова, Байея Тойкиева и Аита Саитова на реке Амзе. На помощь им 4 сентября пришел Салават Юлаев, 7 сентября Ярмухамет снова сразился с Штеричем. 18 и 22 сентября в битвах при реке Бирь и селе Нуркино Юлаев сражался с отрядом подполковника Ивана Рылеева. В бою 22 сентября повстанцы потеряли около четырех сотен и отступили под артиллерийским огнем.

В то время отряд Юлая Азналина осаждал Катав-Ивановский завод. Позже к нему подступил Салават. Однако завод не сдавался, а его защитники не верили словам башкир. На Сибирскую дорогу императрицей были отправлены лояльные ей башкирские старейшины и регулярные войска под командованием генерал-майора Магнуса Фердинанда фон Фреймана. Корпус последнего в битве при Катав-Ивановском заводе разбил Салавата Юлаева, и 25 ноября 1774 года башкирский полководец попал в плен.

При подавлении восстания в Кунгуре были повешены Субхангул Кильтяков и Чюря Расулов, многих предводителей восстания отправили на каторгу, но рядовых башкир репрессии почти не затронули. Они лишь были вынуждены отдать четыре тысячи коней как штраф. Башкирские старейшины, находившиеся в следственных комиссиях, были освобождены от наказания — жестокие расправы вынудили бы башкир уйти к казахам, а этого в Петербурге не хотели.


*Кунгур. Обелиск в память победы над отрядами Пугачева*

# Запад и восток

## Как правитель Мамай власть терял




***Всё то время, когда в Улусе свирепствовала «великая замятня», на восточных рубежах, в Синей Орде (она же Улус Орда-Эчжена, брата Бату-хана, получившего его во владение во время раздела наследия их отца), сохранялся относительный порядок – правители Чимтай (1345–1361), его брат Орда-Мелик (1360–1362) и сын Чимтая (по одной из версий) Мухаммад Урус-хан (1362–1376), сменяя друг друга, сидели в Сыгнаке (столице улуса), удерживали власть в руках и истребляли родственников – так что их (родственников) в итоге осталось мало, потому большой опасности они не представляли, и можно было заняться внешней политикой…***

*Дмитрий ГРЕКОВ*

### Изгнание из столицы

Например, влезть в борьбу за ханский престол в Золотой Орде. В 1272 году Урус-хан (он же Орыс, Арыс или даже Ырыс) двинулся на Новый Сарай и выгнал оттуда Булак-хана. Не удовольствовавшись этой победой, «синий ордынец» пошел в 1274 году на город Хаджи-Тархан (Астрахань) и выгнал оттуда правившего там Хаджи-Черкеса.

Но тут на Уруса обрушились сразу две беды – во-первых, в Синей Орде снова начались смуты (кто-то из родственников остался недобит), а во-вторых, из еще одного вассального владения Орды, Улуса Шибанидов (со столицей в городе Сарайчук, или Сарайчик) набежал тамошний правитель Ильбек.

Решив, что своя орда важнее чужих, Урус-хан вернулся в Сыгнак для подавления оппозиции, а Шибанид оккупировал столицу – Новый Сарай. Однако триумф Ильбека был вельми недолговечен – в Поволжье возвратился Мамай и вступился за «обиженного сироту-воспитанника», разгромив и убив узурпатора и водворив Булак-хана обратно в столицу Улуса. Затем беклярбек убыл на западные границы собственных владений, где опять безобразничали литвины, и тогда из степей снова налетел Урус – и выгнал Булака. И снова ненадолго, будучи изгнан…



*Развалины Сарайчика*

Затем на Новый Сарай набежал вернувшийся в Астрахань Хаджи-Черкес, разбил врагов и изгнал Булак-хана, сбежавшего со своим покровителем в Крым. В начале 1375 года Мамай вернулся и на сей раз прогнал Хаджи-Черкеса, чтобы… в июне 1375 года быть снова изгнанным вернувшимся Урус-ханом. В июле удалось отогнать «поганца» обратно, но в конце 1375 года из степей набежал очередной Шибанид, Гияс уд-Дин Каганбек-хан, и отобрал у тёмника и его подопечного призрак верховной власти в Золотой Орде.

### Западные рубежи

Более Мамай в Новый Сарай не вернется – его целиком поглощают дела собственного улуса. В Крыму подняли голову генуэзцы – еще в 1365 году они отняли у вассального византийского княжества Феодоро крепость Солдайю, назначили туда консула и принялись укреплять свои черноморские колонии. В наказание за сие в 1375 году беклярбек отобрал у «наглых фаранги» 18 поселений в Сурожской долине, отодвинул генуэзские владения обратно к морю и возвел стены вокруг ордынской резиденции в Крыму, города Солхат (Старый Крым).

Однако тут по закону нарастания неприятностей в природе начали «отваливаться» русские княжества. Сперва в 1374 году князь Дмитрий Нижегородский посадил в узилище посланца Мамая – Сарай-аку, а через год вообще убил.

В том же 1375 году Дмитрий Московский отказался платить «выход». Пришлось отправить «зондеркоманды» – ордынцы сожгли принадлежавшие князю Нижегородскому волости Киш и Запьянье, а также город Новосиль, владение князя Московского.

Затем Мамай снова выдал ярлык на Владимир князю Михаилу II (Александровичу) Тверскому. Москва на сей раз отреагировала быстро – собрав всех своих «верных союзников-нахлебников» (10 князей Северо-Восточной Руси и новгородскую рать), Дмитрий Иванович набежал на Тверь и «пригнул» соперника, заставив того признать себя «старшим братом» и заключить военный союз против Орды – а в качестве гарантии отобрал город Кашин (который Михаил долго пытался отнять у своего родича князя Василия Михайловича).

К тому же утвердившийся к тому времени в Новом Сарае Каганбек приказал князьям Московскому и Нижегородскому напасть в 1376 году на Волжскую Булгарию (Дмитрий Иванович опять отправил в поход своего «боевого терминатора», служилого князя Дмитрия Боброка-Волынца) и принудить ее амира Асана, сохранявшего верность Булак-хану, подчиниться новому хозяину Золотой Орды.



*Битва на Воже*

### От Пьяны до Куличек

Однако «жадные урусы» сильно пограбили булгар и стрясли с Асана много денег. Тот нажаловался Каганбеку, и поскольку князья с ним не поделились, хан наслал на Русь своего кузена (двоюродного брата, сына хана Мир Пулада) Араб-шаха Музаффара (в русских летописях – «царевич Арапша»), который и совершил знаменитое нападение 2 августа 1377 года на «истомившихся жарой с похмельем и гулявших в одних портах» московско-нижегородских ратников на реке Пьяне (2-е сражение на Пьяне), учинив большой погром и убив княжича Ивана Дмитриевича Нижегородского. Победитель разорил Нижегородское княжество, а потом вторгся в Рязанское и сжег его столицу.

Воодушевленный таким «наказанием строптивых урусов», решил воспользоваться благоприятной конъюнктурой и Мамай, отправивший летом 1378 года на «подлую Москву» в набег войско под командой мурзы Бегича (или Бегиша).

Каковое и было разбито 11 августа в хорошо известной школьникам и прочим любителям «популярной исторической литературы» битве на реке Воже. Правда, многие россияне, до сих пор доверяющие школьным учебникам, не в курсе, что наряду с московской ратью там дрались и воины пока еще независимого от Москвы князя Даниила Пронского – ведь сама река Вожа, вообще-то, в его княжестве и находилась.

Мамай в качестве «мести» снова разорил Рязанское княжество (напав с юга), а потом решил попробовать договориться с Дмитрием Московским миром, но тот, раздувшись от собственного величия, «послов послал» в «пешее эротическое путешествие». Оставался лишь один выход – набирать «неисчислимые рати» и идти походом на Москву в 1380 году...

Но увы, дорогие мои читатели, увольте от пересказа сотен книг и статей о Куликовской битве (она же, по твердому убеждению сторонников «новой хронологии», «Битва на Куличках»), авторы которых уже лет двести друг с другом спорят, до хрипоты поноса оппонентов – в конце концов, мы тут говорим об истории не России, а Золотой Орды. Посему все, кто до сих пор не решил до конца, сражались ли за Мамая генуэзцы в «полном турнирном доспехе» (спойлер: не сражались), на кого на самом деле ходили и куда дошли великий князь литовский Ольгерд и великий князь Рязанский Олег Рязанский, и чем вообще закончилось дело 8 сентября 1380 года, могут припадать к другим «источникам знаний»...



## Как беженцы от погромов создали государство Израиль

*Мы продолжаем рассказ об интересной, но не очень любимой в нашей стране теме — зарождении мирового сионистского движения, создании Израиля и той роли, которую сыграли в этом выходцы из России*

*Дмитрий ГРЕКОВ*

# Россия – родина сионизма

*(Продолжение. Начало — в предыдущем номере)*

### Люди и деньги

Всего за год после первого конгресса мир буквально захлестнула волна сионизма. До 1897 года кружков и организаций евреев, ратовавших за изложенные Герцлем и его соратниками идеи, по всему мир было 117, а в 1898 году их стало уже 913. В России же соответствующие цифры — 23 и 373. То есть доля участия наших соотечественников в «мировом сионизме» выросла с 19,6 % до 40,8 %.

19 августа 1898 года в Варшаве состоялся первый сионистский конгресс Российской империи — он проходил нелегально, ибо, хотя «мировых евреев» не ловили, как социалистов или националистов, никаких симпатий к их идеям правительство таки не питало. В нем участвовало около 160 представителей из 93 городов и местечек. Основную повестку составило обсуждение вопросов будущего Второго сионистского конгресса, который открылся 28 августа снова в Базеле — большинство российских делегатов прямо туда из Варшавы и направились. Герцля снова единодушно избрали президентом, а одним из трех вице-президентов форума был избран житель Киева.

Обсуждало «мировое еврейство» на конгрессе «текущие мировые темы» — например, «дело Дрейфуса» (ложное обвинение военными-антисемитами офицера генштаба Франции в шпионаже). Важнейшим же принятым решением стало основание банка для финансирования переселения в Палестину. Еврейский колониальный банк был зарегистрирован 20 марта 1899 года в Лондоне в качестве английского акционерного общества под названием «Джуиш Колониэл Лтд Траст». В конце апреля того же года было выпущено 200 тысяч акций достоинством в один фунт стерлингов (или десять рублей) каждая. На 75 % всех этих акций подписались русские евреи.

По уставу банк был вправе приступить к регулярной работе только при наличии минимального капитала в 250 тысяч фунтов. Недостающая сумма (50 тысяч) собиралась с трудом, и банк начал функционировать лишь в начале 1902 года. В конце февраля была создана дочерняя компания банка под названием Англо-Палестинское общество, затем — Англо-Палестинский банк (ныне — Банк леуми ле-Исраэль, Национальный банк Израиля). Эта фирма начала действовать в Яффе летом 1903 года.

### Заграница не поможет?

Однако массовость сионистского движения в России «компенсировалась» тем, что царские власти ничем его не поддерживали — даже вредили чем могли, лишь не переводя ситуацию в насильственное противостояние. Потому Герцль и «мировая закулиса» обратили свое внимание на другие правительства — в первую очередь Германии, которое имело большое влияние на Османскую империю, снабжая ее оружием, технологиями и специалистами. А поскольку Палестина всё еще принадлежала туркам, с этой стороны можно было «подкопаться»...

Дошло даже до того, что кайзер Вильгельм II посетил Палестину в то же самое время, что и Герцль с делегацией сионистов, обещая им накануне «поговорить с султаном». Но увы — беседа с Абдулом Хамидом II и собственными дипломатами (антисемитами, да еще и не хотевшими «обострять вопрос» с Англией, Францией и Россией) охладила рвение императора, и скоропостижный «роман с евреями» закончился.



*Кайзер Вильгельм II евреям не помог...*



*Султан Абдул Хамид II тоже не помог...*



*Помогал только банкир Натан Ротшильд*

Пришлось как-то контактировать с турецким султаном напрямую — на Третьем сионистском конгрессе (снова в Базеле — 15–18 августа 1899 года) Герцль заявил: «Мы стараемся добиться от турецкого правительства „чартера“ — разрешения на поселение под верховным покровительством султана. Лишь располагая такой гласной санкцией, содержащей необходимые гарантии публично-правового характера, мы сумеем приступить к широкому практическому заселению». Колониальный банк рассматривался как средство и орудие для получения «чартера» (для выкупа земли и финансирования переселенцев, а также для взяток и «умасливания» османского правительства).

Однако же, как было указано выше, колониальный банк смог заработать только в 1903 году. Так что до того времени пришлось «частным лицам» брать инициативу на себя — вдохновившийся идеями сионизма «мировой олигарх» Натан Ротшильд на собственные деньги скупал в Палестине «пустующие» земельные участки, которые предоставлял в пользование приезжавшим туда переселенцам. Местные арабы и османские чиновники, естественно, были от эдаких схем «далеко не в восторге»...

## Только Израиль, только хардкор!

Третий сионистский конгресс стал своего рода судьбоносным — австрийское руководство во главе с Герцлем впервые подверглось критике со стороны многочисленной оппозиции... правильно, из России. Россияне вообще составляли большинство из 280 делегатов, немало их было среди приглашенных 150 журналистов и «сотен гостей».

Формально поводом для спора стала формулировка положения о банке, точнее, слова «поселение евреев может иметь место в Палестине, в Сирии либо в любой другой стране в любой части света». На основании чего, кстати, на заседаниях делегатов даже поднимался вопрос о колонизации Кипра, оккупированного англичанами лет 20 назад, где не было султанской бюрократии и мусульман — что до глубины души возмутило ортодоксальных иудеев, настроенных «возводить второй храм только на месте первого». Также Герцля и Ко обвинили в желании «прибрать к рукам» управление будущим колониальным банком.

Всё это вызвало к жизни обвинение в «авторитаризме»: «Есть моменты, когда диктатура нужна... Но диктатура всегда явление временное и преходящее. Устойчивые движения не знают диктатуры — в противном случае они долго бы не просуществовали». «Патриарх», с точки зрения «россиян», обещал «мировому еврейству» слишком много и слишком быстро, тогда как для настоящего «триумфа сионизма» нужны были многие годы кропотливой работы многочисленных ячеек, а не «пламенных вождистских речей».

Накал дискуссии дошел до того, что после завершения работы конгресса (на котором «кипрский проект» таки похоронили, а вопрос о структуре управления банком «подвис в воздухе») Герцль и «русские евреи» для «выглаживания углов» устроили совместный банкет, демонстрируя «любовь и огромное уважение, которое сионисты России питали к великому вождю сионистского движения, несмотря на имевшиеся расхождения во взглядах».

***(Продолжение следует)***

# НӘРСӘ УЛ - ТОРМЫШ? НӘРСӘ УЛ - ЯШӘҮ?



*Гакыйль Шәрифулла улы Сәгыйровка быел 85 яшь тулган булыр иде.*

***1938 елның 16 февралендә дөньяга килгән һәм гомерен түшәк өстендә үткәрергә мәҗбүр булган якташыбыз - Гакыйль Шәрифулла улы Сәгыйровны күренекле татар шагыйре, язучы, хәбәрче һәм рәссам, дип атыйбыз. Һәм ул - бу югары исемнәргә бик тә лаеклы шәхес.***

***Эльмира Шәвәлиева әзерләде***

...Мәктәптә иң булдыклы укучы була ул. Бөтен яклап та: шигырьләр дә язгалый, рәсемнәр дә ясый. Ул җиденче классны “5”ле билгеләренә тәмамлый. Мактау грамотасы белән дә бүләкләнә. Хыялларның иге-чиге булмый. Әмма язмыш рәхимсезлек кыла: яшүсмер авырый башлый. Ләкин аның язмыш белән ризалашасы килми: ихтыярын туплап, шифаханәгә китә, операция өстәленә ята. Өйгә аны носилкада алып кайталар. Ул язарга, рәсем ясарга тели, ләкин куллары тыңламый... Бер көнне “Огонек” журналыннан тешләре белән рәсем ясаучы рәссам турында укый. Бу аңа көч бирә - беренче күнегүләр, өметсезлекләр, уңышсызлыклар. Әнисенең кызганып елаулары... Шундый озын-озак газаплардан соң кәгазь битенә беренче шигырь юллары төшә. Аларда туган ягын сөю хисләре, ана батырлыгы, киләчәк буыннарга үгет-нәсыйхәт, батырлык һәм өметсезлек хисләре...

*... Кайсыгыз анда туйган яшәүдән?-*
*Тыгыз уйлардан, мәшәкатьләрдән,*
*Тынгысызлыктан, кыен эшләрдән*
*Һәм тирләп - пешеп, янып*
*эшләүдән?*
*Кайсыгыз анда туйган сөюдән,*
*Башкалар өчен янып-көюдән,*
*Мәхәббәт хисен туң кырау алган*
*Һәм йөрәкләре гел бушап калган?..*
*Кайсыгыз анда туйган*
*барысыннан:*
*Кошлар җырыннан, чишмә*
*тавышыннан,*
*Якын дустыннан, елмаюлардан,*
*Җил-давыллардан, ерак юллардан?*
*Килегез әле минем яныма!*
*Килегез әле минем яныма,*
*Ятыгыз әле минем урыныма,*
*Бирегез миңа аяк-кул гына!..*

Гакыйль Сәгыйров тормышка фәлсәфи яктан чыгып карый, көндәлекләр яза. Анда мондый юллар бар: “Нәрсә ул - тормыш? Нәрсә ул - яшәү? Бу сораулар гасырлар буена кешелекне борчып килгән... Кеше яши һәм беркөнне юкка чыга. Бу гел шулай дәвам иткән һәм итәчәк тә. Киләчәк кешеләре безне гомуми исем белән генә - егерменче гасыр кешеләре, дип атаячаклар, ул көннәргә безнең чордан берничә йөз кешенең исеме генә барып җитәчәк”...

1960нчы еллардан башлап, Гакыйль Сәгыйровның исеме бөтен татар дөньясына тарала. Николай Островский батырлыгын кабатлаган татар шагыйрен күрергә бөтен Россиядән зыярлылар килә башлый. Куйбышевтан “Ялкынлы яшьлек”, “Идел” ансамбльләре артистлары, өлкә “Бердәмлек” газетасының баш мөхәррире Рәфгать Әһлиуллин, Камышлы районы газетасы хәбәрчесе Фәния Кәримова, Ульян



***Иске Фәйзулла авылында Гакыйль Сәгыйров яшәгән йорт***

өлкәсенең “Өмет” газетасы баш мөхәррире Исхак Хәлимов һәм ул вакытта “Чаян” журналында эшләгән хәзерге редакторыбыз Данияр Сәйфиев һәм башка матбугат чаралары вәкилләре килеп, язып, Сәгыйровның батырлыгын еракларга тараталар.

***“Бу сәяхәттән без яңа шагыйрь алып кайттык...” дип аталган мәкаләсендә татар шагыйре Илдар Юзеев 1968 елда болай дип яза:*** “Яшь шагыйрь Гакыйль Сәгыйровның исемен беренче тапкыр «Ялкын» журналында эшләгәндә, моннан алтыҗиде еллар элек ишеттем. Әдәбият бүлеге мөдире Г. Сабитов ашыгып керде дә безгә бер шигырь укып күрсәтте:

*Әй, кыш килгән, кыш килгән,*
*ак бүрек кигән.*
*Кисмәктәге су туңган,*
*Ватып алырлык булган.*

Шигырь безгә шунда ук ошады. Ләкин аның бер кимчелеге бар иде, автор нишләптер шигырен акка күчереп тормыйча, каралама хәлендә җибәргән. Шигырен журналга тәкъдим иттек, ә үзенә, шелтәләп, хат язып салдык. Редакциягә кулъязмаларны ачык итеп, кара белән язып җибәр, алай ярамый, янәсе. Ул егет шул ук вакытта рәсемнәрен дә җибәрде. Алар гаҗәп матур эшләнгәннәр иде.

Безнең үпкәбезгә аңардан җавап хаты килде. Кыска гына язылган юлларда: «Мин бит - инвалид», - диюдән башка сүзләр юк иде.

Берничә ел узгач, «Социалистик Татарстан» газетасының үз хәбәрчесе, яшь язучы Рәшит Зәкиев сәләтле бу егетнең язмышын газета аша укучыларга хәбәр итте. Үзе турында берни дә әйтмәгән Гакыйль урында хәрәкәтсез ята һәм каләмне тешләренә кабып иҗат итә икән.

Аның иҗаты һәм тормышы белән укучылар ныграк кызыксына башладылар.

Яхшы шигырь безне дә ерак юлга чакырды. Шәүкәт Галиев белән бергәләперактагы Куйбышев өлкәсе Кошки районы Иске Фәйзулла авылында яшәүче Гакыйль Сәгыйров янына киттек. Октябрь Норлаты районында безгә Рәшит Зәкиев тә кушылды.

Һәм менә без аның өендә. Ул да, без дә, әнисе Хәбибҗамал апа да башта каушап, сүз табалмыйча тордык. Китап киштәсендәге бер китап сүзне башларга ярдәм итте.

— «Хөсәен Ямашев». Автор үзе бүләк иткәндер инде?

— Әйе, күптән түгел Норлатка килгәч, Расих абый, Гөлшат Зәйнашева һәм Роберт Әхмәтҗановлар кергәннәр иде.

Без алып килгән әманәтләрне, автограф язылган китапларны, хатларны тапшырабыз. Гакыйльдән шигырьләрен күрсәтүне сорый-



Яңа шигырь туа







Аның рәсемнәре

быз. Менә балалар өчен язылган бер шигырь:

*«Антеннада ике карга*
*Тирбәлә кунган көйгә.*
*Шуларны күрде дә Дилә*
*Йөгереп керде өйгә.*
*Әнием, телевизорны*
*Тизрәк инде кабыз, ди,*
*Анда кунган каргаларны*
*Күрмичә калабыз, ди».*

*Бир ышанып миңа кулларыңны,*
*Чын иптәшем булып күтәрел!»*

Гакыйль дөньяга художник күзе белән карый: аның сизгер йөрәге табигатьтәге, тормыштагы буяуларны, контрастларны, нечкәлекләрне тотып ала белә.

*«Тормыш агай, алып күкрәгемнән,*
*Бирсә бирде минем кирәкне,*
*Һаман саен һәрбер матурлыкка*
*Сизгеррәк итте йөрәкне»...*



***Гакыйль әнисе Хәбибҗамал һәм журналист Луиза Әхтәмова белән (1960нчы еллар фотосы)***

Без рәхәтләнеп көләбез. Балаларча, яңача, үзенчә... Шул вакыт бүлмәдәге телевизорга күз төште. Аны Гакыйльгә Татарстан нефтьчеләре бүләк иткән икән. Лениногорск киностудиясеннән килеп, аны кинога да төшергәннәр. Гакыйльне больницага алып китеп, Лениногорск табиблары дәвалаганнар да.. Вертолет туптуры Гакыйльләрнең ишек алдына төшкән.

*«Яшәве дә авыр, үлеме дә,*
*Тормыш өчен көчең салмагач,*
*Үзең үлсәң, сине күңелләрдә*
*Яшәтерлек эшең калмагач».*

Гакыйльнең шигырьләре моңландыра да, түбән иелгән башны югары да күтәрә.

*«Без җитәсе җирләр ерак әле,*
*Без барасы юллар киртәле,*

Гакыйль шигырьдә - рәссам, рәсемдә - шагыйрь. Шигырь юлларына кергән теге топольләрне ул натурадан кәгазьгә дә төшергән. Әмма Гакыйль фотограф түгел. Ул топольләрне үз хыялы белән баета, сәнгать дәрәҗәсенә күтәрә. Шул ук вакытта ул топольләрне Гакыйльнең читкә киткән һәрбер авылдашы танып алыр һәм: «Аһ, шул топольләрне кайтып бер генә күрәсе иде!» - дип әйтер...

Гакыйльнең үзен күргәч, яңа шигырьләрен тыңлагач, элек язылган хатыбыз өчен уңайсызланып киттем. Шигырьдәге һәрбер хәрефне язу яки рәсемдәге һәр ноктаны кәгазьгә төшерү өчен, күпме чыдамлык, тырышлык кирәк! Шулай да, аның почеркының матурлыгын күреп, гаҗәпкә каласың. Шигырьдә дә Гакыйльнең үзе генә тапкан почеркы бар. Шагыйрьнең үзенчәлеге кешенең, табигатьнең матурлыгын эзләүгә, укучыда оптимистик рух уятуга юнәлгән. Гакыйль поэзиянең төрле өлкәсендә үзенең көчен сыный: лирика, сатира-юмор, балалар өчен шигырьләр...

Бу сәяхәттән без үзебез өчен яңа шагыйрь ачып кайттык”...

Гакыйльнең иҗат архивы кәгазьләре арасында татар шигъриятенең икенче корифее, күренекле балалар шагыйре Шәүкәт Галиев тарафыннан мәктәпкәчә яшьтәге сабыйлар өчен язылган шигырьләренә ясалган рецензия дә бар. Анда Шәүкәт ага, һәр шигырьне укып, тикшереп, үзенең фикерен белдерә, аларны ничек итеп яхшырту, камилләштерү юлларын да күрсәтә. Бу яшь шагыйрь өчен чын-чынлап бер мастер-класс булгандыр, мөгаен. Шигырьләрнең күбесенә югары бәя биреп, Шәүкәт Галиев “Балык шулпасы” дигәненең читенә: “Менә ичмасам бу шигырь инде! Мин язган булсам иде, дип көнләшерлек!” – дип язып та куйган әле.



***Менә шулай туа иде Гакыйльнең картиналары***

...Гакыйль Сәгыйровның беренче шигырьләре 1960 елда район үзәге — Нурлат шәһәрендә нәшер ителә торган «Дуслык» газетасында басылып чыга. Озакламый Казан газета-журналларында да

исеме күренә башлый, «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасында яшь шагыйрь турында зур язма басыла, журналист Луиза Хәйруллина Лениногорск телевидениесеннән аңа багышланган зур тапшыру оештыра, шагыйрьнең бер бәйләм шигырьләре «Беренче карлыгачлар» дигән күмәк җыентыкка (1968) урнаштырыла, ә 1970 елда Татарстан китап нәшриятында «Тормыш җиле» исеме белән беренче мөстәкыйль китабы басылып чыга. «Айбагарлар» дип аталган икенче китабы исә 1983 елда Татарстан Язучылар берлегенең Ш.Маннур исемендәге әдәби премиягә лаек була. 1990 елда башта Ульянда - "Өмет", аннан Самарда "Бердәмлек" өлкә татар газеталары чыга башлагач, Гакыйльне ике өлкә татарлары да белә, китапларын, әлеге газеталарда басылып чыккан мәкаләләрен укый башлыйлар.

1994 елда Татарстан китап нәшрияты әдипнең сайланма әсәрләр төсендә төзелгән «Кабатланмас моң» тупланмасын



Гакыйль Сәгыйров «Самар өлкәсенең мәшһүр татары» исеме бирелгәннән соң

5 мең тираж белән укучыларга тәкъдим итә. Якташыбыз Рәшит Шакиров ул җыентыкка кергән шигырьләрне рус теленә тәрҗемә итә. Татарча оригиналлары янәшәсенә русча тәрҗемәләре урнаштырылган һәм авторның үз рәсемнәре белән бизәлгән китап "Бердәмлек" газетасы редакторы Рәфгать Әһлиуллин катнашы һәм тырышлыгы белән дөнья күрә. Димитровград (Мәләкәс) шәһәре дә шагыйрь иҗатына битараф калмый: «Ике кояш» дип аталган күләмле җыентыгын укучыларга бүләк итә. Шул уңайдан Татарстаннан, Ульяннан һәм башка



*«Бердәмлек» газетасы баш мөхәррире Рәфгать Әһлиуллин һәм «Идел» ансамбле Сәгыйровларда кунакта*

төбәкләрдән мәртәбәле кунаклар чакырылып, Самарның Металлурглар Мәдәният сараенда иҗат кичәсе уздырыла.

Күренекле татар шагыйре һәм рәссам Гакыйль Сәгыйровны берҗюлы өч төбәктә – Татарстан Республикасында, Самар һәм Ульяновск өлкәләрендә яшәүчеләр үзләренең якташлары, дип санаййлар. Гакыйль бит әтисенең туган ягында - Татарстанның Нурлат районы Әхмәт авылында туган, башлангыч белемне дә шунда алган. Әтисе Шәрифулла аганың сугышта һәлак булуы турында хәбәр килгәч, алар әнисе һәм әнесе белән Хәбибҗамал апаның туган ягына – Самар өлкәсе Кошки районы Иске Фәйзулла авылына күченәләр. Биредә аның яшүсмер чагы үтә, умыртка сөягенә ясалган уңышсыз операциядән соң бернинди хәрәкәтсез түшәктә генә ятып торырга дучар була. Нәкъ Иске Фәйзуллада яшәгән чорында ул күпчелек шигырьләрен яза, рәсемнәрен ясый, чын шагыйрь һәм рәссам буларак җитлегә.

Рәсем сәнгатендәге уңышлары өчен Г. Сәгыйров 1999 елда Халыкара «Филантроп» оешмасы бүләгенәлаекбула.Мөмкинлекләре чикләнгәннәргә ярдәм күрсәтү оешмасы игълан иткән бәйгедә (анда дөньяның 62 төбәгеннән бер мең инвалид катнаша) Г. Сәгыйров график рәсемнәре белән җиңү яулый. 1998 елда, шагыйрьнең 60 еллык юбилеена туры китереп, Самар өлкәсендә әле генә булдырылган **"Вөҗданлылык" бүләге тапшырыла.** Бүләкне тапшырганда Самар драма академия театры артисткасы, СССРның халык артисткасы Вера Ершова, каһарман якташыбыз алдына тезләнеп, башын ия. Аның лауреат турында сөйләгән сүзләрен зал алкышлап каршы ала.

Гомумән, Самарда да, Иске Фәйзуллада да аның юбилейларына карата иҗат кичәләре даими оештырылып тора иде. Гакыйль Сәгыйровның алтмыш, алтмыш

биш, җитмеш еллык юбилейларын өч төбәк – Татарстан Республикасы, Самар, Ульяновск өлкәләре вәкилләре Димитровградның “Восход” Мәдәният сараенда уткәреп килделәр. Сәламәтлеге шәптән булмаса да, шагыйрь юбилейларның барысында да үзе катнаша һәм аны хөрмәтләп килгән публика алдында чыгыш ясарга, төпле фикерләрен әйтергә кыенсынмый иде.

таралып килүче колхозлар, эшсезлек турында кайгырганы, бу халәттән чыгу юлларын күрсәтеп сөйләгәннәре хәтердә калган. Соңрак, бергәләшеп чәйләр эчкәч, яңа кешеләргә ияләшеп киткәч, яшь кызларыбызга шаяртыбрак дәшә башлады, шигырьләрен укып күрсәтте... Моның белән нәрсә әйтәсем килә: Гакыйль - язучы-журналист, шагыйрь, рәссам, сәясәтче генә түгел, дөнья матур-



Хәбибҗамал апа улы белән

“Бердәмлек” әле Самарның Галактионовский урамында урнашкан чагында ул редакциягә үзе дә килеп чыккан иде. 1994 – 1995 еллар булгандыр бу. Редакциянең биек дүртенче катына аны туганнан туган энеләре - Ринат белән Марат күтәреп алып менделәр. Бала кебек, одеалга әйбәтләп төрелгән гәүдәсен инвалид креслосына утыртып, өс киемнәрен төзәткәләп бетергәч кенә, редакция коллективы каршына чыгардылар. Аның йөзе мескен гарип кешенеке түгел иде - күзләре тирән һәм уйчан, карашы горур, әкрен, ләкин төпле сөйләм... Аның акрын тавышын ишетү өчен, редакция хезмәткәрләренә аңа якынрак елышырга туры килде. Бернинди зарлану сүзе ишетмәдек. Гакыйль Сәгыйров илдәге сәясәт, лыгын күрә белүче зыялы ир дә иде.

Әйе, Рәфгать Әһлиуллин белән Гакыйль Сәгыйров бик зур дуслар иде. Даими күрешеп, хатлар алышып, телефон аша серләшеп яшиләр иде. Рәфгать Нәбиуллловичның кайнап торган энергиясе Гакыйль Сәгыйровның популярлыгын арттырды, инвалид кешегә тиешле хөрмәт һәм ярдәм алырга булышты. Гакыйль Сәгыйров вафат булгач, аның истәлеген саклауны да редакторыбыз үз өстенә йөкләде. Шулай, 2015 елда «Гакыйль Сәгыйров. Үзе турында һәм барысы да аның турында” дип аталган китап дөнья күрде. Анда Гакыйль Сәгыйровның яшүсмер чагындагы хатирәләре, берничә хикәясе һәм “Бердәмлек” газетасында аның турында басылып чыккан күп санлы мәкаләләре тупланган. Бу китап басылып чыккач, Рәфгать Нәбиуллович өлкә районнарына йөреп, презентацияләр уздырды һәм китапханәләргә өләште. Кызыксынган кеше бу китапны табып укый ала.

Әйе, гомерләр уза... Менә инде Гакыйль Сәгыйров та, аны күреп белгән кешеләр дә дөньядан берәмберәм китеп баралар - Рифкать Фәретдинов, Рәфгать Әһлиуллин, Идеал Галәветдинов, Илгиз Колючев, Фәния Шәфигуллина... Хәтта Иске Җүрәйдә Сәгыйровлар яшәгән йорт та юк инде хәзер. Ике ел элек музей салабыз, дип, тузган өен иштеләр дә әле һаман яңасын төзү эшләренә тотынганнары юк. Сәбәбен әйтә алмыйбыз, «Прогресс-В» төзү компаниясе алынган иде моңа. Ә бит Сәгыйровлар өен саклап калырга кирәк булуы турында әле 2002 елның 5 январенда “Бердәмлек” хәбәрчесе Руфия Низаметдинова “Ул яшәгән йорт таралмасын иде”, дип язып чыккан иде.

Шагыйрь 2009 елда, кызу июньнең 29нда вафат булып, бер ел узгач, мәрхүм Рәфгать Әһлиуллин



Соңгы фотосы

да бу мәсьәләне күтәрде: ”Гакыйль Сәгыйров, әнисе Хәбибҗамал апа 1934 елда төзелгән бу өйдә Димитровградка, энесе Наил янына күчеп киткәнче яшәделәр. Шул чакта ук без «Бердәмлек»тә шагыйрьнең ятим калган өен саклап калу, музеен ачу мәсьәләсен күтәреп чыккан идек. Тәкъдимне хуплаучылар табылса да, бу изге

эшне башлап, артыннан йөрергә теләүчеләр табылмады, эш хәл ителмичә, гел артка кичектерелә торды. Бу турыда шагыйрьнең 60, 65, 70 еллык юбилейларын үткәргәндә дә күп сөйләнде, эшлекле тәкъдимнәр дә әйтелде. Нурлаттан атаклы «Зюзеев-нефть» ширкәтенең генераль директоры Шамил әфәнде Яһудин (аның әтисе Габделхәй ага тумышы буенча шушы Иске Фәйзулла авылыннан) берничә тапкыр очрашып сөйләшү вакытында мәсьәләнең зур әһәмияткә ия булуын аңлап, кирәкле матди ярдәм күрсәтергә дә вәгъдә иткән иде. Бәлки, ул сүзендә торган да булыр иде. Тик без үзебез, ваемсызлык күрсәтеп, эшләнәсе эшләрнең күләмен билгеләүне, кирәкле смета-проект кәгазьләрен әзерләүне гел артка чигәрә килдек. Хәер, акчасыз, файдасы булмаган эшкә кем алынсын инде?"

...Менә шулай Гакыйль Сәгыйровсыз 14 ел гомер дә үтеп киткән инде. Ә музей булдыру эше һаман тоткарлана. Кайберәүләр ул авыл бетә инде, биредә музей ачу - акча туздыру гына, диләр. Теләсәң, бу проблеманы да чишеп була. Мисал итеп Каюм Насыйриның Олы Ачасыр авылында урнашкан музеен китерергә була. Аннан 7 километр ераклыкта булган туган авылы Олы Шырдан бик кечкенә булганлыктан, анда Каюм Насыйри үзе казыган кое гына калган, ә өен Олы Ачасырга күчереп салганнар һәм анда Каюм Насыйри исемендәге архитектура һәм этнография комплексы барлыкка килгән. Туристларның иге-чиге юк! Димәк, Кошки район үзәгендә дә шундый ук комплекс төзергә мөмкиндер бит?! Моның өчен махсус фонд оештыру, исәп-хисабын ачу гына кирәк. Акча булса, барысын да уңай хәл итеп булыр. Бу фикерләрне Самар өлкәсе һәм шәһәренең татар милли-мәдәни автономияләре җитәкчеләре дә хуплап, тормышка ашыру өчен, бөтен көчләрен куячакларын белдергәннәр иде. Татарстан Республикасында да бу башлангычны яклаучылар табылачагына ышаныч зур. Гакыйль Сәгыйров моңа бик тә лаеклы. Бу уңайдан танылган татар язучысы, публицисты Фәнзаман Батталның Гакыйль Сәгыйров турында әйткән фикерләре игътибарга лаек:

– Әйе, Гакыйль Сәгыйров чынчынлап Зур шагыйрь иде. 1994 елда Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшләгәндә, мин аның "Кабатланмас моң" дигән китабын редакцияләү бәхетенә ирештем. Аның китабы белән параллель рәвештә икенче бер "халык шагыйре"нең китабын да редакцияләргә туры килде. Шунда мин: "Менә бит аларның кайсысы Халык шагыйре!" - дип, бөтен редакторлар алдында Гакыйльнең кулъязмасын күтәреп селтәп, соклanудан кычкырып җибәргән идем.

Ул чакта ук халкыбызның Олы шагыйре иде ул. Тукай премиясенә дә шул чакта ук лаек иде! Булалмады. Чөнки андый дәрәҗәләр хәзер үзе соранып йөргәннәргә генә бирелә. Самарлыларга шуны әйтәсем килә: Зур шагыйрьләребезнең берсе - сездә! Горурланып яшәгез, исемен дә, иҗатын да югалтмагыз!»



*Гакыйль Сәгыйров каберенә таш куела*


*Гакыйльне вертолетта дәваларга алып китәләр*

Бу сүзләр васыять булып яңгырый түгелме? Шундый ук бәяләмәләрне үз вакытында Гакыйль Сәгыйровның күпкырлы иҗатына Айдар Хәлим, Рөстәм Мингалим кебек танылган шагыйрьләр дә, Гариф Ахунов, Фоат Галимуллин кебек күренекле язучылар да биргәннәр иде.

Яшьләр безнең шушы батыр шагыйребезне, тиңсез рәссамыбызны онытып бетергәнче, музей төзү эшләрен кузгатырга кирәк. Без эшләп калдырмасак, киләсе буын кешеләре моңа алынмас.

**(Рәфгать Әһлиуллинның "Гакыйль Сәгыйров. Үзе турында һәм барысы да аның турында" китабындагы материалларга таянып язылды).**

# И ЖИЗНЬ ПРОЖИТЬ, И ПОЛЕ ПЕРЕЙТИ

***Заголовок данной статьи придумал ее герой, сместив акценты в пословице – «Жизнь прожить – не поле перейти». Сделал он это, видимо, с учетом своей любимой фразы – «Жизнь удалась...». И ведь действительно удалась! В начале весны текущего года известный ульяновский журналист И.З. Сайфиев отметил свое 75-летие. Даты бывают и повесомее, но вызывает уважение и преодоление с запасом уровня 0,7 векового юбилея. За многие годы работы в ведущих газетах области ему пришлось перемерить ногами не одно поле в хозяйствах подшефных районов. То были поля жатвы, однако доставались и поля битвы, когда приходилось отстаивать правду и не идти против совести. Поэтому к Иреку Завдатовичу имеет отношение и другое известное словосочетание – «Это сладкое слово – свобода!», тем более что всем известен смысл имени Ирек. Наш герой написал несколько книг, в том числе «Мечети Самарского края», стал лауреатом литературной премии имени Г. Кандалыя, а также отцом трех журналистов, которые занимаются любимым делом в Самаре и Ульяновске.***

***Рашид Шакиров***



Родился Ирек эфенди 5 марта 1948 года в селе Туйметкино Первомайского района ТАССР (ныне – Черемшанского района РТ) четвертым сыном в семье сельских интеллигентов. Ее глава – Сайфиев (Сайфетдинов) Завдат Рауфович по образованию был агрономом, получившим специальность в Самаркандском сельскохозяйственном техникуме. Ему одному из первых присвоили звание «Заслуженный



*Отец Завдат Сайфиев*



*Хава, мама Ирека Завдатовича*

агроном Татарской АССР». Среди других наград агронома ордена Трудового Красного Знамени, «Знак Почета» и многие медали. В годы Великой Отечественной войны он не попал на фронт из-за зрения и был направлен на Челябинский тракторный завод, который 6 октября 1941 года переименовали в «Кировский завод Наркомата танковой промышленности в городе Челябинске», а неофициально называли «Танкоградом».

При подведении итогов научного форума академик Б.Д. Греков изложил главный вывод сессии: нынешние татары по своему происхождению не имеют никакого отношения к монголам, являясь потомками булгар. Таким образом, можно говорить о том, что именно Латиф Заляй сделал первую удачную попытку использования языкового материала для выяснения этнической истории народа. Правда, вопрос этногенеза татар дебатируется до сих пор, поскольку ныне существуют три теории появления наших соплеменников: тюрко-татарская, булгаро-татарская и татаро-монгольская. Усилиями Заляя и его сторонников наиболее признанной в течение продолжительного времени считалась булгаро-татарская теория, но потом большее признание получила тюрко-татарская.



*Сотрудники сектора языка ИЯЛИ, 1953 год. Заляй – 3-й справа*

А доцента Л.З. Залялетдинова, ставшего после названной сессии и дебатов в научных журналах более известным, начали активно приглашать на различные научные мероприятия. Так, на конференции тюркских диалектологов, состоявшейся в 1956 году в Баку, он выступил с докладом на тему «Опорный диалект в образовании татарского языка». Со временем его имя стало известно и заграничным языковедам, проживавшим в Болгарии, Румынии, Чехословакии и других странах.

Основным своим трудом Заляй ага считал двухтомную рукопись по исследованию среднего диалекта татарского языка. Ее он положил в основу докторской диссертации «Татар теленең урта



*Среди писаталей*

диалекты», которую защитил в 1954 году в московском Институте языкознания АН СССР, став первым в стране доктором филологических наук по татарскому языку. Член-корреспондент союзной академии наук, известный тюрколог, профессор Н.К. Дмитриев дал следующую оценку этой диссертации: «...перед нами первый грандиозный опыт, которого татарская наука еще не знала, и в этот памятник, подобный башне Сююмбике, автор вложил всю свою молодость и весь огонь творческих и смелых исканий». А его коллега, академик Б.А. Серебренников считал, что любой будущий историк татарского языка не пройдет мимо сей работы Залялетдинова.

Среди других заметных его трудов следует отметить такие книги: «Татар теленең орфоэпик нигезләре» («Основы орфоэпии татарского языка», 1953) – первая серьезная работа по культуре татарской речи, «Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар» («Материалы по исторической фонетике татарского языка», 1954), «Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәр» («Фразеология, пословицы и поговорки татарского языка», 1957, в соавторстве). В 1960 году профессор Л. Заляй сдал в издательство Казанского университета рукопись книги «Татар теленең тарихи морфологиясе буенча очерклар» («Очерки по исторической морфологии татарского языка»). Но она тогда не была издана, и лишь в 2000 году ее опубликовал Институт языка, литературы и искусства АН РТ.

Перечень приведенных публикаций (а еще были и статьи) позволяет понять, почему Патиф эфенди признан основоположником ряда отраслей татарского языкознания (история литературного языка, историческая грамматика), а не только одной диалектологии. В общем списке его научных трудов и статей значатся 123 названия, в том числе 32 книги и публикации в сборниках, 54 статьи в журналах и 37 – в газетах.

Наш герой активно занимался и подготовкой новых научных кадров в области лингвистики, щедро делясь знаниями со своими и сторонними аспирантами. Только под его непосредственным руководством около двух десятков молодых специалистов защитили кандидатские диссертации. А четыре ученика Л. Заляя стали докторами филологических наук (М.З. Закиев, Ф.А. Ганиев, В.Х. Хаков и Г.Х. Ахунзянов). Еще с 1945 года он начал рекомендовать в качестве тем диссертационных исследований говоры отдельных территориальных групп татарского народа. Так были исследованы говоры уральских, сергачских, учалинских, касимовских, каринско-глазовских, среднеуральских и других групп татар.

Поскольку в 40–60-е годы Латиф эфенди был единственным специалистом по диалектологии, истории языка и исторической грамматике татарского языка, то к нему обращались за помощью не только казанские студенты и аспиранты, но и из других городов страны. Вот письмо аспирантки Восточного факультета Ленинградского университета Л.Т. Махмутовой: «Будучи студенткой, я много слышала о Вас как о специалисте в области татарского языка и его диалектов от моих уважаемых учителей: проф. Н.К. Дмитриева и проф. С.Е. Малова (заведующие кафедрой тюркской филологии ЛГУ в 1944–1949 гг. – Прим. Р.Ш.). Кроме того, я знакома с рядом Ваших работ, принесших мне большую пользу. Поэтому я хотела бы обратиться именно к Вам с убедительной просьбой не отказать мне, дать ряд ответов и указаний по интересующим меня вопросам. Я специализируюсь в области татарского языка, который для меня является родным. Тема моей кандидатской диссертации – «Мишарский диалект татарского языка».

Избирая тему для кандидатской диссертации, я руководствовалась известным указанием проф. Н.К. Дмитриева о степени изученности мишарского диалекта, о важности изучения его для истории татарского языка, для научной разработки татарского литературного языка. Однако я оторвана от Казани, научного центра татарского языковедения... В каком на-

правлении ведется исследование мишарского диалекта в настоящее время? Какие мишарские районы наиболее изучены и какие – наименее? В какие районы следовало бы поехать для сбора материалов? Хотелось бы услышать ваши соображения по поводу выбора мною темы».

После ответа Залялетдинова она прислала второе письмо: «Ваши рекомендации держу перед глазами и выберу пензенских или касимовских татар. Уважающая Вас Махмутова». Впоследствии Ляйля Тагировна, бывшая, кстати, с двухгодовалого возраста до 17 лет нашей землячкой, защитила кандидатскую диссертацию на тему «Особенности касимовского говора татарского языка» и более 30 лет работала в ИЯЛИ, приняв от Л. Заляя в 1961 году руководство сектором.

Теперь упомянем обращение к нему студентки того же факультета ЛГУ: «Я оканчиваю тюркское отделение. Занимаюсь своим родным татарским языком. По окончании III курса ездила к татарам Белебеевского района Башкирии. Собрала материал по фольклору. По окончании IV курса ездила к татарам Стерлибашевского района. Записала фонетические особенности говора татарского района и небольшой фольклорный материал, где можно проследить эти особенности. Руководителем моим на практике была ваша книга «Татарская диалектология». Темой моей дипломной работы является «Фонетические особенности говора деревни Стерлибашево», отнесла я этот говор по фонетическим особенностям к среднему диалекту. Сергей Ефимович Малов, мой руководитель, одобрил тему и предупредил, что литературы, соответствующей моей работе, очень мало, он не специалист по диалектологии… Не сможете ли Вы мне помочь чем-нибудь в моей работе? С уважением к Вам Зухра Валиуллина, 17 ноября 1948 г.». Вскоре пришло второе ее послание: «Латиф абый! Большое Вам спасибо за помощь…Мне очень надо побывать в Казани, так как имеющиеся там материалы и Ваши советы принесут мне большую пользу. Если не возражаете, я бы выслала Вам план моей дипломной работы».



***Участники 2-го регионального совещания по диалектологии тюркских народов, Казань, 1958 год. Заляй – 2-й справа в нижнем ряду***

Эти письма подтверждают высказывания давно знавших Заляя людей о том, что он был очень простым и доступным в общении не только со студентами. Любимых своих учеников Латиф абый звал не их именам, а по именам дедов, «извлекая» их из фамилий. Так, Мирфатыха Закиева он называл Заки, Анвара Афлатунова – Афлатун, Вахита Хакова – Хак, Шамиля Бохарова – Бохар, Юныса Аминева – Амин, Гумара Саттарова – Саттар. Как отмечал позже перечисленный последним Гумар Фаизович (1932–2020), многие коллеги так и продолжали обращаться к нему, хотя он был уже доктором филологических наук, заслуженным деятелем науки РФ и ТАССР, лауреатом Государственной премии РТ.

Погруженность нашего героя в любимую науку, накопленный им богатый фактический материал, подвергнутый анализу, который приводил к интересным (порой новаторским) обобщениям и выводам, в сочетании с ораторским



***Во время беседы с китайскими языковедами, Казань, 1958 год. Заляй – крайний справа***

умением и некоторыми нестандартными ходами преподавателя позволяли ему легко «держать» на занятиях студенческую аудиторию. В лекциях Л. Заляя находилось место науке и юмору, добытым им самим фактам и примерам, остроумным фразам.

Приведем выдержки из воспоминаний его бывших студентов: «Мне довелось слушать увлекательные лекции доктора наук Заляя в КГУ», «Часами слушали его, глядя в рот», «На 2-м и 3-м году обучения нам читал очень интересные лекции», «Открытая нам ученым Заляем таинственная жизнь языка до сих пор в памяти, хотя за прошедшее с тех пор время пришлось прочитать много специальной литературы по диалектологии», «На лекциях заслушивалась его изложением темы, и тогда он говорил: «А вот это надо записать в тетрадь». Упомянутого студента Саттарова наш лектор так «зацепил» примерами по ономастике (раздел лексикологии, изучающий любые имена собственные), что тот со временем вырос во всемирно известного тюрколога-ономаста.

Студенты уважали Залялетдинова также за скромность и понимание их проблем. Сельчан, спешивших в конце недели домой, он мог отпустить с занятий. На экзамене спрашивал: «Какую оценку поставить?». И выставлял «хор.», чтобы была стипендия, а просившим незаслуженное «отл.» обоснованно отказывал. Лучших из студентов после защиты диплома приглашал к себе на работу в сектор ИЯЛИ.

Что касается других его нестандартных ходов, то они описаны в книге народного писателя Республики Татарстан Р. Батуллы «Тузга язмаган хәлләр» («Курьезы»). Так, заходя в аудиторию на первое семинарское занятие, Латиф-ага спрашивал: «Есть ли мишари?» Лишь несколько человек поднимали руку. «Оказывается, настоящих ребят мало!» – реагировал педагог. И у студентов возникал немой или заданный тут же вопрос – почему такой вывод? Этого и добивался Заляй, чтобы, начав с мишарского диалекта, который сохранил больше древних черт по сравнению со средним диалектом и в меньшей степени был подвержен внешним влияниям, завести речь и о других диалектах татарского языка.

Иногда Латиф эфенди позволял студентам «уговорить» себя на исполнение родных песен прямо на занятиях. Он обладал красивым голосом, и слушать его было одно удовольствие. Но, думается, шел на это педагог потому, что словарный ряд песни органично встраивался в ткань проводимого семинара.

Отметим и его нестандартные действия на грани фола. Когда пришла пора мини-юбок, Заляй объявил им войну. Он вызывал студентку к доске и давал задание что-то на ней написать, говоря при этом: «Выше пиши, чтобы всем было видно!» Та тянулась к верхнему краю доски, и всем действительно становилось все видно. Вскоре модницы стали являться на занятия Залялетдинова в миди. А вот следующему его действу объяснение и оправдание найти не удается. Дело в том, что, придя на лекцию, Заляй ага садился за стол, через некоторое время доставал папиросы-спички и, пуская густой дым, начинал тихо говорить по намеченной теме. Почему-то администрация факультета с этим мирилась.

Превращение нашего героя в видного ученого-лингвиста не ослабило его интереса к изучению языка татарской художественной литературы. Проявляя себя компетентным критиком, который тонко чувствует слово и ратует за чистоту литературного языка, он продолжал публиковать статьи теоретического плана и о творчестве литераторов (К. Насыри, Ф. Амирхана, Ш. Камала, С. Хакима, К. Наджми, Н. Исанбета, А. Шамова, М. Максуда, Ш. Мударриса и др.), рецензии на их произведения и на театральные премьеры. В итоге из-под его пера вышло более 60 таких статей и рецензий. Нельзя не отметить Заляя ага и как автора многих учебников и учебных пособий для школ и вузов.

Еще в самарский период жизни он стал семьянином и отцом Анвара. Но первая юношеская любовь к дочери Ситдыка хазрата оказалась настолько сильной, что Латиф решился на разрыв брака и женился на ушедшей от мужа Рушание Ситдыковне Шамгуновой – представительнице династии учителей, занимавшихся просветительством с 20-х годов XIX века на территории Симбирской и Самарской гу-



*С женой, 1931 год*

берний, ТАССР и других регионов страны. Благодаря членам этой династии в 4-м и 6-м поколениях (Л.Р. Лукиных и Д.Б. Башкировой) удалось пополнить багаж знаний о нашем герое и его родни, а также фоторяд, за что им большое спасибо.

По сведениям Лилии Ризаевны, после переезда Заляев в Казань Анвар учился в татарской школе и писал стихи на родном языке. В 1942 году он добровольцем ушел на фронт и пропал без вести. Совместных детей у Латифа ага и Раушан ханум не было, и после войны они взяли на воспитание семилетнюю Венеру – оставшуюся без отца-фронтовика племянницу Раушан апа. Заляй очень любил приемную дочь и называл ее в детстве «чемчук», «чемчушка». Видимо, это новообразование маститого филолога от выражения «чеметеп

алырлык кына» («очень маленькая»).



*С племянницей и приемной дочерью*

Венера не расставалась с приемными родителями до их кончины. Она, выпускница университета, ставшая специалистом по электронной вычислительной технике, и поныне здравствует (81 год), общаясь с двумя успешными сыновьями и тремя внуками. Последние 10 лет у Заляев в Казани жила и остабика Марзия – жена Ситдыка хазрата, арестованного в Самаре в 1937 году и вскоре расстрелянного. Латиф абый называл тещу уважительно – «абыстай» и хорошо к ней относился.

В столице ТАССР семья нашего героя располагалась в доме на улице Маяковского (его еще называют «Домом ученых»), и дверь их квартиры была широко открыта для родственников, соратников и студентов, которых здесь всегда привечали и угощали. Частенько Заляи звали в гости и проживавшую в этом же доме сотрудницу сектора языкознания ИЯЛИ Нагиму ханум. По ее наблюдениям, жили супруги очень дружно. Жена старательно ухаживала за Латифом абый, создавала ему все условия для работы и вкусно готовила. А сам Заляй ага запомнился коллеге Нагиме как удивительно обаятельный, с корректной сочной речью работящий ученый, который с уважением относился к людям.

Приведем и наблюдения племянницы жены Заляя – упомянутой уже Лилии Ризаевны Лукиных (Шамгуновой): «Латиф абый был разносторонне образованным и продолжал учиться всю жизнь. Учебу он считал главным делом человека, поэтому помогал всем юным родственникам (как своим, так и супруги) получить образование и радовался их успехам. Я часто посещала Рушанию апа и Латифа абый, беседовала с ними, расспрашивала о прошлом и родственных связях. Была свидетелем разговоров с разными интересными людьми. Поэтому пришла к выводу, что главной любовью профессора являлся татарский народ, его язык, культура, традиции и деятели искусств, возвышающие соплеменников.



*С сыном (в тюбетейке), женой (сидит рядом) и ее родственниками, август 1941 года*

Ближайшим его другом считался художник Баки ага Урманче. Они были примерно одного возраста. Хотя тогда я не все понимала, но слышала, как горячо они говорили об истории и судьбах татарского народа. Другой задушевный приятель – композитор Салих Сайдашев. Они жили недалеко друг от друга. Салих ага часто посещал дядю. Я несколько раз наблюдала, как они проводили время. Под аккомпанемент композитора на пианино вдвоем вполголоса пели народные песни и арии из музыкальных произведений Сайдашева. Латиф абый рассказывал, что в молодости обладал мощным голосом. Он вставал на берегу реки в родной деревне и затягивал грустные мелодии. Даже на другом берегу собирался народ, чтобы послушать. Его любовь к родной музыке не знала предела. Когда приезжали наши старшие родственники из Средней Азии, к абый приходили известные певцы Рашид Вагапов, Мунира Булатова, Гульсум Сулейманова, Усман Альмеев и давали настоящие концерты. Дядя очень высоко отзывался о молодых тогда Ильгаме Шакирове и Альфие Авзаловой.



*С женой, 60-е годы*

Завсегдатаями в его квартире были и выдающиеся актеры татарского театра: Халил Абжалилов, Габдулла Шамуков, Камал III, Гульсум Камская, Гульсум Болгарская и супруги Салимжановы (родители будущего известного режиссера Марселя Салимжанова), да и другие мастера сцены. Посещали его и многие писатели.

Профессор никогда не рвался делать карьеру, никому не льстил, не юлил и не угодничал. О таких людях в народе говорят: «правдолюб и правдоруб». Мог высказать свое мнение невзирая на лица».

Да, прямота высказываний ему была присуща. Узнав, что у двоюродного племянника И. Сайфиева не приняли документы для поступления на отделение журналистики КГУ из-за отсутствия стажа работы, он не стал утешать того по-родственному, ругать вузовских бюрократов и обещать посодействовать – все-таки не последний человек в научной и литературной среде. Латиф абы сказал без обиняков: «Это хорошо, что тебя «завернули», будет время проверить себя. Поработай в газете, где ты начал печататься, а потом уж и сделаешь свой выбор». Юноша так и поступил, добившись со временем успехов на журналистском поприще и признания коллег. А при подготовке сей статьи Ирек Завдатович оказал помощь ее автору информацией о Л. Заляе и фотографиями.

Наш герой тяжело перенес кончину Раушан апа и буквально не находил себе места. На завершающем этапе жизни он серьезно заболел и в 1962 году перенес ампутационную операцию на правой ноге. Через некоторое время пришлось оперировать и вторую ногу, так как кровь не проходила в конечность и началась гангрена. Хирургические вмешательства Латиф эфенди выдержал, но очень похудел и лишился возможности выходить из дома.



***Пригласительный билет на 60-летие Заляя***

Но он не обнулил свою активность на научной ниве, несмотря на тяжелейшее положение со здоровьем и бытом. На заседания специализированного совета по защите кандидатских диссертаций Заляя ага привозили на такси, а внутри учебного корпуса несли на стуле до нужной аудитории на пятом этаже. В феврале 1965 года он написал письмо В. Хакову, издавшему свою книгу «Введение в стилистику татарского языка». Невозможно не дать выдержки из этого послания: «С большой и нужной работы начал ты свое литературное дело. Замечательная работа, ну очень хороша! Мастерство танцора оценивают по первому прыжку. Этот труд показывает стиль твоего танца в зале науки. И глядя на это, мы можем предвидеть твои будущие успехи. Тему стилистики надо развивать до докторской диссертации… Если нужны советы, я всегда к твоим услугам. Но работу над диссертацией надо начинать сейчас. Давай, трудись! Давай, танцуй смело!». Это письмо придало Хаку сил, и он справился с диссертацией, защитив ее в 1971 году. Позже доктор наук В.Х. Хаков (1926–2008) стал профессором, заслуженным деятелем науки ТАССР и лауреатом Госпремии РТ.

По мнению упомянутого выше Саттара, хоть и тяжело болел Заляй ага, но не потерял остроумия, умения пошутить и присущей татарам стойкости. Наш главный персонаж продолжал трудиться над созданием исторического синтаксиса татарского языка, но завершить работу не успел. Он умер 1 августа 1966 года в деревне Кзыл-Чишма Черемшанского района ТАССР и похоронен на татарском кладбище в Казани. На двоих с женой у них одно место упокоения, ограниченное оградой, и один могильный камень.

Коллеги-языковеды его не забывают, откликаясь на юбилейные даты Л.З. Залялетдинова статьями в прессе и научных сборниках, конференциями и совещаниями диалектологов. Помнят о нем и в Татарском Урайкино, но улицу в честь земляка в селе не назвали, хотя их аж 15.

И еще об улицах. В конце минувшего века в масс-медиа Татарстана появлялась публикация, содержавшая предложение о переименовании ул. Маяковского в Казани, на которой жил наш герой, в ул. Заляя. Но, видимо, неизбалованному наградами первому доктору наук – филологу по татарскому языку и ныне тяжело тягаться с главным бунтарем и классиком русской литературы. Тогда, может быть, сделать явью «Заляевские чтения» или «Заляйфест»?

В год 100-летия Латифа эфенди профессор Г. Саттаров назвал своего учителя и наставника главным нашим языковедом, который основал и вырастил разветвленный легендарный сад лингвистов. Судя по нынешним публикациям, такая оценка сохраняется в научном обществе. Что же – пожелаем саду цвесть и давать плоды!

*Яшьләр нигә иртә китә икән?*
*Туар ал таңнарны калдырып.*
*Бала, якыннарын ташлап*
*китә,*
*Йөрәкләргә сагыш салдырып...*

*Нигә икән өзелә яшь гомерләр?*
*Яшәргә дә иде бит әле, яшәргә!*
*Җавап таба алмый, өзгәләнә*
*күңелләр,*
*Үлем һәр мизгелдә йөри*
*янәшә...*

*Ничек кенә сыкрамасын*
*җаннар,*
*Узмыш юк шул язган*
*язмыштан.*
*Алардан башка ата хәзер*
*безнең таңнар,*
*Урыннары, Раббым, булсын*
*оҗмахта...*

# МИЛЛИ ХӘРӘКӘТ КҮГЕНДӘ ЯКТЫ ЙОЛДЫЗ БУЛЫП ЯНДЫ УЛ!



**Самар татар милли хәрәкәте активисты, өлкә «Туган тел» татар җәмгыяте әгъзасы, «Ялкынлы яшьлек» ансамбле җитәкчесе Альбина Харис кызы Мәхмүтованың хастаханәдә операциядән соң үлүе турындагы хәбәрне ишеткәч, күңелем моңсулык белән тулып, шушы шигъри юлларны иҗат иткән идем.**

**Миләүшә Газимова**

«Альбина вафат булды...» сүзләрен колак ишетсә дә, йөрәкнең бу тетрәндергеч чынбарлыкка һич кенә дә ышанасы килмәде. «Ничек инде алай?», «Болай булырга тиеш түгел бит!» – җавабы булмаган шундый сораулар чолгап алды.

Әйе, Аллаһы Тәгалә күпме гомер биргән икән, үлем фәрештәсе, яшең ничә, балаларың кечкенәме, башкарасы эшләрең әле күпме, дип сорап та, көтеп тә тормый шул, үз вазифасын үти...

Менә Альбинага да бары тик 43 яшь кенә иде бит. Өч баласы – 22 яшьлек Фәрзәнә, 15 яшен тутырган Самат һәм әле бары тик 6 яшендәге Таһир ятим калды. Ә Альбинаның алга корып яшәгән планнары турында әйтеп торасы да юк. Өлкәбез буенча гына түгел, башка төбәкләрдә концертлар куеп йөрергә дә бик хыяллана иде ул.

Альбина Мәхмүтова Самар татар милли хәрәкәте күгендә якты йолдыз булып янды. Бер генә татар чарасы да аңардан һәм аның ире Фәрхәттән (берничә ел элек ул да бакыйлыкка күчте) башка узмады диярлек.

Татар халкы өчен җан атып, аның язмышын үзенекедәй кайгыртып яшәгән мондый шәхесләрне еш очратмыйсың. Үз милләтенә олуг һәм ихлас мәхәббәт аларның җан-тәненә генә түгел, канына сеңгән иде. Икесе дә, милли хәрәкәттә бик күп еллар хезмәт итеп, татар телен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятен саклап калу һәм үстерүгә гаять зур өлеш керттеләр. Халык мәхәббәтен яуладылар, татарлар арасында гына түгел, башка милләт вәкилләре һәм түрәләр алдында да зур абруй-хөрмәт казандылар.

Альбина Таҗикстан Республикасының Турсунзаде шәһәрендә туган. Бәләкәй чагында аның әти-әнисе ул вакыттагы Куйбышев, хәзерге Самар шәһәренә күчеп урнашкан.

Кыз кечкенәдән үк җыр-моңга мөкиббән булган. Шуңа күрә ул музыка мәктәбенә, Халидә ханым Вәлиева җитәкчелегендәге татар мәдәнияте түгәрәгенә йөргән. 1992 елдан алып (13 яшендә), 2000 елга кадәр «Ялкынлы яшьлек»тә җырлаган. Аннары,





озак тәнәфестән соң, 2019 елда анда кире кайткан.

Альбина Самарның социаль-педагогика көллиятен, аннары педагогика университетын кызыл дипломга тәмамлаган. Ул үзе белем алган көллияттә музыка укытучысы булып эшли иде.

«Ялкынлы яшьлек»кә нигез салган, аны озак еллар җитәкләгән Илгиз Кәлүчев вафат булганнан соң ансамбльне үз кулларына Альбина ханым Мәхмүтова алды һәм аңа лаеклы алмаш була алды. «Ялкынлы яшьлек»кә яңа сулыш өрде, диләр иде Альбина турында.

Былтыр март аенда мин, аның белән әңгәмә корып, «Сәлам» гәҗитәсенә ансамбльнең туган көненә багышланган мәкалә язган идем. «Сәхнәгә бер мәртәбә чыккан кеше аңардан башка яши алмый!» – диде миңа шунда Альбина.

Шул чакта үзе белән сөйләшеп утырганда аның тыйнаклыгына исем китте.

«Миләүшә, зинһар, минем фотомны гына куймагыз әле, барыбыз да бергә төшкәнне бастырыгыз. «Ялкынлы яшьлек»кә искиткеч шәхесләр җыелган бит. Барысына да өлгерәләр алар – эшлиләр дә, укыйлар да. Бик сәләтле, булдыклы кешеләр», – дип, үзе турында аз сөйләп, күбрәк башкаларны мактады ул.

Альбина Мәхмүтованың якыннары, хезмәттәшләре, фикердәшләре, күз яшьләрен тыя алмыйча, аның турында истәлекләре белән уртаклаштылар.

**Әнисенең бертуган сеңелесе Рәсимә Алюшева:**

«Альбинабыз кечкенәдән җырлый иде. Авылда әтиебез кунакка кайткан оныкларын бакчага чыгара да: «Кызым, син карлыган җый, улым, син – кура җиләген. Ә син, Альбина, җырла», – дия торган иде.

Аңа бу сәләт этисе Харистан күчкән булган, күрәсең. Ул җырлады да, музыка уен коралларында да оста уйнады.

Альбина әнисе Розага, аңа музыкаль белем алырга ярдәм иткәне өчен, бик рәхмәтле булды.

Апам, музыка мәктәбенә барып, укытучылардан бу өлкәдәге нечкәлекләр турында сораша иде.

Аннары инде өйдә пианинода уйнап утырган кызына: «Балам, менә монысын шулай эшләргә кирәк», – дип киңәшләрен бирә тора. Альбина исә: «Әни, син бит музыкада бернәрсә дә аңламыйм дигән идең!» – дип, аптырашка кала.

Инде көллиятне, аннан университетны тәмамлагач, Альбина серләшеп утырган чакларыбызда еш кына: «Апа, мин бит музыкаль белемне әнием ярдәмендә алдым», – дия иде.

Сеңелем ярдәмчеллеге, кешелеклелеге, игелеклеге белән аерылып торды. Мәктәптә укыганда сыйныфташларына да, көллияттә эшләгәндә хезмәттәшләренә дә, күршеләренә дә, гомумән, кешеләргә һәрвакыт ярдәм итеп яшәде. Кемгәдер – яхшы сүз, киңәш, кемгәдер эш белән гел булышты ул.

Аның белән булган бер хәл әле дә исемдә. Альбинаның студент чаклары. Имтиханга юл тота. Автобустан чыкканда бер хатын, таеп китеп, аягын сындырган.

Альбина узып баручы бер машинаны туктаткан да аны хастаханәгә илткән. Алай гына да түгел, әле туганнарына хәбәр итеп, аларның килүен көтеп тә утырган.

Имтиханга, әлбәттә, соңга калган. Икенче көнне бу хәл турында инде ишетеп белгән укытучысы: «Афәрин, Мәмедалиева, яхшы эш эшләгәнсең!» – дип мактаган.

Шулай, чит-ят кешеләрнең бәла-казасына да битараф кала алмады ул.

Бик тә актив иде инде. Аның студентлары һәрвакыт, төрледән-төрле конкурсларда катнашып, призлы урыннар яулап килделәр. Кайда гына катнаштырмады үзләрен. Хезмәтен бик яратып башкарды. Югары категорияле укытучы иде бит ул.

Сеңелемнең 40на багышланган мәҗлескә килгән педагогика көллияте мөдире: «Альбина Харисовнага алмаш таба алмыйм.






Хезмәттәшләре дә, укучылары да аны бик яраталар иде», – дип күңелсезләнеп сөйләде.

Өйләреннән кеше өзелмәде. Әле студентлары, әле «Ялкынлы яшьлек»тән кемдер килә. Мәш килеп утыралар, нәрсәдер язалар, нәрсәдер планлаштыралар.

Үз өстенә гаять күп эш алды Альбина. Ял итәргә бер секунд вакыты юк иде аның. Төп эше, өч бала, өй мәшәкатьләре, ял көннәрендә репитицияләр, милли чаралар, концертлар һәм башкасы, һәм башкасы… Көчен, сәламәтлеген бер генә дә жәлләмәде.

«Сеңелем, ансамбльне житәкләп, өстеңә тагын бер зур йөкләмә аласың бит инде», – дигән идем аңа. Ул шунда ук: «Апа, «Ялкынлы яшьлек» бит ул! Илгиз абый Кәлүчевнең баласы. Житәкләмәсәң, таркалырга мөмкин. Аны ничек тә саклап калырга кирәк», – дип җавап бирде.

Бу эш белән янып йөрде, аңа бөтен көчен, җанын, йөрәген бирде.

Балалары өчен өзелеп торды Альбина, гомерен кыз-улларына багышлады. Үзләренә тавыш күтәргәне булмады. Йомшаклык белән, яратып, назлап үстерде. Аларга да музыкаль белем бирергә тырышты.

Фәрзәнә музыка мәктәбен тәмамлады. Самат хәзер шулай ук анда укый.

Альбина ачулана да белми иде. Һәрвакыт барысын да гафу итте, үпкә тотмады, олыны – олы, кечене кече итеп яшәде.

«Мин белмим», – дигән сүзне кулланганы булмады. Барысына да алынды, тырышты, өйрәнде.

Кешене борчымады, бөтенесен дә үзе эшләргә тырышты.

Тыйнак, бик түземле, туган җанлы. Газиз балаларына – яхшы әни, иренә – асыл хатын, каенатакаенанасына миһербанлы килен булды.

Альбина белән бер-беребезгә бик якын идек. Сөйләшеп, серләшеп, киңәшеп яшәдек.

Әле хәзер дә: «Апа, көт, мин сиңа кунакка киләм», – дип шалтыратыр төсле. «Яктылык» мәктәбендә эшлим мин. Анда озаграк калырга тырышам, өйгә ашыкмыйм. Кайтып, үзең генә калгач, шундый авыр, Альбина шулкадәр сагындыра.

Күзен операция алдыннан Иске Кулаткыга әтисе ягыннан туганнары белән күрешергә барган иде. Бөтенесе бергә җыелып, аралашып утырганнар. Әйтерсең лә алар белән саубуллашып кайтты…

«Апа, 20 көннән чыгам. Концертыбыз булачак», – дип ятты ул хастаханәгә.

Чыга алмады шул… Йомшак күцелле, назлы сеңелебезнең чәчәктәй гомере бик иртә өзелде.

Альбинаны күпләр ярата иде. Аны соңгы юлга озатырга бихисап кеше җыелды.

Халык бик булышты. Татар җәмәгатьчелегенә, хәзрәтләребезгә, милли әйдаманнарыбызга, олуг кайгыбызны уртаклашкан, авыр чакта безгә ярдәм кулын сузган изге йөрәкле һәркемгә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре яусын».

### Кызы Фәрзәнә Мәхмүтова:

«Әниебез сабырлыкта һәм чыдамлыкта күпләргә үрнәк булырлык кеше иде.

Ул безнең һәр башлангычыбызны хуплап каршы алды, һәрнәрсәдә ярдәмен күрсәтте.

Уй-ниятләребезне тормышка ашыру мөмкинлеген бирә, тәҗрибәсе белән уртаклаша иде.

Ул бездә татар теленә карата мәхәббәт тәрбияләде. Кечкенәдән ана телендә яхшы сөйләшәбез. «Тел бетсә – милләт бетә», – дигән сүзләрне еш кабатлап торды.

Әниемнең: «Балаларым, сез – тормышта бер-берегезгә иң якын кешеләр. Һәрвакыт дус булып яшәгез, бер-берегезгә терәк һәм таяныч булыгыз», – дигәнен мәңге онытмам.

Газиз әниебез безне күп нәрсәгә өйрәтеп калдырды. Без, аңа бик рәхмәтле булып, аның үгет-нәсыйхәтләрен гомер буе үтәп яшәргә тырышырбыз, Аллаһы теләсә».



**Фәния Гыйләҗева,**
*«Яктылык» мәктәбе укытучысы:*

«Альбинаның вакытсыз вафат булуы барыбызның да йөрәкләрен тетрәндерде.

Аны мин, хезмәттәшем Рәсимә Алюшеваның апасының кызы буларак, 1998 елдан бирле белә идем. Ул чакта Альбина «Ягымлы яз» бәйгесендә җиңеп кайтты.

Сәхнәдәге чыгышын «Ялкынлы яшьлек» ансамбле концертында беренче мәртәбә күреп, осталыгына чиксез сокланган идем. Арабыздан нинди зур талант иясе китте!

Күндәм, артык күндәм иде шул Альбина. Беркемгә дә каршы килмичә, «юк», дия белмичә яшәде ул. Янәшәсендәге барлык кешеләрне якын күрде, киңәшләрен бирде, ярдәм кулын сузды.

Искиткеч милли җанлы шәхес!

Мәктәптә укыган вакытларында минем балаларымны Халыклар дуслыгы йортында узган чыршы бәйрәмнәреннән, Сабан туйларында үткәрелгән бәйгеләрдән калдырмады. Альбина апалары хастаханәдә ятканда ук улым да, кызым да аның өчен бик нык кайгырдылар.

Яхшы кеше турында күпме әйтсәң дә, аз булыр күк.

Ул кылган изгелекләр газиз өч баласының, матур булып үсеп җитеп, аякка басуларына ярдәм итсен, йа, Раббым!

Якты истәлеге күңелләребездә яшәсен».



**Шамилә Ибраһимова,**
*«Ялкынлы яшьлек» ансамбле җырчысы:*

«Мөлаем, көләч йөзле Альбинабыз истән чыкмый. Аның шулкадәр тырыш, талантлы, уңган, тәрбияле булуына исем китә иде.

Кешеләргә гел яхшылык кылырга омтылды ул. Башкаларны рәнҗетүдән курка иде.

Үтә дә тыйнак. Әле дә фотоларны карап утырабыз. Альбина гел читтәрәк баскан. Башкарган эшләре гаять зур, ә үзе гел күләгәдә калырга тырышты.

Аның хезмәт сөючәнлегенә хәйран калырлык иде. Кызым Алсу Беленова белән алар «Ялкынлы яшьлек» өчен күп эшләр башкардылар. Икәү бергә утырып, проектлар, планнар төзиләр иде.

Шундый дустын, фикердәшен, хезмәттәшен югалтканга Алсу да, бик кайгырып: «Әни, Альбинадан башка ничек булырга да белмим. Шундый зур хыялларыбыз, ниятләребез бар иде бит безнең», – ди.

Альбина, югары һөнәрмәнд, үз эшенең остасы буларак, ансамблебезнең дәрәҗәсен күтәрде. Бөтен яктан да килгән, гыйлемле. Безне, һәвәскәр җырчыларны, музыкаль грамотага өйрәтә иде.

«Ялкынлы яшьлек»не җитәкләгәч, Альбина безне бер-беребез белән тагын да якынайтты, берләштерде, бер гаиләдәй булдык.



Аның вафатыннан соң канатларыбыз сынды. Әле дә кайгыдан айный алмыйбыз.

Альбинадан башка ансамбль ятим булып калды».

**Нурания Абзалова,**
*Татар Байтуганы авылындагы «Әлифба» авторы Сәләй Вагыйзов музей-йортының мөдире:*

«Альбинаны берничә тапкыр күргәнем булды. Бервакыт ул безнең авылга да килгән иде әле. Ул чакта үзе белән алай тыгыз аралашып булмады.

Ә менә август аенда Бөтендөнья татар конгрессының сигезенче җыелышына баргач, аның белән дүрт көн буена рәхәтләнеп сөйләшергә насыйп булды.

Бигрәк тә Альбинаның елмаюы исемнән чыкмый. Болытлы көндә кинәт кенә чыккан якты кояшны хәтерләтә ул миңа.

Мин әле аның укытучы икәнен дә белми идем. Ә үзендә шунда ук чын мөгаллим кыяфәтен күреп алдым.

Зыялы, тыныч, илтифатлы.

Азсүзле, кешене зур игътибар белән тыңлый белеп, үз эченнән генә нәтиҗәләр ясаучы, тирәнтен уйлаучан, сүзен үлчәп әйтүче, җитди, түземле шәхес буларак тасвирлар идем мин Альбинаны.

Ул бер дә исемнән чыкмый. Аның рухына догалар кылам. Раббым кабул итсен».



**Флорида Локманова,**
*өлкә «Туган тел» татар җәмгыяте әгъзасы:*

«Альбинаны мин бик яхшы белә идем.

Сабан туйларында алар оештырган мәйданчыкта булмыйча калмадым. Бөтен чараларны да, яхшылап әзерләп, зур тырышлык куеп, югары дәрәҗәдә үткәрерләр иде.

Альбина һәм Фәрхәт Мәхмүтовлар татар милләте өчен янып-көеп йөрделәр. Шулкадәр милли җанлы, үз халкы өчен өзелеп торучы кешеләрне сирәк очратасың.

Альбинаның бер тискәре сыйфаты да юк иде. Тыныч холыклы, кешеләрне тыңлый белүче, хөрмәт итүче. Гомумән, аның яхшылыкларын санап бетерерлек түгел.

Альбинаның вафат булуы – Самар татарлары өчен бик зур югалту...»

**Римма Нуретдинова,**
*«Самар татарлары» сайты мөхәррире, өлкә «Туган тел» татар җәмгыяте әгъзасы:*

«Альбина апа тәртипле, мәрхәмәтле, кеше хәленә керүчән, үтә дә җаваплы иде.

Татар халкы иминлеге хакына бөтен йөрәген, җанын-тәнен биреп, үз-үзен җәлләмичә хезмәт итте ул.



Кайчак өстенә күтәрә алмаслык йөкне дә ала иде. Һәрхәлдә, һәртөрле ситуацияләрдә зур чыдамлык күрсәтте.

«Шулкадәр энергияне кайдан туплап бетерә икән?» – дип уйлый идем. Сабан туйлары, концертлар, милли һәм халыкара чаралар, төп эше, балалар… Күрәсең, шуңа да җан көченең запасы беткән, организмы таушалган булгандыр. Кызганычка, үз-үзен саклый белмәде шул ул.

Әле Альбина апа авырганчы, бер төш күргән идем. Сабан туе бара икән. Бер мәлне давыл күтәрелде дә бөтен нәрсәне җимереп ташлады. Шулвакытта кайдандыр җиккән атка утырган Фәрхәт абый килеп чыкты. «Альбина, әйдә, сикер, вакыт юк!» – ди. Альбина апа исә берсүзсез арбага менеп утырды һәм бергә китеп тә бардылар.

Бу төш нәрсәгә булды икән, дип уйландым һәм тиздән аны оныттым. Вакыт шактый үтте инде. Альбина апа вафат булгач, шалт итеп искә төште.

Анда кирәктер, шуңа Фәрхәт абый хатынын шулай ашык-пошык алып киткәндер, дип, хәзер үзебезне юатырга гына кала.

Ә Альбина апа бит, дөрестән дә, ирен һәрвакыт берсүзсез тыңлап яшәде. Хәләл җефетеннән башка калуы, ышанычлы терәген, таянычын югалтуы бик авыр булгандыр аңа.



Мин Альбина апа белән Фәрхәт абыйны 17 яшемнән белә идем. Үзем дә – яшьләр оешмасына йөргән кеше. Егерме ел аралашып яшәдек.

«Фәрхәт абый, шунда-шунда булышырга кирәк иде бит», – дип шалтыратам. «Миннән башка берни дә эшли алмыйсыз инде», – дип, кайчак бераз сукранса да, ярдәм кулын сузмыйча калмады.

Ә Альбина апа инде һәрвакыт берсүзсез ризалашты. Ул, гомумән, «юк», дия белдеме икән соң?!

Аның белән бергә беренче тапкыр үткән Хатын-кызлар форумына барган идек. Казаннан төнлә юлга чыгып, иртүк Самарга кайтып төштек. Безне Фәрхәт абый каршы алды. «Хәзер Камышлыга бер чарага барам. Әйдәгез, минем белән киттек», – ди. «Юк, – мин әйтәм. – Өйгә кайтып ял итәм. Кирәксә – фотоаппаратны бирәм». Шунда Альбина апа: «Ярар, Фәрхәт, әлбәттә, мин барам. Римма, фотоаппаратыңны бир, үзем фотосурәтләр төшерергә тырышырмын», – диде. Шулай, төнге юлдан соң чемоданы белән Камышлыга чарага китте.

Бик җәл. Бик зур кайгы. Аллаһы Тәгалә хәсрәт утында янучы балаларына, якыннарына сабырлык бирсен».

Әйе, кызганыч... Татар милли хәрәкәте күгендәге якты йолдыз мәңгелеккә сүнде. Һәм караңгы, салкын булып калды...



# ЯТИМНӘРНЕ КЕШЕ ИТЕП ЧЫГАРДЫЛАР

***1943 елның кышында Курск дугасында коточкыч каты сугышлар барган вакытта шундагы ятим балалар йортын ашыгыч рәвештә Идел Арты җирләренә эвакуациялиләр. Аны Куйбышев өлкәсенең Камышлы районындагы Иске Ярмәк авылына җибәрү турында карар кабул ителә.***

***Фәрид Шириязданов.***

Авыл хуҗалыгының бөтен авырлыклары да картлар, балалар һәм хатын-кызлар өстенә йөкләнгән вакытта авыл халкына, әле 140 ятим баланы да кабул итеп, аларны урнаштыру бурычы йөкләнә.

Бу бит хатын-кызлар көнетөне колхоз эшендә чакта, үз балаларының да киемнәре булмаганга, алар, урамга да чыга алмыйча, ач-ялангач килеш өйдә елашып утырган вакытта булган хәл.

Сугыш салымнарын ничек тә түләргә кирәклеге өстенә, әле бу ятимнәрне дә киендерергә, ашатырга һәм күбесе «беспризорникка» әйләнгән хулиганнарны укытып, тәрбияләргә дә кирәк бит!

Балалар йортының эшчәнлеге авылда бары тик егерме еллар тирәсе дәвам итсә дә, аның истәлекләре халык күңелендә озак еллар буена сакланды. Анда «Республика ШКИД» фильмындагы кебек күренешләр дә җитәрлек булды. Тәрбиячеләргә качып китүчеләрне ил буйлап эзләп йөрүләр, хәтта артык азган, бандитлык юлына басканнарны балалар колониясенә озатуга кадәр эшләр барып җитә иде.

Язмышлары имгәнеп, рухлары сынган сугыш ятимнәренә күңел җылысы биреп, аларда яшәү дәрте уятып, үзләрен ничектер мавыктыру өчен, балалар йорты хезмәткәрләре төрле юллар эзлиләр. Алдагы зур проблемасын хәл итү өчен, җир бүлеп бирүләрен сорап, колхоз идарәсенә мөрәҗәгать итәләр.

Унөч гектар җир һәм хуҗалыкта эшләргә бер ат та бирелгәч, аларның ихтыяҗларын хәл итәргә киң мөмкинлекләр ачыла. Биредә балалар бакчачылык белән шөгыльләнәләр, казлар, үрдәкләр, бозаулар асрыйлар. Булдырган әйберләрне әле базарда сатып, аларга төрле көнкүреш кирәкяраклары да алалар.

Мәсәлән, кызларга «Зингер» тегү машинкалары алып, аларны тегү эшенә өйрәтәләр. Хәзерге белән чагыштырсаң, ул чакта моны хәзерге “Иномарка” машинага тиңләп булыр иде бит!

Ә ир балаларга, тимер һәм агач эшләре белән мавыгу өчен, эш кораллары, радио, велосипедлар, төрле ял итү, спорт җиһазлары һәм башка тормыш кирәк-яраклары алалар. Ә радио һәм велосипед авылда булса да, ул вакытта бары бер-ике кешедә генә булгандыр. Әле алар да сугыштан кайткан трофейлар гына!

Гомумән, балалар йортында торабара тулы җанлы тормыш кайный башлый. Балалар һәм аларның тәрбиячеләре зур бер тату гаилә кебек яшиләр. Әлбәттә, мондый хәлне булдыру өчен, анда иң лаеклы, ятимнәргә үз әти-әниләрен алыштыра алырдай кешеләр эшкә алына.

Авылдагы өйләр салам башлы булып, халык әле ипигә дә туймаган, колхозда халыкка бөтенләй акча бирелмәгән вакытта да бу ятимнәрне тәрбияләүгә бик зур әһәмият бирелә.

Авыл халкы, ямау өстенә ямау салынган сәләмә киемнәр киеп, туйганчы ипи ашарга хыялланып йөргәндә дә, ул балаларның өсте бөтен, тамагы тук булды. Алар чиста киемнәр киделәр, ак җәймәләр җәелгән караватларда йокладылар.

1950 елларда, әле сугыш арты авырлыклары җиңелмәгән, ытлык заманда бу балаларны иң лаеклы хезмәткәләр чын күңел биреп тәрбияләделәр. Аларны ялан аяклы авыл балаларының төшенә дә кермәгән ризыклр белән сыйлап, өс-башларын юып, чистартып тордылар.

Балалар йортында тәрбияләнүчеләрнең, башларына панамалар киеп, кинодагы кебек, урамнан строй белән су кирәргә узулары әле дә хәтердә. Тик шундый житешле шартларда тәрбияләнсәләр дә, аларга барыбер нидер җитми, үзләренә балалар йорты тар булып тоела иде.

Бәлки, шуңадыр укытучылар коллективында, шул балаларны ял көннәрендә үз гаиләләренә алып кайтып, аларны кунак итү гадәте бар иде. Бу чакта аларның, ятимлекләрен дә онытып, бәхетле мизгелләр кичерүләре ачык күренә иде.

Бәлки, гаилә җылысын тою аларның нindидер тирәндә яткан хисләрен уятып, нечкә уйлар, шатлыклы мизгелләр тудыргандыр. Тик яңадан балалар йортына кайтыргавакытҗиткәндә,ятимнәрнең

моңсуланып калуы кызганыч булып тоелды.

Без, «чебеш чыгып» беткән ялан аяклы авыл малайлары, аларның строй белән йөрүен күргәч, безнең кебек, көннәр буена рәхәтләнеп су да керә алмаулары өчен ничектер җәлли дә идек үзләрен.

Иске Ярмәк авылындагы балалар йорты эшчәнлеге 1964 елга кадәр дәвам итте. Биредә тәрбияләнгән балалар, бу авыл белән элемтәләрен өзмичә, авыл халкына, тәрбиячеләренә, укытучыларга олы рәхмәтле булып, хәбәрләшеп тордылар. Биредә төпле тәрбия алып, үз тормышларын уңышлы итеп коргач, алардан рәхмәт хатлары килеп торды, һәм үзләре дә кунакка кайтып-китеп йөриләр иде.

Шулай итеп, Иске Ярмәктәге балалар йорты эшчәнлеге авылда якты эз калдырган, истәлекле бер дәвер булып тарихка керде.

Бу елларны искә алганда, анда директорлар булып эшләгән Минегали улы Гәрәй ага Һидиятов һәм Ваһаҗ улы Әсхәт ага Мөхәммәтҗанов күз алдына килә. Алар һәрвакытта елмаючан, ачык йөзле һәм киң күңелле булдылар һәм, бар куәткә тырышып, чын күңел биреп эшләделәр.



*Директор Гәрәй Һидиятов*

Тормышта күргәнебезчә, җитәкченең холкы нинди, ул җитәкләгән коллектив хезмәткәрләре дә шундый була. Шуңа да авыл уртасында



*Администрация һәм балалар йорты эшчеләре*

урнашкан балалар йорты, кечкенә бер дәүләт кебек булып, андагы тормыш һәрвакытта шау-гөр килеп, кайнап торды.

Әле сугыштан калган бер «полуторка» машина, атлар, сыерлар да бар иде алар хуҗалыгында. Төрле милләт балалары, тату бер гаиләдәй, дус булып, хезмәткә өйрәнеп үстеләр.

Иске Ярмәк авылындагы балалар йорты хәлләрен күзаллаганда, ул күп нәрсәне искә төшерә һәм тирән уйлар тудыра. Курск шәһәреннән килгән ятимнәр, үсеп, олы тормышка юл алгач та, монда шушы авылдагы һәм башка тирә-як авыллардагы сугыш ятимнәре дә тәрбияләнде. Бер Иске Ярмәк авылында гына да алты йөздән артык баланың әтиләре сугыш кырларында ятып калган бит!

Кайберләренең әле әниләре дә, авыр эштән иза чигеп, ятим балалары белән тол калу кайгысыннан чиргә сабышып, үз-үзләрен дә карый алмас хәлгә килә яисә үлеп тә китәләр.

Авылдагы балалар йортында әле менә шундыйларны да чарасызлыктан коткарып, үзләрен тормышта уңышлы шәхесләр булырлык итеп тәрбиялиләр. Шунда тәрбияләнгән Мәгъмүрә апа Миннәхмәтова әле бүген дә авылда яши. Ул шунда үткәргән еллары турында түбәндәгеләрне сөйләде:



«Әтиебезнең сугышта хәбәрсез югалуы турында хәбәр килгәч, әнием: «Аяксыз булса да, кулсыз булса да, кайтсын иде!» - дип озак вакыт аны зарыгып көтте. Ахырда рак чире белән авырды. Шул чактагы бер мизгел һаман да истә. Өзелеп ашыйсы килгәндә, ике кечкенә бармагымны күрсәтеп: «Менә шуның кадәр генә ипи булса, мин аны ашамыйча, көне буена суырып кына йөрер идем», - дип хыялланып елый идем.

Әни үлгәч, бер абыем ФЗОда укый, икенчесе армиядә хезмәт итә иде. Мин 12 - 13 яшьләрдә тулы ятим калдым. Ачтан ахыр чиккә җитеп интеккәндә, абыем кайтып, ФЗОда үзенә биргән бушлатын сатты һәм миңа бер чиләк он алып калдырды. Әле аны болгатырга учак ягып су кайнату өчен, чыбык-



*Директор Әсхәт Мөхәммәтҗанов һәм тәрбияче Кәримә Сәлахова балалар йортында тәрбияләнүчеләр белән*

чабык, сыер тизәге табуы да авыр иде бит ичмасам!

Берүзем интегеп яши торгач, авыл советы рәисе Шәһит абый Әхмәтов мине балалар йортына урнаштырды. Башта анда күнегә алмый интектем. Аннан соң ул туган йортым кебек булды.

Гөлчирә исемле кыз белән бик нык дуслаштык, бертуганнар кебек яшәдек. 1953 - 1955 елларда, мин балалар йортында торган чакта, авылдагы тормыш әле шактый авыр булса да, безгә анда бөтен уңайлыклар да тудырылган иде - дәрес әзерләргә дә, уйнарга да.

Эштә дә чыныгып үстек. Күп нәрсә онытылган булса да, үзебезнең балалар йорты басуында кәлтә бәйләгәнебез, хуҗалык умарталыгында эшләгәндә, корт-лардан чактыра-чактыра, бал ашаганыбыз истә. Ашханәдә күп итеп бәрәңге чистартканыбыз да нык истә калган.

Безнең балалар йорты хуҗалыгында үз ихтыяҗларыбызны капларлык азык-төлек җитештерелә иде. Зур землянкада кыш чыгарлык бәрәңге, суган, чөгендер һәм башкалар тулы була иде. Үзебезнең тавыклар, казлар, үрдәкләр, бозаулар, атлар, хәтта сыерлар да бар иде. Без, чын авыл тормышына күнегеп, эшкә өйрәнеп үстек.

Төрле походларга да йөри идек. Үзебез авыл клубында концертлар, спектакльләр куйдык. Әле тирә-як авылларга да барып куя идек. Гаҗәп, клублар тулы халык була, һәм алар безгә гөрләтеп кул чабалар иде!

Без барыбыз да балалар йорты хезмәткәрләренә рәхмәтлебез. Алар мәктәпкә озаталар һәм каршы да алалар иде. Шуңа да бөтенебез анда ашкынып кайта торган идек. Биредә мөстәкыйльлеккә, үзебезне рәнҗеттермәскә, үз исемебезгә тап төшермәскә дә өйрәндек. Чын дусларны да мин шунда таптым.

Балалар йортында вакытта да, аннан соңгы тормышта да безнең өчен иң якын кешебез – балалар йорты директоры Әсхәт абый Мөхәммәтҗанов булды. Без барыбыз да аны бик хөрмәт иттек. Иске Ярмәккә кайтканда, иң элек, аларга бара идек. Үзе дә, аның хатыны Кәримә апа да һәрвакытта ачык йөзле, киң күңелле булдылар. Алардагы ягымлылыкны, олы җанлылыкны без, ятимнәр, аеруча тирәнтен тоя идек.

Мәктәптә яхшы укыганга, мин укытучы булырга хыяллана идем. Тик 7нче классны тәмамлап, Камышлы педучилищесына укырга керергә җыенганда аны яптылар. Ә мине Куйбышевтагы һөнәр училищесына укырга җибәрделәр.

Армиядән соң абыем авылда торды. Мин аны бик ярата, хөрмәт итә идем. Тик шулай да, каникулларга кайтканда, бер-ике көн аларда кунсам, балалар йортына ашкынып китә идем, алар үпкәләсәләр дә. Хәзерге вакыттагы балалар йортларын яхшы яктан телгә алмасалар да, мин анда узган елларны сагынып, кадерләп искә алам.

Әсхәт абый һәм Кәримә апа инде хәзер бакыйлыкка күчтеләр. Урыннары оҗмахта булсын. Мин, “Ясин” укып, Кәримә апаның ахыргы төннәрен аның янында үткәрдем. Бөтен шартын туры китереп әзерләп, ахыр юлга балалары белән бергә озаттым”.

Иске Ярмәк авылы халкында тупланган кешелек сыйфатлары, андагы җәмгыятьнең рухи ныклыгы гасырлар дәвамында күп тапкырлар сыналган. Сугыш елларындагы, аннан соңгы авырлык-



*Ашханә*

ларны җиңгәндә дә, мондый изге сыйфатлар ачык күренгән. Бигрәк тә балалар йорты эшчәнлегендә. Аның хезмәткәрләре, ятимнәрне өметсезлектән коткарып, үзләренә ныклы тәрбия бирделәр һәм мөстәкыйльлеккә өйрәттеләр. Гомумән, алар, күп балаларга үз ата-аналарын алмаштырып, лаеклы рәвештә хөрмәт казандылар.

Халыкның узгандагы изгелекләре, ятимнәрнең бихисап рәхмәтләре киләчәктә дә бу авылның бәрәкәтен һәм бөтенлеген саклаучы ныклы илаһи терәк булса иде.

# АЛАР ТОРМЫШЫНДА МИЛЛӘТЕБЕЗНЕҢ АСЫЛЫ АЧЫК КҮРЕНӘ

***Татарлардагы кунакчыллык, ярдәмчеллек, уңганлык һәм мәрхәмәтлелек кебек сыйфатлар меңнәрчә еллар дәвамында тупланган. Шул ук вакытта киң күңеллелек, олыларга хөрмәт, туганлыкның кадерен белү һәм башка матур сыйфатлар халыкның гореф-гадәтләре нигезенә дә салынган***

***Фәрид Шириязданов.***

Гасырлар буена зур авырлыклар аша үтсәләр дә, борынгы бабаларыбыз халкыбызның асылын, милләтебез дәрәҗәсен, гореф-гадәтләрен кадерләп саклап яшәгәннәр.

Болар әле бер утыз еллар элек кенә җәмгыятебездә ачык күренә, һәм шулар безнең милли горурлыгыбыз булып санала иде.

Ни кызганыч, тик 1990нчы еллар башында өстебездән пәри өермәсе узгандай булды. Илебезнең асты өскә килде. Дөньяны хаерчелек басты. Бар җирдә дә ташланган ятимнәр күбәйгән заман килде. Шул вакытта Иске Ярмәк авылы халкы шул ятимнәрне үз гаиләләренә алып тәрбияләүгә алындылар.

Бу авылдагы мондый киң күңеллелек очраклы күренешме?! Юк шул. Кешелеклелек, мәрхәмәтлелек кебек сыйфатлар - монда элгәредән, тирәннән килә торган күренеш.

Бала тәрбияләү бервакытта да җиңел булмаган. Ә хәзерге кискен үзгәрешләр тудырган авырлыклар, заман чирләре баскан заманда – бигрәк тә. Ә анасы карынында ук агуланган, психикасы бозылган, ташландык балаларны, тәвәккәлләп, үз гаиләсенә тәрбиягә алуның никадәр җаваплы һәм хәтәр гамәл икәнлеген хәзер аңлап, моның ахырын күз алдына китерергә дә авыр.

Шул балаларны үстереп, белем һәм тәрбия биреп, үзләрен уңай тормыш юлына бастыру өчен, никадәр киң күңелле, батыр рухлы булырга кирәк бит!

Иске Ярмәктәге Альберт һәм Сәрия Хәлиуллиннар – менә шундыйлардан.

Түбәндә алар белән булган әңгәмәбез.



***– Сәрия, сезнең гаилә педагогикасы турында китап язарлык. Тормышта бер нәрсә дә юктан бар булмаган кебек, сезнең гаиләдә бала тәрбияләү osталыгы, олы йөрәклелек кайдан килгән икән?***

– Моны үзем туып-үскән гаиләбез традициясе, дип исәпләргә дә була торгандыр. Әниебез озак еллар авылдагы ятим балалар йортында эшләгән. Аның сөйләве буенча, аңа 140 баланың өс-башын, постельләрен юып, үтүкләү эше йөкләнгән булган. Шулай ук аларны мунча да кerтkән.

Әлбәттә, ул чакта кер юу машиналары, сууткәргеч булмавын һәм бөтен эшләр кул белән эшләнгәнен хәзер күз алдына китерү дә авыр.

Аның сөйләве буенча, төнлә коедан 200 чиләк су ташып, утын белән мунча яккан. Иртәнге аштан соң, балаларны юындырыр өчен, суны җылытып өлгерергә дә кирәк бит әле! Башта малайларны, аннан соң кызларны, саклап торып, юындырган.

Кечкенә буйлы булуына карамастан, кул белән шул керләрне юып, елгага ташып чайкатуның никадәр авыр булуын үзе генә белгәндер инде! Ул уңган, тәмле телле, киң күңелле иде.

Өебез балалар йортына якын гына булганга, ул көне-төне шул ике арада йөргән. Монда үзенең биш баласын үстерергә, мал-туарларны карарга да кирәклеген исәпләсәң – боларга ничек өлгерүенә хәйран калырлык.

**– Асрауга балалар алу турындагы фикер кайдан килде?**

– Үзебезнең улыбыз һәм кызыбыз үсеп җиткәч, аларның читкә китәчәген исәпләп, бер ятим бала алып үстерергә булдык. Тольятти шәһәрендәге приютта бер кечкенә

кызчык күңелебезгә якын булып тоелды. Үзебезгә алырга дигәндә, аның ике абыйсы булганлыгы да беленде.

Приют хезмәткәрләре безгә: «Сез бик яхшы кешеләр булып күренәсез. Өчесен дә алсагыз, зур изгелек булыр үзегезгә», – дип, барысын да алырга күндерделәр. Аларның күзләрендәге моңсу ялваруны күргәч, алмыйча булдыра алмадык шул.

Бераз вакыт аралашканнан соң, саубуллашканда, алар үз тәрбиячеләренә: «Спасибо, вы нашли нам хороших родителей!» – дип, үзләренең зур шатлыкларын белдерделәр.

***– Психология фәнендә: «Кешедәге сыйфатларның кырык проценты тәрбиядән килсә, алтмышы кан белән бирелә», – диелгән. Аларның каннары бозылу гына түгел, әле психикасы да нык таушалган. Моны исәпләгәндә, аларда ничек тормыш дәрте уятып, уңай тәрбия бирә алдыгыз?! Әле күп кенә уңай гаиләләрдә дә бозык балалар үсә бит.***

– Без, иң элек, мондый балаларның күңел җылысыннан, ана назыннан мәхрүм булып үскәннәрен нык аңлап эш иттек. Ачулану, җәза бирү кебек нәрсәләрне дә кулланмадык. Иң элек, аларда эшкә хөрмәт уятырга һәм үз үрнәгебездә тәрбияләргә тырыштык.

Яхшылыкны, күңел назын кеше баласы гына түгел, хайваннар да аңлый бит! Бу балалар иң баштан ук безгә: «Әти-әни», – дип эндәштеләр һәм әле дә, кайда гына яшәсәләр дә, һәр көнне иртән шалтыратып, хәлебезне белешәләр.

Без аларны шулай ук, кушканны көтмичә, һәр эшне үзләре белеп эшләргә күндердек. Ә иң мөһиме – хезмәтне яратып, аннан ямь һәм тәм табып башкарырга өйрәттек.

***– Алар үзләрен тудырган ата-аналары белән кызыксынганнары бармы?***

– Әлбәттә. Олы малаебыз Владик – бер атадан, ә Дима һәм кече кыз Алёна – икенчедән. Аларны үзебезгә алганда, Владикка – 8, Димага – 5, ә Алёнага 3 яшь иде.

Дима белән Алёна әниләрен хәтерләмәсәләр дә, Владик Тольяттида торганнарын яхшы хәтерли. Әле әнисе эчеп йөргәндә, аларны ташлаган чакта, энесе белән сеңелесен, кешеләрдән хәер сорап, ашатканы да исендә.

Владик үзе бик теләмәсә дә, үскәч, без аны әнисенең хәлен белеп кайтырга күндердек. Анда баргач, ул ишеге бер күгәндә асылынып торган, идән такталарына кадәр ватылган, ташландык хәлдәге фатирда дөм исерек әнисен күргәч, борылып чыгып китә. Шуннан соң бу темага бер дә сүз кузгатмады. Ә әтиләренең икесе турында да белүче дә, күрүче дә юк.

***– Аларның күңелендә үзләренең әти-әниләренә карата ниндидер рәнҗү, үпкә, ачу саклау яисә кеше арасында кимсенү кебек нәрсәләр сизелмәдеме?***

– Әлбәттә, каннар бәйләнеше төрле хисләр уята, бу очракта – бигрәк тә. Без балалардагы берберсенә карата булган туганлык бәйләнешен көчәйтеп, мондый моңсу уйларга урын калдырмаска тырыштык. Аларның шулхәтле бер-берсен кайгыртып, туганлашып яшәве – безнең өчен дә зур куаныч бит!

Аннан соң, үзебез дә, аларны үз балаларыбыз белән бертигез күреп, назлап тәрбияләдек. Әле Владик мөстәкыйль тормышка кучеп, Самардагы техникумда укый башлагач та, зур улыбыз Айрат һәм кызыбыз Лилия аны гел контрольдә тоттылар һәм кирәк чакта ярдәм дә иттеләр. Без аларның өчесен дә укырга урнаштырып, урта махсус белем алдырырга тырыштык. Ял вакытларында гел каршы алып, озата да идек. Матди яктан да ярдәм иттек.

Владик армиядә хезмәт итеп кайтты. Яхшы эштә эшли. Ярмәк кызына өйләнде. Без зурлап туй үткәрдек, никах укыттык. Хәзер инде үзләренең дә балалары туды. Авылда, мәҗлес җыеп, никах укыттык.



***Сәрия Алёна белән***



***Владик баласы белән***



***Дима***



*Владик туенда*

Үзләренә, бик зур авырлык белән булса да, фатир алырга булыштык. Бик кыен булды, җиде ел буена прокуратура, судлар юлын да таптадык. Беренчедән, чират бик озын. Икенчедән, алар үзләре пропискада булган фатирда тагын алты кеше язылган һәм анда ничәмә еллар түләнмәгән бурыч тупланган иде.

Моның өстенә, аналары исән булганга, аларга пенсия дә түләнмәде.

Башкаларның, алдагы көндә тормыш башлар өчен, акча җыела торган булса, боларга ул да булмады. Шулай да, җаен табып, ярдәм итәбез, ташламыйбыз.

Гомумән, без балаларыбызны беркайчан да асрау балалары итеп санамадык. Әле мәктәпкә ата-аналар җыелышына барганда да, шундый сүз әйтсәләр, йөрәккә тия иде. Әле дә үз балаларыбыз белән бертигез күрәбез.

Дима техникум тәмамлады һәм хәзер Украина чигендә хезмәт итә. Хәрби техникаларны ремонтлый. Гел шалтыратып, хәлебезне белешеп тора. Ул эчми-тартмый, эшкә уңган, аралашучан булып үсте.

Аларны Сызраньнан Ростовкага алып киткәндә, аның эчкән яшьтәшләрен тәртипкә салырга ярдәм итүенә хәйран калып, командирлары җибәргән хатта:

«Ваш сын – прекрасный парень. Спасибо за то, что воспитали его порядочным человеком и патриотом. Надеюсь, что его ждёт достойное будущее.

Если все парни будут такими – нам не страшны никакие угрозы извне ...», – дигән сүзләр бар иде.

Алёна да узган ел техникумны тәмамлады. Хәзер үз һөнәре буенча уңышлы гына эшли.

Безнең алда әле аңа да фатир алып бирү проблемасы тора, – дип сөйләде Сәрия ханым.

Җәмгыятьтә әхлак һәм әдәп сансызланып, кешеләрдән оят качкан, һәркем үз мәнфәгатен генә кайгыртып яшәгәндә, арабызда Альберт һәм Сәрия Хәлиуллиннар кебек кешеләрнең дә булуы – гаҗәеп матур күренеш.

Алар белән аралашу да өметсезлектән, ямансу уйлардан коткара, тормыш чынбарлыгына башка күзләр белән карарга ярдәм итә. Алар һәрвакытта да якты йөзле, ачык күңелле.

Читтән аларның тормышы гел майлагандай барган кебек күренсә дә, Сәриянең йөрәгенә операция ясап, биш стенд куюлары күпне сөйли.

Усаллык эшләргә берни тормаса да, яхшылык, изгелек эшләү өчен, чын тормыш батырлыгы кирәк шул. Бигрәк тә хәзер, изгелек эшләү, намус саклау кебек гамәлләр кадерсезләнгән заманда.

Авыр эштән арыгач, тәнне ятып ял иттереп булса да, йөрәк белән күтәргән авырлыклар тиз генә җиңелми, җыела гына бара шул.

Советлар Союзы җимерелеп, Россиядә кыргый капитализм корып маташканда, җәмгыятебездә рухи гариплек көчәеп, халыктагы кешелек сыйфатлары нык имгәнде. Менә шул заманда Иске Ярмәк халкының, ташланган балаларга лаеклы тәрбия биреп, аларны үрнәк шәхесләргә әверелдерә алуы могҗизага тиң күренеш түгелме соң?!

Мондый тәрбия бирүгә сәләтле, олы җанлы кешеләр, һичшиксез, хөрмәткә лаек булып, аларның хезмәте югары бәяләнергә һәм үзләренә мактаулы исемнәр, орден-медальләр дә бирелергә тиеш.

Дөрес, Альберт һәм Сәрия Хәлиуллиннарга Самар өлкәсе тарафыннан «За крепость семейных устоев, основанных на взаимной любви и верности, в честь празднования Дня любви и верности» дигән медаль бирелгән.

Тик шулай да, аларның игелеге, тормыш батырлыгы күпкә югарырак бәяләнергә тиеш. Чөнки бу медальдә телгә алынган мәхәббәт һәм тугрылык кебек изге хисләр дулкынында алар үз балаларын гына түгел, өч үксез ятимне дә сокланырлык итеп тәрбияләгәннәр.

Менә бу фотоларда балаларның йөзендәге яшәү шатлыгы, бәхетле елмаюлары сүзсез дә күпне сөйлиләр бит!

Бу гаиләнең тәрбия өлкәсендә ирешкән уңышлары турында авылда, районда гына түгел, өлкә күләмендә билгеле булырга тиеш!

Хәзер үз эченә генә бикләнеп, пыскып, мескенәеп яшәүчеләр саны коточкыч рәвештә арта барган вакытта – бигрәк тә.

Ни дисәң дә, Сәрия һәм Альберт кебек кешеләр - ювелирлар сыман, иң кадерле материал – кеше җаны белән эш итүче, иң җаваплы хезмәт ияләре.

Алар – рухлары сынган, язмышлары имгәнгән балаларның акылын, уй-фикерләрен һәм киләчәк тормышын туры эзгә салучылар!



# ЕГО ДЖАЛИЛЬ БЛАГОСЛОВИЛ

*Муса Джалиль, работавший с 1933 года заведующим отделом литературы и искусства общесоюзной татарской газеты «Коммунист», которая издавалась в Москве, в том же году обратил внимание на только что вышедший в Самаре добротный поэтический сборник неведомого доселе автора – С.К. Мавлютова. Завотделом написал положительную рецензию на сборник в упомянутой газете, а через год в таком же духе откликнулся на страницах этого СМИ и на вторую подборку сочинений Мавлютова. Более того, Муса эфенди вступил в переписку с самарцем и стал для него добрым наставником. Так на небосклоне татарской поэзии взошла новая звездочка, которая со временем выросла в популярного поэта-песенника, автора 15 книг, литератора и журналиста, известного многим под псевдонимом Сахаб Урайский.*

*Рашид Шакиров*

С помощью этого литературного имени, выбор которого пришлось поначалу объяснять даже в органах власти, Сахабетдин Камалетдинович Мавлютов решил зафиксировать место своего появления на свет. Ведь родился он 21 декабря 1907 года в деревне Татарское Урайкино (тат. – Иске Кызылсу) Помряскинской волости Ставропольского уезда Самарской губернии (ныне – Старомайнского района Ульяновской области). Родительская семья была бедной, глава ее Камалетдин Мавлютов занимался батрачеством. Вскоре роль батрака пришлось освоить и Сахабу, поскольку он рано познал тяготы сиротства. Мальчишка пас скот и мечтал об учебе, которая стала для него доступной после установления советской власти.

Начальное образование Сахаб получил в сельской школе. Авторы большинства публикаций о нем полагают, что герой статьи учился на малой родине, где в 1918 году было открыто начальное учебное заведение. Но в Татарском Калмаюре – бывшей деревне Ставропольского уезда Самарской губернии (ныне – Чердаклинского района Ульяновской области, соседствующего со Старомайнским районом) считают по-другому. В музее МОУ Тат. Калмаюрской СОШ им. Д.И. Шарипова есть зал знаменитых людей этого села – выпускников школы. И среди них фигурирует поэт Сахаб Урайский. Возможно, он начал обучаться в Татарском Урайкино, а завершал школьный этап освоения знаний в Татарском Калмаюре, поскольку здешняя школа славилась еще с царских времен. Она одной из первых в регионе перешла на новометодное обучение, а после долгие годы считалась лучшей среди татарских школ округи, и из ее стен вышли будущие крупные ученые, политические и общественные деятели.

После школы Сахаб продолжил «грызть гранит науки» в Самарском татаро-башкирском педагогическом техникуме, в который он поступил в 1927 году. Здесь его интерес к учебе дополнился тягой к литературному творчеству, а именно к написанию заметок, статей и очерков. Чуть позже в печати появляются и стихи. По завершении второго курса наш герой вместе с другими учащимися узнал о решении секретариата Средневолжского областного комитета ВКП(б) о переводе этого техникума в г. Кузнецк. Пришлось ли Мавлютову и его однокурсникам переезжать в тот город или они успели пройти программу обучения в Самаре – это нам неведомо. Известно лишь то, что получив в 1930 году свидетельство об окончании педтехникума, Сахаб в течение двух лет преподавал татарский язык и литературу в Средневолжской краевой совпартшколе, а потом отправился на учебу в Восточный педагогический институт (г. Казань), но по семейным обстоятельствам

вынужден был оставить занятия и вернуться в Самару.

В столице края его в 1932 году принял в свои ряды коллектив татарской газеты «Колхозче» – органа Средневолжского крайкома партии и крайисполкома. В найденном списке сотрудников этого СМИ от 1933 года комсомолец Урайский фигурирует как заведующий массо-


KOLXOZCЬ

28

„КОЛХОЗЧЕ“

Irtəgə вygengedən də jaxşьraq eşlərgə

*Газета «Колхозче»*

вым отделом. В редакции было еще два отдела: расследования и сельскохозяйственный. Такая структура отвечала требованиям времени, поскольку в стране реализовывался курс «догоняющей» модернизации, и ВКП(б) «подхлестывала» население новыми экономическими проектами, а печать усиливала пропаганду всех партийных начинаний. От газет требовалось смелое бичевание извращений классовой политики и бюрократизма, углубление самокритики, расширение освещения вопросов партийного строительства, оказание помощи парторганизациям в проведении важнейших политических и хозяйственных кампаний, развитие массовой работы СМИ и постоянная забота о рабселькорах и редакторах бригадных стенгазет.

Так, в рамках массовой работы «Колхозче» проводил выездные редакции для подготовки материалов по обслуживанию прополочной, взмета ранних паров и подготовки к проведению уборочной кампании. За первый квартал одного из годов самарцы помогли выпустить на местах следующие издания: в Саранском районе – 10 номеров районной газеты и три номера – областной, а также две газеты сельского масштаба; в Старо-Кулаткинском и Байтугановском районах – по три номера. Силами редакции обслужены Абдулинский, Бугурусланский и Красноярский районы. Кроме того коллектив «Колхозче» готовил обзоры публикаций районных газет, выходящих на татарском языке, и высылал им свои соображения.

«Колхозчелар» использовали и другие формы массовой работы: читательские конференции, отчеты на рабочих собраниях, конкурсы, смотры и пр. Так, планом редакции ко Дню печати 1935 года было предусмотрено проведение конкурса на лучшую стенгазету, конференции читателей в колхозе «Волжская коммуна» Лямбирского района, в колхозе «Кызыл су» Мало-Кандалинского района и в колхозе им. Баумана Байтугановского района. Также запланированы обзоры бригадных стенгазет колхоза им. Сталина Торбеевского района, колхоза «Волга» Богдашкинского района и колхоза им. Клары Цеткин Старо-Кулаткинского района. А обзоры на тему «Борьба за действенность селькоровской заметки» должны были поступить в Лямбир, Старую Кулатку и Байтуган – для районных газет.

Занимаясь этой разнообразной массовой работой, Сахаб не забывал и о своем литературном творчестве. На страницах «Колхозче» появлялись подборки его стихов. А в 1933 году, как уже отмечалось в преамбуле, Средневолжское краевое госиздательство выпустило первую книгу Урайского «Көтүче кызы» («Дочь пастуха»), на 97 страницах которой была напечатана поэма и подборка стихотворений. Годом позже в том же издательстве вышел второй сборник стихов нашего героя под названием «Таныш елмаю» («Знакомая улыбка»).

С первых же шагов на этом поприще уроженец самарской земли стал рупором комсомола, призывающим советскую молодежь к трудовым подвигам и светлым идеалам, показывая образцы таких устремлений. Летом 1934 года он получил письмо от М. Джалиля: «Я чувствую у тебя писательский талант. А это – первое условие для такого труда. Твои стихи ровные, хорошо сложены. И в рассказах много красивых мест. Но ты действуешь по шаблону, не ищешь оригинальные образы, картины и сюжеты. Повторяешь тысячи раз сказанные до тебя слова и мысли. Глубже познавая жизнь, старайся показывать разные ее стороны и проявления: противоречивые, сложные, интересные. Ищи оригинальные темы, сюжеты и, конечно, много работай, постоянно работай. Не торопись! Чтобы хорошо писать, надо много читать, знать, быть «в культуре». Этого не забывай».

Такое внимание и вдохновляло, и мобилизовывало. Тем более что вскоре Урайского командировали на учебу в Москву, что возможно, произошло не без участия Джалиля. Во многих публикациях о герое сей статьи написано, что он в 1934–1936 годах обучался на Высших литературных курсах при Союзе писателей (СП) СССР. Увы, это не так, упомянутые курсы открылись при Литературном институте в 50-е годы. Видимо, ближе к истине те авторы, которые упоминают курсы молодых писателей, организованные ЦК ВЛКСМ и СП СССР, хотя документального подтверждения этого найти не удалось.

Не исключен сбор на искомые курсы не просто молодых мастеров пера, а детских писателей, так как в то время вопросы развития литературы для детей получили большое внимание партийного руководства. «Теперь следует поставить вопрос, как реализовать такое внимание», – подчеркнул оргсекретарь Союза писателей СССР и куратор этого Союза по линии ЦК А.С. Щербаков на организационном совещании детских писателей в октябре 1934 года. А учитывая состоявшееся годом ранее выделение издания детской литературы в самостоятельное издательство – Детгиз, которое находилось тогда в ведении ЦК ВЛКСМ, можно пред-

положить, что центральные комсомольские и писательские органы просто обязаны были совершить какие-то «телодвижения» по части повышения квалификации и увеличения количества «пишущей братии» на молодежно-детские темы. Так, в Ленинграде под руководством С. Маршака заработал детский литературный университет. Учились и московские писатели: вместе с работниками Детгиза штудировали иностранные языки, философию. Не на этих ли курсах занимался и Урайский?

Очевидно одно – одним из кураторов их был В.П. Ставский – ответственный секретарь Союза советских писателей. Именно он принял участие в судьбе героя сей статьи, когда тот получил послание из Самары. Ответственный редактор «Колхозче» Ф.М. Мубаракшин (статья о нем была напечатана в 21-м номере нашего журнала) решил отозвать с учебы С. Урайского, который, по его мнению, прохлаждался в столице. Редактор отправил ему ультиматум: или срочно возвращаешься на работу, или можешь считать себя уволенным. Тот показал перевод послания руководству курсов, и в феврале 1935 года в культпроп крайкома партии поступило письмо Ставского следующего содержания: «На курсах молодых писателей в Москве учится молодой татарский писатель Урайский. А редактор «Колхозче» т. Мубаракшин совершенно неправильно истолковывает пребывание на курсах Урайского, сотрудника редакции, как праздный отдых и веселое времяпрепровождение. Редактор газеты угрожает т. Урайскому увольнением, отказывает в выплате зарплаты. Прошу растолковать редактору, что он поступает неправильно».

Растолкование состоялось, и Сахаб, завершив обучение на курсах, вернулся на работу в родной журналистский коллектив. В декабре 1935 года краевое правление Союза советских писателей представило в крайком ВКП(б) справку о состоянии литературы в крае и «лице» местных писателей. Про Сахаба написано так: «Урайский. Служащий, комсомолец, татарин. Поэт и прозаик. Кандидат в члены Союза советских писателей. Печатается в сборниках и газетах. Работает в редакции краевой татарской газеты «Колхозче».


ƏDƏBIAT SƏXIFƏSE

S. Urajski şiƣr.

Safin brigadasь turьnda

*Стихи С. Урайского в газете «Колхозче»*

Но трудиться в ней пришлось недолго, поскольку бюро Куйбышевского обкома ВКП(б) приняло решение о прекращении выпуска этого СМИ с 1 апреля 1938 года. К сожалению, в 30-е годы в стране закрылись все краевые газеты и журналы, а также областные и окружные газеты на татарском языке. Поэтому Урайский, успевший выпустить в самарский период своей жизнедеятельности и третью книгу («Две встречи», 1937), решил повторить попытку превращения в жителя Казани. В столице ТАССР он на весь довоенный период стал корресполндентом республиканской молодежной газеты «Яшь сталинчы» («Молодой сталинец»), которая со второй половины 30-х годов уделяла большое внимание военно-патриотическому воспитанию.

Тема воспитательного воздействия была близка Сахабу, и, думается, он комфортно себя чувствовал в новой редакции. Тем более что в ее составе трудились и «собратья по поэтическому цеху», например, Гали Хужи и Наби Даули, имевшие изданные труды. Пополнил список написанных им книг и наш герой. Так, в 1939 году в Казани увидели свет его сборники «Давыллар аша» («Сквозь бури», стихи, поэмы, рассказы) и «Чыршы янында» («Около елки», стихи). Название первого сборника было и названием поэмы о сироте Гайше, убежавшей из деревни в город, жившей в ночлежках и занимавшейся воровством. Но в итоге она поступила в школу фабрично-заводского обучения и устроилась на работу. Другую свою поэму – «Порт-шәһәр» («Город-порт») – Урайский посвятил трудовому энтузиазму юношей и девушек на строительстве электростанции в родных краях. В конце того же десятилетия он, как и названные выше его коллеги, стал членом Союза писателей СССР. К счастью, репрессии обошли их стороной, хотя некоторые сотрудники газеты тех лет трудились в ней не более квартала, в том числе и сменявшие друг друга редакторы.

В военное лихолетье выход номеров этого СМИ был приостановлен, так как большинство журналистов убыло на фронт. Сахаб в 1941 году стал политруком автобатальона и участвовал в боевых действиях. Но когда здоровье старшего лейтенанта пошатнулось, его переправили в тыл и он продолжил службу в органах МВД. На интернет-портале «Память народа» Министерства обороны РФ и Корпорации ЭЛАР, где наш герой

зафиксирован как Мавлютов-Урайский Сахаб Камалович, отмечено, что демобилизовался он в сентябре 1945 года, причем последним местом пребывания в армейских рядах указан казанский эвакогоспиталь № 2778.

Приступив к мирной жизни, Урайский снова отправился на учебу – на сей раз в только что открытую партийную школу при Татарском обкоме ВКП(б), имевшую статус неполного высшего учебного заведения с двухлетним сроком обучения. Окончив ее в 1948 году, он был направлен на работу заведующим парткабинетом одного из райкомов партии на территории ТАССР. Но с 20 августа 1949 года, со дня возобновления издания газеты «Яшь сталинчы», нашего героя отозвали в ее редакцию, и он стал в ней литературным сотрудником.




*Газета «Яшь сталинчы»*

Здесь Сахаб продолжил общение с орденоносцем Гали Хужи, которого назначили ответственным редактором этого СМИ. Бывший военный корреспондент газеты «За честь Родины» 1-го Украинского фронта умело руководил коллективом, а военная тема занимала ведущее место в его творчестве. А вот биографию Наби Даули война поломала. Точнее, не она, а плен и концлагеря, после которых к поэту относились с подозрением и исключили из Союза писателей ТАССР. Трудиться пришлось не в редакции газеты, а в художественных мастерских. Лишь в конце 50-х начали издаваться его послевоенные произведения.

До каких пор Сахаб эфенди трудился в газете выяснить не удалось, но, по мнению литературоведа Х. Хайри, опубликовавшего статью к 60-летию поэта, Урайский по стажу до- и послевоенной работы в республиканской «молодежке» может считаться самым «аксакалистым» ее сотрудником. А последним местом трудовой деятельности Сахабетдина Камалетдиновича стало Татарское книжное издательство (Таткнигоиздат), в котором он занимал должность редактора редакции литературы для детей и юношества.

Такое перемещение было неслучайным. В автореферате докторской диссертации А.Р. Абдулхаковой «Татарская детская книга 1917–1991 гг.: эволюция и тенденции развития», названы прозаики, поэты и драматурги Татарии, которые еще в довоенный период работали в области детской книги. Наряду с Д. Аппаковой, А. Айдаром, Г. Лутфи, У. Бакировым, С. Адгамовой, А. Бакчантаевой, Н. Гайсиным, Дж. Тарджемановым, Г. Хасановым упомянут и С. Урайский. А в годы работы в Таткнигоиздате он продолжал общаться с молодежью, дружил с молодыми писателями. Молодежная тема уверенно занимала главное место в его стихотворном творчестве. Подчеркнем, что в республике стихотворения всегда были самым активно издаваемым жанром детской литературы, причем наивысшие показатели их выхода в свет приходятся на 1950–1960-е годы – время самого активного печатания детской книги в ТАССР.

Не будет преувеличением, если скажем, что к этому процессу наш герой имел отношение и как редактор, и как автор. Так, в 1948 году вышла книжка его стихов «Бәхетле балалар» («Счастливые дети»), а в те самые 50-е – шесть сборников стихотворений. Столь много книг Урайского до этого ни в одном десятилетии не издавалось.

Комсомольский поэт не стоял на месте, а развивался в своем творчестве, От первых романтических строф, в которых отношения людей редко показывались в реальной жизни, он перешел к лирико-публицистическим стихам о молодежи, «поднимающей» новую страну и самих себя вместе с ней. Из года в год расширялась тематика произведений Урайского, рассказывавшего читателям о важнейших событиях в жизни Советского Союза. Под впечатлением от своих наблюдений он написал серию очерков о грандиозном строительстве Куйбышевской ГЭС. Среди них назовем сборник стихов «В Жигулях» и очерки «Его строит вся страна», «Преобразуется река», «Молодежная бригада экскаваторщиков», «В дождливый день», «У Жигулей», «Заря в Жигулях», «Весна в Жигулях» и др. Потом пришло время стихов, богатых татарским колоритом. Специалисты отмечали также его умение выражать картины природы и красоту земли проникновенными образами.

Но широко известен Сахаб эфенди стал, думается, благодаря своим красивым песням ностальгии и грусти, любви, мира и труда. Его стихи положили на музыку как маститые композиторы, так и молодые. Большой популярностью у разновозрастной публики пользовались в свое время следующие песни нашего героя: «Пионерлар жыры» («Песня пионеров», муз. Х. Валиуллина), «Чыршы янында» («У елки», муз. И. Шамсутдинова), «Укырга» («Учиться», муз. С. Сайдашева), «Икебез ике якта» («Мы на разных сторонах», муз. Ш. Мазитова), «Безнең яшьләр» («Наша молодежь», муз. Ш. Мазитова) «Тау кызы» («Горная девушка», муз. Ш. Мазитова), «Син кал бездә» («Ты останься у нас», муз. Р. Яхина), «Онытма» («Не забудь», муз. Р. Яхина), «Тынычлык сугышны җиңәр («Мир победит войну», муз. Э. Бакирова, «Өй артында шомыртым» («Черемуха за домом», муз. народная).

А его «Син кайтмадың»(«Ты не вернулся», муз. М. Музафарова) по праву считается одной из самых трогательных песен, посвященных Великой Отечественной войне. Ее




***Грампластинки с записями песен С. Урайского***

исполняли А. Авзалова, М. Булатова и Р. Ибрагимова, Ш. Ахметзянов и В. Усманов. Эта песня и в конце XX века часто звучала по радио.

В текущем году интернет-газета «Реальное время» опубликовала статью Р. Кашапова «Дискотека 90-х: вечнозеленый хит «Чыршы янында». Автор считает, что в татарской эстраде не так-то много новогодних популярных песен. А самая известная, знакомая и взрослым, и детям, была написана давно и, кажется, уже стала народной. Это упомянутая выше «Чыршы янында», первый куплет которой теперь живет самостоятельной жизнью:

*Чыршы, чыршы, без сине*
*Сагынып көттек ел буе.*
*Син тагын да матурырак*
*Бизәлгәнсең бу юлы.*

Позволим себе предложить такой перевод:

*Елка, елка, мы тебя*
*Ждали, целый год терпя.*
*Ты еще красивей стала*
*И в нарядах заблистала.*

Отдавая должное «родителям» этого произведения, Кашапов называет его «шлягером от певца трудового подвига и любителя джаза», имея в виду пристрастия поэта и композитора.

Наш герой еще занимался переводом на татарский язык стихотворений многих известных авторов: М. Лермонтова, Т. Шевченко, К. Хетагурова, А. Твардовского, М. Исаковского, А. Барто, казахского советского поэта-акына Джамбула, киргизского советского поэта-акына Токтогула и др. Из-под пера Урайского появлялись и статьи-рецензии о творчестве поэтов-современников и известных предшественников, которым тоже покровительствовал Пегас.

В найденных нами публикациях о Сахабе эфенди почему-то ни слова не говорится о его семейных делах. Но благодаря главе Администрации муниципального образования «Урайкинское сельское поселение» А.Х. Галяутдинову удалось связаться с родственниками поэта, которые поделились информацией об этой важной стороне его жизни. По словам С. Каримовой – племянницы жены героя статьи, и П.Ф. Урайского – его правнука, С. Урайский женился во время проживания в Самаре на местной девушке по имени Салима, которая была моложе супруга на десять лет. Познакомились молодые люди в редакции самарской газеты (видимо, «Колхозче»), где избранница поэта работала секретарем-машинисткой. Она была 11-м (предпоследним) ребенком Хасанши хазрата Богатова (Хасанши Мухамманджановича Габдулбогатова), который служил муэдзином Второй мечети на ул. Казанской (ныне это Самарская Историческая мечеть на ул. А. Толстого) с 1894 года и до ее закрытия в 1930 году.

Двумя годами позже Хасанша хазрат вместе с другими руководителями «дома Аллаха» был арестован как член «ликвидированной контрреволюционной мечетной группировки», но через несколько месяцев его освободили из-под стражи, зачтя срок предварительного заключения за наказание. Со своим будущим зятем-партийцем он взаимопонимания так и не нашел. После кончины самый известный самарский муэдзин был реабилитирован Куйбышевским облсудом.

Надо полагать, что у него было очень много внуков. Среди них значились и пятеро детей Сахаба и Салимы: Рафаэль, Шамиль, Фаимя, Наиля и Фарида. Две последние дочки поэта здравствуют и поныне. Так, Наиля апа (ей около 80 лет) живет в Казани, а Фарида ханум (ей 71 год) – в Оренбурге.

Когда творчество Сахабетдина Камалетдиновича вошло по сути в пору цветения, он ушел из жизни. Это случилось 15 февраля 1957 года в Казани. До этого продолжительное время поэт болел, а его пристрастие к спиртному не добавляло здоровья. Но он продолжал работу со словом, отливавшуюся в появ-




***Нынешние дети исполняют песню С. Урайского «У елки»***

ление новых своих произведений и редактирование чужих трудов. Хоронили его в очень холодный



***Правнук поэта с семьей у мемориальной доски С. Урайскому, Татарское Урайкино, 2022 год***

февральский день, но, тем не менее, венки траурная процессия несла от Дома печати на ул. Баумана до самого кладбища.

Стихи и поэмы Сахаба абый издавались в виде книг и после его кончины – в 1959, 1966 и 2008 годах. А в 1960 году вышел сборник самых популярных песен нашего героя под названием «Син кал бездә» («Оставайся у нас») тиражом 7000 экземпляров.

Можно констатировать, что и поныне имя этого уроженца Самарской губернии на слуху. Так, редакцией Ульяновской областной татарской газеты «Өмет» («Надежда») учреждена и вручается литературная премия имени поэта-фронтовика С. Урайского. В его родном селе есть улица Сахаба-Урайкино. К 100-летию известного земляка там в торжественной обстановке открыли мемориальную доску ему в здании местной школы. В церемонии открытия участвовали председатель областного Законодательного собрания Б. Зотов, представители областной администрации и общественности района, ветераны войны и труда, а также жители села и гости из Татарстана: писатели В. Нуриев, Л. Хамидуллин и поэтесса Э. Шарифуллина. Вниманию собравшихся была предложена литературно-музыкальная композиция, посвященная жизненному и творческому пути юбиляра.

Но в 2015 году трехэтажная школа в Татарском Урайкино закрылась, и памятная доска, оставшись внутри помещения, перестала выполнять свою основную функцию. Поэтому упомянутый выше А.Х. Галяутдинов инициировал создание второй мемериальной доски С. Урайскому в селе. Ее торжественное открытие на здании администрации Урайкинского сельского поселения состоялось 9 мая прошлого года. На сей раз в церемонии участвовали земляки поэта-песенника и названный в статье его правнук с женой и сыновьями. Литературный псевдоним Сахаба эфенди стал их фамилией.

Стихи Урайского и в наши дни звучат в молодежных аудиториях. Например, преподаватель Новиковской средней школы муниципального образования «Старомайнский район» Ульяновской области Х.Г. Мухаметшина разработала и утвердила у директора учебного заведения программу внеурочной деятельности «Татарские жемчужины» на 2018–2019 учебный год объемом 35 часов для 5–10-х классов. Одна из тем этой программы посвящена стихотворениям Сахаба ага, для ознакомления с которыми предусматривались подготовка практических работ и проведение дискуссий, а также поход в сельскую библиотеку. А учащаяся Елабужского колледжа культуры и искусств (РТ) А. Гирфанова на Всероссийском конкурсе чтецов «Помнит сердце, не забудет никогда» к 75-летию Победы выступила со стихом нашего героя «Сугыш беткән иртәдә» («Наутро после окончания войны»). Конкурс прошел, видимо, в режиме онлайн и собрал почти восемь тысяч участников. Одним словом, не вянут стихи поэта-песенника, держатся как стойкие цветы.

Именно об этом и мечтал он, написав следующую строфу:

*Җырчы үлсә, аның эше кала,*
*Исеме кала халык теленда...*
*Мин шаттырган гөлләр бердә шиңми*
*Үссен иде туган илемдә!*

Переведем это так:

*Поэт не вечен, стих лишь остается,*
*И имя, незабвенное в стране...*
*Цветам моим пусть вечно удается*
*Красы родной добавить стороне!*



***При открытии мемориальной доски С. Урайскому, 2022 год***

# СЫЙНЫФТАШЛАР – ГОМЕРЛЕК ДУСЛАР



***Мәктәп еллары һәрберебезнең күңелендә аерым бер урын биләп тора. Чәчәк бәйләмнәрен тотып, уку йортын тәүге тапкыр атлап кергән көннән алып, соңгы кыңгырау чыңлаган көнгә кадәр үткән дәвердә сыйныфташлар да, укытучылар да бер-берсе өчен якын кешеләргә әвереләләр, бер зур гаиләне хәтерләтәләр бит.***

***Миләүшә Газимова.***
***Әнәс Мингалиев фотосурәтләре.***

Менә 1983 елда Елховка районының Тупли авылы мәктәбен бетергән милләттәшләребез дә укыган елларда да бик тату булганнар һәм бүгенге көндә дә шушы ныклы дуслыкларын саклап яшиләр, биш ел саен классташлары белән очрашып торалар.

Ә быел мәктәпне тәмамлауларына 40 ел тулган икән инде. Шушы уңайдан алар Самарның “Белоснежка” кафесында вафат булган укытучылары, сыйныфташлары һәм мәктәпнең башка хезмәткәрләре рухына багышлап дини мәҗлес үткәргәннәр.

“Без укыган елларда Тупли мәктәбе гөрләп торды, укучылар бик күп иде.

Беренче класска без 50 бала бардык, ике параллель сыйныфта белем алдык. Аннары инде тора-бара килүчеләр дә, китүчеләр дә булды. Шулай итеп, ике 10нчы сыйныфны барлыгы 36 укучы тәмамлады.

Элеккеге елларда очрашу кичәләребез башка форматта уза иде. Казаннан танылган җырчыларны чакырып, көндез авыл клубында ата-аналарыбыз, укытучыларыбыз өчен концерт куйдырабыз. Ә кичен, мулла дәшеп, мәктәптә табын корабыз. Әти-әниләр, мөгаллимнәребез таралышкач, үзебез генә калып, сөйләшеп утырабыз.

35 һәм 40 еллык очрашу кичәләре исә “Белоснежка” кафесында дини мәҗлес буларак үтте. Аның хуҗасы Тәлгат Мортазин – безнең авылдашыбыз. Биредә татар коллективы эшли. Һәрвакыт ачык йөз белән каршы алалар. Хәләл ризыклардан мул өстәл коралар. Безнең ихтыяҗларны, теләкләрне исәпкә алып, барысын да югары дәрәҗәдә оештыралар, рәхмәт яугыры.

Быел без бер уй-фикергә килдек тә вафат булган классташларыбыз, Тупли авылы мәктәбенең без белгән барлык укытучылары һәм башка хезмәткәрләре рухына багышланган Коръән мәҗлесе үткәрергә булдык.

Кызганыч ки, ике параллель сыйныфтан уналты кеше мәңгелеккә китеп барды:

***Әхтәм кызы Нурия Әхмәтҗанова,***
***Минәхмәт улы Юныс Вәлиев,***
***Нургали улы Галимҗан Гыйльметдинов,***
***Нәбиулла улы Хәтимулла Кәлимуллин,***
***Мөхәммәтгали улы Хәмзә Лотфуллин,***
***Миневәли улы Равил Хисмәтуллин,***
***Гомәрҗан улы Юныс Гайнетдинов,***
***Мотыйгулла улы Фатих Гыймадиев,***
***Габделхак улы Рәшит Идрисов,***
***Хәтимулла улы Рәшит Исмәгыйлев,***
***Нурулла улы Йосыф Садыйков,***
***Әзгат улы Тәлгат Зәйдуллин,***
***Зиннәт улы Равил Гарифуллин,***
***Минәхмәт улы Равил Якупов,***
***Нургали кызы Сафия Лотфуллина,***
***Минәхмәт кызы Зәмзәмия Шәрәпова.***

Мөгаллимнәрнең, мәктәпнең башка хезмәткәрләре – идән юучылар, хуҗалык эшләрен алып баручылар һәм башкаларның да бик күбесе якты дөньяда юк инде:

***Илһам кызы Җария Дәүләтшина,***
***Мотыйгулла кызы Гаян Хәлиуллина,***
***Хәйдәр кызы Фәһимә Вәлиәхмәтова,***
***Нургали кызы Гөлфия Гайсина,***
***Нәбиулла улы Хәйрулла Сафин,***
***Нигъмәт улы Абдулла Насыйров,***
***Имам кызы Равия Насыйрова,***
***Акбәр кызы Нажия Усманова,***
***Закир улы Гомәр Шәкүров,***
***Аләветдин кызы Алия Шәкүрова,***
***Аләветдин кызы Мәдинә Сатдарова,***
***Әхмәт улы Гали Сатдаров,***
***Мәхмүт улы Мәзгут Вәлиәхмәтов,***
***Җәләлетдин улы Йосыф Шәрипов,***
***Насыйбулла кызы Лалә Вәлиәхмәтова,***
***Вәлиәхмәт улы Минәхмәт Вәлиәхмәтов,***
***Мөхәммәтгата улы Әнвәр Зилидинов,***
***Шакирҗан кызы Нажия Шәрәпова,***
***Әхмәт кызы Хәдичә Мөхтәрова,***
***Ясави кызы Гөлсинур Гәрәева,***
***Исмәгыйл кызы Сара Камалетдинова,***
***Нурмөхәммәт кызы Галия Загретдинова,***
***Әүхәт улы Тәлгат Мингалиев,***
***Кашап улы Зөфәр Салиев,***
***Мәхмүт улы Ярулла Мостафин,***
***Хәлил кызы Мәрьям Шәкүрова,***
***Габбас улы Камил Камалетдинов,***
***Гәрәй улы Габдерәүф Гыйльманов,***
***Әхмәт улы Минегали Хуҗин,***
***Мөхәммәт улы Минегали Давыдов,***
***Касыйм улы Хөсәен Шәрәпов,***
***Салимҗан улы Галимҗан Садров,***
***Таһир улы Исмәгыйл Мәхмүтов,***
***Мөхәммәтгәрәй кызы Нурҗиһан Хуҗина,***
***Мәхмүт кызы Әминә Мөхетдинова,***
***Гәрәй кызы Минегаян Гыйльманова,***
***Минсафа кызы Гөлсем Зәйнуллина,***
***Вәлиәхмәт кызы Нәсыйха Зәйдуллина,***
***Гәрәй кызы Минҗиһан Гиләчева,***
***Зәйдулла кызы Хәдичә Шәрәпова***
***һәм башкалар.***

Сүз уңаеннан, шушы исемлекләрне төзергә бик зур ярдәм күрсәткән авылдашыбыз Исмәгыйл Латыйповка олуг рәхмәтебезне белдерәсем килә. Ул 1987 – 1997 елларда Тупли мәктәбе мөдире булып эшләде.

Һәрберебез мәҗлескә белгәннәребезне укып килгән идек. Шулай ук әрвахлар рухына өч тулы Коръән багышланды, Аллаһыга шөкер. Раббыбыз укыганнарыбызны кабул итсен иде.

Коръән ашын безнең авылда туып-үскән, ә бүгенге көндә Самарда яшәүче Хәтимулла улы Габдулла Гыйльметдинов бик матур итеп алып барды. Аңа Аллаһының рәхмәтләре яусын.

Шуны да әйтеп үтәргә телим, күп классташларыбыз төрле сәбәпләр аркасында Коръән ашына килә алмадылар. Әмма, садакаларын җибәреп, безгә кушылдылар.

Бүгенге көндә, Аллаһыга шөкер, укытучыларыбыз – Гайнетдин улы Наил һәм Мөстәкыйм кызы Зөлфирә Гыйматдиновлар, Тәлгать кызы Равилә Зилидинова, Вәлиәхмәт кызы Әлфия Зилидинова исән-саулар. Мәҗлескә җыйган садакаларыбыздан аларга да өлеш чыгарып, үзләренә күчтәнәчләр алдык.

Шулай ук Тупли авылының өч мәчетенә хәерләребезне һәм вафат булган укытучыларның, мәктәп хезмәткәрләренең, классташларыбызның исемлекләрен җибәрдек. Аларның исемнәре Аллаһы йортында да искә алынып, рухларына догалар барып торсын иде.

Әлхәмдүлилләһ, безгә бик гыйлемле, дәрәҗәле, мактаулы, абруйлы мөгаллимнәр белем бирделәр.

Гайнетдин улы Наил абый Гыйматдинов физика дәресен алып барды. Ул “Б” сыйныфының җитәкчесе иде. Бүгенге көндә Наил әфәнде Тупли авылының Таш мәчете имамы булып хезмәт итә.

Аның хәләл җефете – Мөстәкыйм кызы Зөлфирә Гыйматдинова алгебра белән геометрия фәннәрен укытты, “А” классын җитәкләде.

Биш ел элек сыйныфташлар белән очрашу мәҗлесен нәкъ алар алып барганнар иде.

Тәлгать кызы Равилә Зилидинова, Вәлиәхмәт кызы Әлфия Зилидинова рус теле һәм әдәбияты дәресләрен алып бардылар.



Аркадий кызы Татьяна Ярушкина 5 – 7 сыйныфларда укыганда безнең класс җитәкчебез иде.

Аның ире - Арсентий улы Степан Ярушкин черчение һәм хезмәт дәресләреннән белем бирде.

Харис кызы Әлфия Гыйниятуллина җыр дәресләрен алып барды. Мәктәбебездә пианино бар иде. Әлфия апа уйный, без җырлый идек.

Александр кызы Анна Әбүзәрова тарих укытучысы иде.

Хөсәен улы Ибраһим Шәрәпов башлангыч хәрби әзерлек дәресен укытты.

Класстан тыш эшләр бүлеге мөдире Борһан улы Таһир Әбүзәровны да телгә аласым килә. Без сигезенче сыйныфта укыганда, кышкы каникулларда, ул мәктәпнең "яхшы" билгеләргә укыган балаларын, активистларны Харьков шәһәренә алып барган иде. Элек һәр елны укучыларны шулай төрле шәһәрләргә экскурсияләргә йөртәләр иде бит. Безгә, мәсәлән, Харьковны күреп кайтырга насыйп булды.

Атап үткән укытучыларыбыз бүгенге көндә исән-саулар, әлхәмдүлилләһ.

Вафат булган мөгаллимнәребездән татар телен укыткан Аләветдин кызы Галия апа Шәкүрованы, безне тракторда йөрергә өйрәткән Нәбиулла улы Хәйрулла Сафинны, алгебра дәресен алып барган Мөхәммәтгата улы Әнвәр Зилидиновны сагынып искә алабыз.

Беренче укытучыларыбыз - Илһам кызы Җария апа Дәүләтшина һәм Мотыйгулла кызы Гаян апа Хәлиуллина да йөрәкләребездә мәңгелеккә саклана-чаклар.

Мөгаллимнәребез безнең өчен икенче әти-әни булдылар. Безне чын күңелләреннән кайгыртып, үз балаларыдай күреп эшләделәр алар.

Башлангыч сыйныфларда икенче сменада укыдык. Кышларын мәктәптән чыкканда инде караңгы төшкән була иде. Укытучылар, һәрберебезгә шарфларны бәйләп, төймәләребезне элэктереп, бияләйләрне кидереп җибәрәләр. Бер очта яшәгәннәрне, сез бергә кайтасыз, дип, кулдан тоттырып озаталар иде.

Элеккеге елларда Туплидән өч чакрым ераклыкта урнашкан Чишмәле авылы булган. Без үскәндә ул беткән иде инде. Матур табигатьле җир бу. Урман эчендә коесы да бар. Без җәйләрне шунда оештырылган хезмәт лагерында уздыра идек. Палаткаларда яшәп, чөгендер утап, су кереп, футбол уйнап, спорт ярышларында катнашып, бик тә күңелле, кызыклы үтә иде ул чаклар! Укытучыларыбыз белән бергә эшли, бергә ашый идек. Алар безнең сердәшчеләребез дә, киңәшчеләребез дә булдылар.

Үзләре дә, кулларына китмән (мотыга) тотып, безнең белән беррәттән чөгендер утыйлар иде. Боларның барысы да безне тагын да берләштерә, якынлаштыра торган иде.

Шунысы мөһим – мөгаллимнәребез безгә белем генә түгел, төпле тәрбия дә бирделәр. Һәм сүз белән әйтеп кенә түгел, үз үрнәкләрендә күрсәтеп. Безгә остаз гына түгел, ә өлкән иптәш тә була белделәр. Аларга мең рәхмәтлебез.

Мәҗлес барышында Габдулла абый Гыйльметдинов да Тупли мәктәбе укытучылары турында күп сөйләде. "Без – бәхетле буын, мөгаллимнәребез безгә тирән белем һәм күркәм тәрбия бирделәр. Үзүзләрен аямыйча, җан-тәннәрен биреп, хезмәтләрен ихластан яратып, һәр балага зур игътибар һәм кай-



гырту күрсәтеп эшләделәр алар", - диде Габдулла әфәнде.

Бүгенге көндә дә, шөкер, укытучыларыбыз белән күрешеп, аралашып, киңәшеп яшибез. Үзләренә булган хөрмәт хисләребез еллар үткән саен кимеми, киресенчә, арта, ныгый гына бара. Алар да безне якын күрәләр. Инде үзебез дә олыгаеп, оныкларыбыз туып, әби-бабай булгач, мөгаллимнәребезнең фидакарь хезмәтен бик яхшы аңлыйбыз.

Аллаһыга шөкер, Коръән мәҗлесебез матур үтте. Барыбызның да Коръән сүрәләре укып килүе күңелгә ятты. Укытучылар, сыйныфташларыбыз рухына багышлап башкарылган эшебез бу. Бездән разый булып ятсыннар иде", - дип сөйләде ***Рифкать Хуҗин.***

Аның берничә классташыннан да уй-фикерләре белән уртаклашуларын сорадым.

***"Җәмилә Хәйруллова*** (кыз фамилиясе – ***Мингалиева***):

"Без гөрләп үстек. Һәр йортта диярлек сыйныфташларыбыз яши иде. Урамнан керми дә идек. Нинди күңелле вакытлар булды ул!

Бүгенге көндә дә бер-беребез белән аралашуыбызга бик шатланам. Бәйрәмнәр, туган көннәр белән котламыйча калмыйбыз.

Очрашу кичәләрендә классташларыбызны күргәч, күңел күтәрелә, яшәреп китәсең. Кызлар белән без аерым да күрешеп торабыз әле, кунакка йөрешәбез. Мәктәп елларындагы фотоларны карап, кызыклы хәлләрне искә алып, рәхәтләнеп сөйләшеп утырабыз.

Сыйныфташларым - минем өчен бик якын кешеләр. Ун ел буена, һәр көнне күрешеп, аралашып, бергә укып йөрдек бит.

Хөрмәтле укытучыларыбызны да бик сагынам. Безне кеше итеп чыгардылар алар. Наил абый, Зөлфирә апа Гыйматдиновлар белән берәрсенең мәҗлесендә очрашкач та, кочаклашабыз, хәл-әхвәл сорашабыз. Якын күрәләр, рәхмәт.

Раббыбыз безгә киләчәктә дә шундый дус булып гомер итәргә язсын иде".

***Нурия Миннигулова*** (кыз фамилиясе – ***Исхакова***):

"Без, "А" сыйныфында укучылар, барыбыз да авылның бер очында яшәдек. Мәктәптән, уйнап, шаярып, гел бергә кайта идек. Рифкать Хуҗин белән Юныс Вәлиев кына башка якта торалар иде. Рифкать әле дә: "Сез бөтенегез дә җыелып китә идегез. Ә без сезгә көнләшеп карап кала идек", - дип исенә төшерә.

Безнең балачак кызыклы булды шул. Балалар бик күп иде. Хәзер генә, укучылар саны аз булганга, кызганычка, мәктәбебез ябылды. Нарасыйлар Елховкага йөреп белем алалар.

Укытучыларыбыз бик яхшы иде безнең. Наил абый, Зөлфирә апа Гыйматдиновлар, Равилә апа, Әлфия апа Зилидиновалар, Галия апа Шәкурова һәм башкалар мөгаллим буларак та, кеше буларак та әйбәтләр иде. Наил абый таләпчән булды. Безнең малайлар аңардан куркалар иде инде (көлә). Безгә тирән белем, лаеклы тәрбия биргәннәре өчен үзләренә олуг рәхмәт.

Классташларыбыз белән укыганда да тату булдык, хәзер дә дуслык җепләрен өзмибез. Аллаһы бирсә, киләчәктә дә шулай булыр, дип ышанам".

***Ислам Хәкимов:***

"Мәктәп еллары истән чыкмый. Сыйныфыбыз бик тату, бердәм, актив булды безнең. Төрледән-төрле чараларда катнашып килдек. Бәйрәмнәр уңаеннан кичәләр үткәрә идек.

Ул чаклар миңа аеруча кадерле. Ник дисәгез, гомерлек мәхәббәтем нәкъ мәктәптә яралды минем. Классташым Хәзинә белән укыган елларда ук бер-беребезгә гашыйк булдык. Аннары өйләнештек һәм менә инде 34 ел бергә без. Бер кыз үстердек, бер оныгыбызга сөенеп туя алмыйбыз. Бәхетебез түгәрәк, әлхәмдүлилләһ.

"Бер күрешү – үзе бер гомер", - дип юкка гына әйтмиләр инде. Сыйныфташларым белән очрашу миндә һәрвакыт тирән тәэсирләр калдыра".

***Венера Шәрәпова*** (кыз фамилиясе – ***Дәүләтшина***):

"Мәктәп еллары, әлбәттә, сагындыра. Кызганыч, яшьлек үтте. Хәзер инде ул күңелле чакларны искә алырга гына кала.




Без барыбыз да яхшы укыдык, актив идек. Бер-беребезгә ярдәмләшеп үстек.

Мөгаллимнәребез искиткеч яхшы булды. Алар безгә укуда гына түгел, шәхси проблемаларыбызда да булышалар иде.

Сыйныфташларым белән күрешү минем өчен бер бәйрәм булып тора. Рифкатькә, Искәндәргә, кызларыбыз Нурия, Гөлгенә, Җәмиләгә рәхмәт. Алар инде - безнең иң актив кешеләребез, очрашуларны оештыралар, безне чакыралар, җыялар.

Классташларны күргәч, үзләренә шулкадәр күп нәрсәне сөйлисе килә. Тик вакыт җитеп бетми шул. Алар миңа үз туганнарымдай якын. Барысы да исән-сау, озын гомерле булсыннар».



Чанышев алда, сулдан икенче, Гыйззәтуллин артта, сулдан икенче

# Алар - яңа, бәхетле тормышка нигез салучы патриот-педагоглар

***Гражданнар сугышыннан соң, илдәге тормышны яңабаштан кору өчен, укымышлы кадрлар кирәклеге зур проблемага әверелә. Бу уңайдан яшь совет хөкүмәте халыкның белемен үстерү мәсьәләсен иң алгы планга куя.***

***Фәрид Шириязданов***

20нче гасыр башында патша Россиясендә яшәгән халыкның җитмеш проценты укый-яза белмәгәнгә күрә, бар җирдә дә балалар өчен мәктәпләр ачыла. Ә олы яштәге гражданнарга «Ликбезлар» һәм Халык университетлары эшли. Совет халкы дөньяда әлегәчә күренмәгән, яңа тормыш төзергә алынгач, бай хыялларга нигезләнгән, бөек күтәрелеш чоры башлана.

Киләчәкнең бәхетле булуына чын күңелдән инанган кешеләр, хезмәт батырлыклары күрсәтеп, хәрабәләр хәлендәге илне аякка бастырып, анда социализм төзергә керешәләр.

Ни кызганыч, тик бу хәерче заманда надан халыкны укымышлы итүгә, аграр илне индустрияле итүгә җаны-тәне белән бирелеп, үз гомерләрен шуңа багышлаган кешеләрнең казанышлары гына түгел, хәзер аларның исемнәре дә онытыла бара.

Шундыйларның берсе – Гариф Сибәгатуллович Гыйззәтуллин. Ул 1897 елда хәзерге Кошки районының Иске Фәйзулла авылында туа. Җиде яшендә, әтиәнисе үлгәч, ул тулы ятим кала. Ятимнәрне төрле гаиләләргә тараткан вакытта аны Кошки төбәгендәге бер авылда немецлар гаиләсенә асрауга бирәләр. Анда ул, кочегар вазыйфасын үтәп, мичләрен салам белән яга. Бу гаиләдә бай китапханә булганга, Гариф китаплар укырга ярата. Аның белемгә омтылуын күргәч, хуҗа немец үзен гимназиягә укырга бирә.

Гариф Сибәгатулла улы Гыйззәтуллин тормыш ачысын балачактан ук татыса да, үзенә Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән сәләтне, төрле мөмкинлекләрне кулланып, тәпле белем алуга ирешә. Тора-бара үзендә тупланган гыйлемне ул, авыр тормышта изелеп яшәгән надан халыкка да җиткереп, аны киләчәктә белемле, югары мәгърифәтле итү хыялы белән яши.

Гомумән, Гыйззәтуллиннар нәселендәге кешеләрнең тормыш юлын, җәмгыятьтәге урынын, башкарган эшләрен күзаллаганда алардагы белемгә омтылу ачык күренә. Гыйлемле шәхесләр, лидерлар буларак, аларның күбесе укытучылар, мәктәп директорлары, төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр булып танылалар.

Гариф аганың яшьлек еллары менә шул массакүләм наданлык белән аяусыз көрәш барган дәһшәтле заманнарга туры килә. Ул әле үзебезнең илдә генә түгел, Урта Азиядә колониаль басым астында яшәгән мөселман халыкларының да белемен, аң дәрәҗәсен үстерү, фикерләү офыгын киңәйтү өчен, аяусыз көрәшә.

Тарихтан белгәнебезчә, яшь совет властеның баштагы елларында Урта Азиядә озак еллар басмачыларга каршы киң җәелгән канлы көрәш бара. Бу вакытта партия съезды: «Об очередных задачах партии в национальном вопросе» дигән резолюция кабул итә. Анда Урта Азия халыкларының культурасын үстерү һәм андагы наданлыкка каршы көрәш алып бару турында җитди планнар корыла.

Бу авыр мәсьәләне гамәлгә ашыру өчен, Урта Идел җирлегендә яшәүче татарлардан торган мөселман батальоннары төзелә. Аларга, тугандаш төрки-мөселман халыкларын феодаль коллыктан азат итеп, үзләрен яңа тормыш юлына алып чыгу өчен, Шәрык (Восток) илләрендә мәгърифәт эшчәнлеген торгызу бурычы куела.

Мөселман батальоннары Урта Азия халыклары янына винтовкалар, пулемётлар белән генә килмиләр, алар әле китаплар, төрле фәннәр буенча төзелгән дәреслекләрне һәм башка уку әсбапларын да алып баралар.

Татар гаскәрләре үзләренең ата-бабалары да, шул җирләргә килеп, андагы халыкларга гасырлар дәвамында белем биргәнен һәм аларның аң дәрәҗәсен, культурасын үстерүгә зур өлеш кerтkәннәрен дә яхшы беләләр. Әлбәттә, бөтен Төркистан киңлекләрендә яшәгән казахлар, кыргызлар, төрекмәннәр, таҗиклар, үзбәкләр дә моны яхшы хәтерлиләр.

Мөселман батальоннары сугышчылары, аларның командирлары, политэшчеләре, җирле халыкларның теле татар теленә якын булганга, бу халыклар телен дә җиңел үзләштерәләр. Бу инде, үзара аңлашу, уңай мөнәсәбәтләр кору өчен, киң мөмкинлекләр ача.

1920-1931 елларда Гариф ага Гыйззәтуллин татар-мөселман гаскәрләре составында басмачылар белән барган канлы сугышларда катнаша. Алар бу көрәшне легендар полководец Якуб Җиһангирович Чанышев җитәкчелегендә алып баралар. Бу легендар шәхес әле Бөек Ватан сугышында да үзен оста хәрби стратег итеп таныта.

Ахырда Гариф Гыйззәтуллин, Кыргыз ССРның Фрунзе шәһәрендәге Аламедин районында укыту белән бергә, анда совет



*Гариф укытучылар белән*

власте урнаштыруда да актив катнаша. Бу елларда эчке реакция һәм чит илләрнең яшерен көчләре


ГРАМОТА

УЧАСТНИКУ СТРОИТЕЛЬСТВА ОБОРОННЫХ СООРУЖЕНИЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЫ

Товарищу [illegible]

Отмечая Вашу особо успешную работу на строительстве оборонительных сооружений в дни Великой Отечественной войны, Управление 24 Военно-Полевого Строительства [illegible] НКО СССР вручает Вам эту грамоту, как подлинному патриоту Социалистического Отечества, за образцовую дисциплинированность, высокое сознание своего долга и стахановский труд, проявленные Вами на строительстве оборонительных сооружений.

Начальник 24 Военно-Полевого Строительства [illegible] НКО СССР (ТОМСКИЙ).

Военный комиссар 24 Военно-Полевого Строительства [illegible] УОС НКО СССР (ЗАРНОВ).

белән дә аяусыз көрәш бара.

Укытучылар эшенә төрлечә аяк чалу белән бергә, аларны, төнлә өйләренә кереп яисә аулак җирдә сагалап торып, үтерәләр. Шундый куркыныч шартларда да алар озак еллар дәвамында наданлыкка каршы аяусыз көрәш алып баралар.

Фронтта дошман билгеле булып, капма-каршы торып сугышса, монда дошман, аларның кыриенда булса да, танылмый. Ул хәйләкәр, мәкерле, аны күреп тә, башкалардан аерып та булмый һәм аның кайчан, ничек һөҗүм итәсе дә билгесез була.

Ул елларда Гариф Гыйззәтуллин кышлак мәктәпләренә укытучылар әзерләү өчен оештырылган курсларда өч ел укып, аны тәмамлагач, укытучы булып эшли. Ахырда аны Фрунзе шәһәрендәге Аламедин районында РОНО мөдире итеп билгелиләр.

1931 елда ул үзенең туган ягына – Иске Фәйзулла авылына кайта. Анда Минҗиһан исемле кызга өйләнеп, тормыш корып җибәрәләр һәм дүрт бала үстерәләр.

Ул елларда үзенең туган ягында да халыктагы наданлык әле шактый көчле була. 1930нчы еллардагы колхозлар оештыру чорында шундый ук сыйнфый көрәш бара. Раскулачиваниеләр, сөргеннәргә сөрү, төрмәләргә озату, шул дәһшәтле чорларның билгесе буларак, илебез тарихына теркәлә.

Тормышны әлегәчә дөньяда күрелмәгән рәвештә, социаль нормаларга, гуманизм принципларына нигезләп кору өчен, укымышлы, алдынгы фикерле кадрлар әзерләү биредә дә зур проблема булып тора. Гариф Гыйззәтуллинга, Урта Азиядә феодализм шартларында яңа мәгърифәткә нигез салган, заманына күрә тәҗрибәле педагог буларак, монда да төрле авылларда яңача укыту эшләрен оештыруны йөклиләр:

1931-1935 елларда ул хәзерге Ульяновск өлкәсенә кергән Өчкаен авылы мәктәбе мөдире булып эшли,

1935-1937 елларда Иске Фәйзулла авылы мәктәбе директоры була.

1937-1941 елларда Ульяновск өлкәсендәге Колмаер районының Моисеевка авылындагы мәктәп директоры эшен башкара.

1941-1943 елларда ул Бөек Ватан сугышында катнаша. Сталинград өчен барган сугышта яралана һәм контузия ала. Җирнең асты өскә килгән мәшһәрдә ул: «Әгәр дә исән калсам, өемә кайткач, корбан чалып, Коръән укытам!» – дип, үз-үзенә вәгъдә бирә. Кайткач, вәгъдәсен үти – туганнарын, тирә-як күршеләрен чакырып, Коръән укыта. Тик моны ишетеп, аны партиядән төшерәләр. Тик авторитетлы укытучы булганга гына, эшеннән кумыйлар, башлангыч классларда укытырга мөмкинлек бирәләр.

1945 елда ул гаиләсе белән ТАССРның Октябрь районындагы Татарстан авылына күчә һәм анда укытучы булып эшкә урнаша. 1973 елда Нурлат шәһәрендә өй сала һәм шунда яши. 1981 елда вафат була.

Гариф ага Гыйззәтуллин катлаулы, ләкин дә бай эчтәлекле тормыш юлы үтә. Ул, чын мәгънәсендә утлар-сулар кичеп, тормышта якты эз калдырган үз чорының данлыклы бер вәкиле.

Алар төшкән фотоларны карaганда, шул давыллы елларда үз гомерен укытучы хезмәтенә багышлап, халкын белемле, тәрбияле итәргә омтылган педагоглар күз алдына килә. Күп авырлыклар аша үткәндә, киртәләр куеп, аркаларына атсалар да, алар, киләчәгебез якты һәм бәхетле булсын өчен, аяусыз көрәшкән чын патриотлар.



*Бөек Ватан сугышы. Гариф алда, уңнан беренче*

# “КҮРӘСЕЛӘРНЕ КҮРДЕМ ИНДЕ”



***Һаҗәр апа Мөгаллимова - сугыш чоры баласы. Быел 10 майда ул 90 яшьлек юбилеен билгеләп үтәргә җыена.***

***Һаҗәр апа Шенталы районы Денис авылында, Сәмига апа белән Шакирҗан абый гаиләсендә 6 баланың өченчесе, көтеп алынган беренче кыз бала булып дөньяга килә. Тыныч кына тормыш итеп ятканда, каһәр суккан сугыш башлана. Авылның бик күп ир-егетләре белән бергә Шакирҗан абыйны да сугышның беренче көненнән үк фронтка алалар. Иң кечкенә сеңелесенә ул вакытта бары тик ике атна гына булган.***

***Ильмира Мөстәкыймова, Эльмира СӘЙФУЛЛИНА***

Алты айдан соң, авылдаберенчеләрдән булып, алар кайгылы хәбәр алалар – әтиләренең үлгән хәбәре килә. “Сигез яшьлек бала булсам да, әле бүгенгедәй күз алдымда. Кара печатьле кәгазь килгәч, әнием сәкегә ятып елады, аңа сарылып, абыем белән мин елыйбыз, сеңелләрем безгә кушыла. Кан-яшь түкмәгән көн юк иде. Әтием сугышка беренчеләрдән булып китте, авылга үлгән хәбәре дә беренчеләрдән булып килде. Дөнья көтүнең бөтен авырлыгы әнием белән 15 яшьлек Мәүлемҗан абыем өстенә калды. Алар көне буе колхоз эшендә, ә мин кечкенә сеңелләрне карыйм. Имчәк суырган кечкенә сеңелемне ничек чыдатып бетергәнмендер инде, аңа кушылып үзем дә елый идем”, – дип сөйли Һаҗәр апа.



1943 елны 17 яшьлек Мәүлемҗан абыйсын да сугышка алалар. Өйдә этиләре урынына калган бердәнбер ир-ат, тормыш терәге, ашатучы, яклаучы була бит ул!

Нужа арбасына инде 13 яшьлек Һаҗәр җигелә. Шуңа да ике сыйныф кына укый ала ул. Абыйсы урынына трактор ярдәмчесе (плугарь) булып та йөрергә туры килә. Тракторчы Җәмил Гатин сабанга күтәреп утырта торган булган үзен.

“Хәзер шуларны уйлыйм да шаккатам, ничек йөрәк җитеп сабанда йөрелгән икән?! Бармас идең – ашарга кирәк, шуңа бер умачлык он бирәләр иде. Өйдә әни аны кайнар суга салып, болгатып җибәрә. Менә сиңа кайнар шулпа!

Ә җәй көннәрендә кузгалак, кычыткан коткара иде. Әле ярый үзебезнең бакчада әземкүпме бәрәңге чәчә идек, шул коткарып калды инде ачлыктан”, – дип искә ала Һаҗәр апа.

Сыер асрау бик авыр була, чөнки аны ашатырга, кыш чыгарырга салам кирәк. Ә колхозда салам бирмиләр. Бер вакыт шулай, 24 кеше – барысы да бала-чага һәм хатын-кызлар, 6 чакрым ераклыктагы Ташлы кырына сәнәскәләр тартып, төнлә салам урларга китәләр. Тарта алганчы төяп, кайтырга чыгалар. Коры елга сыртына күтәрелгәч, каршыларына 16 бүре килеп чыкмасынмы! Инде нишләргә? “Куркабыз, елыйбыз. Ярый әле бер апада шырпы булган. Саламнан кечкенә-кечкенә учма ясап, шуңа ут төртәбез дә йөгерәбез, төртәбез дә йөгерәбез. Бу бүреләрдән котылдык кына дигәндә, кыр капка төбендә икенче “бүре” – ферма мөдире саклап торган икән. Саламнарыбызны фермага бушаттырып, аркан-сәнәкләребезне алып калды. Сталин законы бик коры иде шул. Әле ярый төрмәгә җибәрмәде, шуңа шатландык”, – ди әңгәмәдәшем.

Һәр йортка 12 куб/метр урман кисү йөкләмәсе биргәннәр ул вакытта. „Бер-беребезгә иптәш тә булырбыз, ярдәм дә итешербез, дип, кыш көне иптәш кызым Мөхтәрәмә белән икебезгә Шарлы урманыннан 24 куб/метр агач кисеп, шуны үгезләр белән ташый идек. Ә язга чыккач, Шенталадан чәчү орлыгы ташыйбыз. 16 килограмм орлык төягән капчыкны 12 чакрымнан җилкәгә куеп яисә аркага асып алып кайта идек. Аякларда чабата, язгы суда ул юешләнә, „чәчәк ата”. Чабатаны да үзем тугырга өйрәндем. Өйдә ир-ат булмагач, бөтен ирләр эше үзебезнең өскә төште шул. Абыйдан өчпочмаклы хатлар ки-

леп тора. Түземсезлек белән көткән Җиңү көне дә килде. Ләкин ул безгә шатлык урынына кайгы гына ки-



терде. Исән-сау кайтыр дип көткән абыебызның һәлак булганына похоронка килде. Кайсыбер йорттан бер, ә кайсыбер йорттан бер дә юк, ә безнең йорттан ике кеше кайтмады, кайгы-хәсрәте дә күп булды, – дип сулкылдады Һаҗәр апа.

– Абыем белән бергә сугышка алынган һәм аннан исән-сау кайткан Сәлих абзый Хәкимов абыем турында болай сөйләгән иде: “40 градус салкында палаткаларда торабыз, аяк-куллар өши-туңа. Шунда Мәүлемҗанның аяклары туңды, ә командирлар ышанмыйлар, өенә кайтыр өчен, шулай кыланадыр, диләр. Йөри алмаслык хәлгә килгәч кенә, госпитальгә озаттылар. Син исән-сау өйгә кайтасың, ә без фронтка керәбез, дип, кочаклашып, елашып саубуллаштык. Ә ул Иркутск госпиталендә үлеп калган икән”. Әниебез гел «исән кеше бер кайта, тик безнекеләр генә кайтмас инде», – дип күз яшьләренә төялеп сөйли иде. Авыз тутырып, әти, дия алмыйча, яшьли ятим калып, кагылып-сугылып үстек инде.

17 яшендә Һаҗәр апа мәктәпкә техничка булып эшкә керә. Сталин үлгән көннәрдә ул кичке дежурда торган. Шул көнне стенадан Сталинның рәсемен урлаганнар, бу турыда районга хәбәр дә иткәннәр. Төне белән районнан кешеләр килеп, бөтен җирне бетереп эзләгәннәр – табалмаганнар. Гаепле кеше булып 17 яшьлек кыз кала. Бер укучы бала өенә алып киткән була портретны, ярый әле китереп биргән. «Ул вакыттагы куркулар, елаулар исемә төшсә, хәзер дә тәннәрем чемердәп китә. Әгәр рәсемен тапмасалар, төрмәгә алып китәләр иде. Сталинның үлеме мәңге хәтердә калды», – дип, күз яшьләре белән сөйли Һаҗәр апа.

Яшьли ятимлек ачысын татыган, ачлык-ялангачлыкны күреп үскән Һаҗәр апа 1953 ел ахырында вербовка белән Куйбышев шәһәренә китә.

Анда ташчы һөнәрен үзләштереп, лаеклы ялга чыкканчы, 33 ел Новокуйбышевскиның төзү-монтаж идарәсендә эшләп, бик күп Мактау кәгазьләре белән дә, акчалата премия белән дә бүләкләнә. “Лучший каменщик ордена Ленина строительно-монтажного треста №25”, “Ветеран стройки” дигән мактаулы исемнәргә лаек була. Беренче космонавт Юрий Гагарин исемендәге звездный вымпел белән дә бүләкләнә ул.

Денис авылында бердәнбер ташчы хатын-кыз ул. Авылыбыздагы күпме йортлар аның кулы белән салынган! Аның бакчасында нинди генә җимеш агачлары үсми! Ә капка төбендәге миләш агачлары язын хуш исле чәчәкләре белән, көзен кызыл тәлгәшле җимешләре белән урамны бизәп утыралар.

Кайгы агач башыннан түгел, кеше бышыннан йөри икән шул. 1981 елда әниләрен җирләгәннән



соң, ике көн дә үтми, Һаҗәр апаның сеңелесе Заидәнең армиядә хезмәт итүче улы Ильясның үле гәүдәсен кайтаралар.

Ә бер ел элек аның ире Барый фаҗигале төстә һәлак була. Шушы кайгы-хәсрәтләрне күтәрә алмыйча, сеңелесе Заидә, 50 яшен дә тутыра алмыйча, елый-елый сукраеп, якты дөньяны ташлап китә.

Кеше күрәсен күрми гүргә керми, ди халык мәкале. Инде олыгайган көнегездә бүтән авырлыклар күрмичә, хәләл пенсиягезнең рәхәтен, авылдашларыгызның хөрмәтен, туганнарыгызның ярдәмен тоеп, тынычлыкта, саулыкта яшәргә язсын сезгә, Һаҗәр апа.



*“Безнең Мәрвәр апабыз - искиткеч ярдәмчел, мәрхәмәтле кеше! Рәхим итеп, аның турында мәкалә язмассызмы икән, башкаларга да яхшы үрнәк булыр иде”, - дип, берничә кеше мөрәҗәгать итте миңа Похвистнево районының Гали авылыннан.*

*Миләүшә Газимова*

# КҮҢЕЛЕ ТУЛЫ НУР, ЙӨРӘГЕ ТУЛЫ МӘРХӘМӘТ

Аларның үтенеченә колак салып, Шиһаб кызы Мәрвәр Латыйпова белән әңгәмә корырга булдым. Һәм, әйтергә кирәк, милләттәшебез белән аралашу миндә җылы хисләр калдырды. Мәрвәр апа ачык йөзле, ихластан, рәхәтләнеп, бик ипле итеп сөйләшүче, йомшак күңелле ханым булып чыкты. Үзе бик дини, иманлы, әңгәмә барышында да, Аллаһы Тәгаләне гел искә алып, Аңа шөкерана кылып торды ул.

Мәрвәр ханым Гали авылында туып-үскән.

– Әти-әнием Ислам кануннарын үтәп яшәделәр, биш вакыт намазларын калдырмадылар, Коръән укыйлар иде.

Бездә дә кечкенәдән динебезгә хөрмәт-мәхәббәт тәрбияләделәр алар, Ислам таләпләрен сеңдереп үстерделәр. Икесе дә, җиң сызганып, колхозда эшләде.

Без гаиләдә тугыз бала идек. Кызганычка, бертуганнарымның икесе балачакта вафат булдылар. Мин калган җиде нарасыйның иң кечкенәсе идем.

Дини гаиләдә балаларга дөрес тәрбия бирелә бит ул. Әлхәмдүлилләһ, әти-әниебез үзләрендә булган барлык күркәм сыйфатларны безгә дә күчерергә тырыштылар. Һәм сүз белән генә түгел, үз үрнәкләрендә күрсәтеп. Шөкер, нәселебездә аракы эчүче, тәмәке тартучылар да юк.

Ата-анамның: “Кешегә беркайчан да ачу сакламагыз, миһербанлы булыгыз. Гомерләр бик кыска, күбрәк игелекле гамәлләр кылып, башкаларга булышып яшәргә тырышыгыз. Мәңгелек тормышта барысы өчен дә җавап бирәчәгебез бар”, – дигән сүзләрен һич кенә дә онытасым юк, – дип исенә төшерә газиз кешеләрен Мәрвәр апа.

Нәкъ әти-әнисе тәрбиясенең татлы бер җимеше – ярдәмчеллек сыйфаты милләттәшебезгә ак халатлы һөнәрне сайлап алырга этәргеч биргән дә инде.

Сигезенче сыйныфтан соң ул Похвистнево шәһәрендә медицина училищесын тәмамлаган.

– Бу профессия турында кечкенәдән хыялландым. Иптәшләремнең, күрше-тирәләрнең, туганнарымның, бигрәк тә әти-әниемнең, авырганын күрсәм, үзләренә булышасым, чирләрдән дәвалыйсым, хәлләрен яхшыртасым килә иде.

Авыргач, кешегә берни дә кирәкми бит ул, аның кәефе кырыла, күңеле төшә. Ә мин, алар елмайсыннар, бәхетле булсыннар өчен, үз өлешемне кертергә, ярдәм итәргә тели идем.

Шуңа күрә мәктәптән соң, бер дә икеләнеп тормыйча, медицина училищесына юл тоттым, – дип сөйли язмам герое.

Укудан соң яшь фельдшерны Чуваш Байтуганы авылына җибәрәләр. Биредә ике ел гына эшләп кала ул. Очрашып йөргән авылдаш егетенә кияүгә чыгып, Галигә әйләнеп кайта һәм күршедә урнашкан Ырсай исемле чуваш авылы хастаханәсендә эшли башлый.

– Егерме биш койкалык стационарда 35 ел хезмәт иттем. Шулай итеп, барлыгы 37 ел стаж белән пенсиягә чыктым.

Табиблар белән дә, шәфкать туташлары, санитаркалар белән дә, шулкадәр дус булып, рәхәтләнеп



эшләдек без! Барысы да уңган, тырыш, гадел, мәрхәмәтле кешеләр иде. Әле дә күпләре белән элемтәләребез өзелми. Аралашып,

кунакка йөрешеп яшибез. Бергә хезмәт иткән күңелле чаклар хәзер дә сагындыра.

Эшемне бик тә яратып башкардым мин. Анда барасы килеп тора иде. Көн узгач, и-и-и, инде өйгә кайтырга, дип, хастаханәдән китәсе дә килми иде.



Кешеләргә ярдәм итеп, алардан ихлас рәхмәт сүзләрен ишетүгә генә дә ни торды бит!

Мин эшләгән соңгы елларда хастаханәбездә медик-социаль ярдәм күрсәтү бүлеген ачтылар. Без анда ялгыз калган олыларны карадык. Якыннары булмагач, төрле җирләрдән матди ярдәм эзләп, аларны үзебезгә җирләргә дә туры килә иде.

Безнең диндәге кешеләрне, Галигә китереп, мөселман кануннары буенча соңгы юлга озата идек.

Ул вакытларда авылыбызның колбаса җитештерү цехы хуҗасы, мәрхүм Расыйх Латыйпов безгә күп булышты. Урыны оҗмахта булсын, – дип исенә төшерә әңгәмәдәшем.

Инде күптән лаеклы ялга чыкса да, Мәрвәр апага халык әле бүген дә мөрәҗәгать итә икән. Беренче медицина ярдәмен дә күрсәтә ул, тәҗрибәле, гыйлемле медицина хезмәткәре булганлыктан, файдалы киңәшләрен дә бирә.

Алтмыш тугыз яшендә дә белемен чарлап торырга тырыша, китаплар күп укый, заманадан артта калмый.

45–47 яшьләр тирәсендә Мәрвәр апа ныклап дингә кереп киткән. Биш вакыт намаз укый, ураза тота башлаган. Коръән укырга өйрәнгән.

– Бөтен хыялым хаҗга бару иде. Аллаһы Тәгаләгә мең шөкер, миңа шушы бәхетне ике мәртәбә насыйп итте. Өченче тапкыр исә гомрә хаҗын кылдым, – дип чиксез сөенечен белдерде Мәрвәр ханым Латыйпова.

Изге җирләрдән алып кайткан тәэсирләре белән дә уртаклашты ул.

– Анда бер барсаң, гел барасы килеп тора. Авырлыклар аша узарга туры килсә дә, күңел һәрвакыт шунда тарта.

Хаҗда шулкадәр рәхәт, күздән шатлык яшьләре агып тора. Бу халәтне сүз белән генә әйтеп, аңлатып бирерлек түгел.

Изге җирләрдә Аллаһы Тәгаләдән үзең өчен генә сорамыйсың, якыннарың, туганнарың, күршеләрең, ахирәт дусларың, авылдашларың, милләттәшләрең, диндәшләрең өчен дә үтенәсең.

Раббым балаларыма һәм, гомумән, һәр тәкъва мөселман бәндәсенә шушындый олуг бәхетне насыйп әйләсен иде, – дип сөйләгәндә, ихлас күз яшьләрен тыя алмады Мәрвәр апа.

Тормышта аның тагын бер олуг бәхете – үзеннән соң догачы балалар калдыруы.

– Раббыма мең-мең рәхмәт, кызым Дания, улым Наил, киленем Гөлназ да намаз укыйлар, киявем Равил дә җомгаларга йөри. Дин юлыннан атлаучы, тәүфыйклы балалар – ана өчен бик зур бәхет, бик зур нигъмәт бит ул.

Әлхәмдүлилләһ, алардан мин бик канәгать. Тәртипле булып үстеләр, хафа-борчу китермәделәр. Кечкенәдән хезмәттә чыныгып үстеләр, бәбкәйләрем. Без ирем белән иртәдән кичкә кадәр эштә. Алар маллар да карыйлар, бакчада да мәш киләләр иде инде.

Әлхәмдүлилләһ, икесе дә, гаилә корып, үз авылыбызда йортлар булдырып, матур гына тормыш алып баралар.

Миңа да кадер-хөрмәт күрсәтәләр, булышалар, үзара да, дус булып, туганлык җепләрен саклап яшиләр.

Кызым белән киявем – үгезләр, улым һәм киленем атлар асрыйлар. Шулай, бик тырышып, үз көннәрен үзләре күрәләр.

Наил һәм Гөлназ белән 15 ел бергә тордык без. Хәзер инде алар безнең йортта ук үзләренә аерым өй салып керделәр. Миңа рәхәт инде, кар көрәгәнем дә, бакча чәчкәнем дә юк (елмая).

Килен белән кияүдән дә уңдым, дип, тулы ышаныч белән, горурланып әйтә алам, Аллаһыга шөкер.

Биш оныкның бәхетле әбисе мин.

Даниянең игезәк уллары бар. Шамилебез өйләнде инде, Самарда торалар. Искәндәр әле әти-әнисе белән яши, үзләренә хуҗалыкта ярдәм итә.

Ә кызлары Камилә сигезенче сыйныфта белем ала.

Наилнең кызы Әлфия, минем эздән китеп, медицина өлкәсен сайлап алды. Самар институтында дүртенче курсны тәмамлый, Аллаһы теләсә, педиатр булачак.

Уллары Расих тугызынчы сыйныфта укый.



*Оныгы Камилә.*

– ***Мәрвәр апа, ә вафат булган ирегез турында нинди сүзләр әйтә аласыз?*** – дип мөрәҗәгать иттем әңгәмәдәшемә.

– Хәләл җефетем Әнәс бик тә әйбәт, йомшак күңелле иде. Ул да – дини нәселдән. Кызганыч ки, 24 ел гына бергә яшәп калдык шул.

Ул ветеринария табибы иде. Без аның белән бергәләп Ырсай авылына йөреп эшләдек.

Урыны җәннәт түрләрендә булсын, дип догалар кылам.

***– Сез кешеләрдә нинди сыйфатларны өстен күрәсез?***

– Ачык, гадел, туры юлдан баручылар ошый миңа. Дин тотучыларны сөям. Матур итеп мөселманча киенеп йөрүчеләрне яратам.

***– Бүгенге яшьләргә нинди бәя бирер идегез?***

– Алардан канәгать мин. Күпләре тырыша, тормыш котә, гаилә кора, балалар үстерә.

Шунысы куандыра – дингә тартылалар, мәчет-мәдрәсәләргә йөриләр, Аллаһыга шөкер.

Менә мин үзебезнең авыл мәдрәсәсенә дини гыйлемемне үстерергә йөрим. Яшь кенә мөгаллимнәребезнең акыллы, белемле булуларына исләрем китә. Үзләрен тын да алмыйча тыңлап утырасың.

***– Бүгенге көндә нәрсәләргә шатланып яшисез?***

– Аллаһы Тәгалә биргән исәнлеккә, бала-оныкларымның саусәламәт, дини, иманлы булуларына сөенеп туя алмыйм, шөкер.

Газиз туган авылымда гомер итүем белән бик бәхетле мин, Галиемне өзелеп яратам. Халкыбыз яхшы, эшчән, ярдәмчел, тату.

Раббым дөньяларыбызга, илебезгә тынычлык бирә күрсен, бүгенге аянычлы хәлләр тиз арада хәерлесе белән тәмамлансын иде, дип догалар кылам.

***– Яшьләргә нинди киңәшләр бирер идегез?***

– Дин юлыннан атлаган кеше бәхетле була ул. Ислам таләпләрен үтәп яшәсеннәр иде, дип теләр идем.

Медицина хезмәткәре булып эшләгән кеше буларак, сәламәт яшәү рәвеше алып барырга, спорт белән шөгыльләнергә киңәш итәм, – дип тәмамлады сүзен милләттәшебез.

Мәрвәр апа үзе дә көн саен скандинавия йөреше белән шөгыльләнә икән. "Файдасын бик күрәм", – ди ул һәм башкаларга да бу спорт төрен киңәш итә.

Гомумән, язмам герое актив яшәү рәвеше алып бара. Оста итеп шахмат уйный, оныкларын да моңа өйрәткән. Үзенә сканвордлар чишәргә ошый. Җәйләрен күпләп дару үләннәре җыя.

Ризыкларның да нинди генә төрләрен пешерми. Аеруча бәлеш салырга, тортлар ясарга ярата, ди.

Ә бисер белән чигүне инде әйтеп торасы да юк. Диварларына (стена) эленгән рамка эчендәге чиккән мәчет сурәтләре бөтен өенә ямь биреп торалар.

Авылдашлары Мәрвәр ханым Латыйпова турында әйткән сүзләрне дә мәкаләмдә китермичә булдыра алмыйм. Шундый җылы алар, шундый ихлас, шундый җанга ятышлы…



*Оныклары -Әлфия һәм Расих.*

***Кәүсәрия Шәйхетдинова,***

*Гали авылының "Ак калфак" татар хатын-кызлары оешмасы җитәкчесе, активист:*

"Мәрвәр апа – бик тыйнак, сабыр, гыйлемле, тәҗрибәле ханым.

Ырсайда хастаханә булган вакытта безнең авыл кешеләренә дә шундый уңай иде. Мәрвәр апа анда эшләгәч, аның тарафыннан үзләренә тиешле игътибар, яхшы мөгамәлә күрсәтелде. Бигрәк тә олылар аңа рәхмәтләрен әйтеп бетерә алмыйлар иде инде, бик яраттылар үзен.

Мәрвәр апабыз шундый ярдәмчел ки, мин аңа шаккатам. Теләсә кайсы вакытта мөрәҗәгать итәргә була, һәрвакыт тәпле киңәшен бирер, һәркемгә ярдәм кулын сузар.

Бер дә иренми ул. Гел хәрәкәттә, гел үз өстендә эшли, китаплар укый.

Беркайчан да кычкырып сөйләшми, тыныч, йомшак кына аралаша, түземлек белән аңлата.

Аңа карасаң, әкрен кешедәй, ә үзе әллә нинди эшләр майтарып ташлый. Һәрьяклап килгән, һәрьяклап уңган-булган.

Аш-суга да, кул эшләренә дә оста. Күлмәкләрен үзе тегеп кия, чигә.

Тәртипле хатын, балалары да ипле, тәрбияле.

Мәрвәр ханым Латыйпова дин ягыннан да белемен һәрдаим камилләштереп тора. Үзен табыннарга укырга чакыралар.

Мин Мәрвәр апаны бик хөрмәт итәм. Исән-сау, озын гомерле булсын".

***Зәйтүнә Газизуллина,***

*Гали авыл җирлеге башлыгының урынбасары:*

"Мәрвәр апа – минем күршем. Икебезнең арада бер кечкенә капка бар, бер-беребезгә шуңардан гына кереп-чыгып йөрибез.

"Күрше хакы – Аллаһы хакы", диләр бит. Ул күрше хакын хаклап яши.

Кайгыларны да, шатлыкларны да бергә бүлешеп гомер итәбез, Аллаһыга шөкер.

Без бер йортта яшәгән кебек, бер гаиләдәй.

Аның ире дә бик әйбәт иде. Балалары да нәкъ шундый.

Шулхәтле ярдәмчел, ачык йөзле, киң күңелле, мәрхәмәтле күршем булганга, мин бик бәхетле!

Мәрвәр апага барысы өчен дә рәхмәт".

*Гали авылында туып-үскән, бүгенге көндә Самарда яшәүче* ***Нәфисә Исхакова:***

"Мәрвәр апа Латыйпова миңа үз апамдай якын. Аңардагы кешелеклелек, аңардагы шәфкатьлелек!

Без хаҗда бергә булдык. Ул елны Галидән анда күп кеше барган иде. Мәрвәр апа авылдашларына шундый булышты ки, үзләрен куллрында күтәреп кенә йөртмәде инде менә.

Медицина буенча берәр сорау барлыкка килсә, шунда ук Мәрвәр апага шалтыратам. Һичкайчан караңгы йөз күрсәтмәс, акыллы киңәшен бирер.

Кылган изгелекләре өчен Раббыбыз Мәрвәр апага савапларын кайтарсын иде".

# “Хатыным белән бүлешеп түгел, бер-беребезгә булышып гомер иттек”

*“Күзләр – күңел көзгесе”, - дип белеп әйтәләр дә инде. Нурлы күзләре кешенең игелекле, миһербанлы булуын күрсәтеп торуына күп тапкырлар инанганым бар.*

*Миләүшә Газимова*



Менә Әндәрҗан бабайның да күзләре шундый нурлы. Һәм күңеле дә саф, матур, холкы күркәм аның.

Елховка районының Тупли авылында туып-үсеп, гомере буе шушында яшәүче Әндәрҗан Мөбарәкҗан улы Гайнетдинов дүртенче февральдә 85 яшен тутырды.

Әлбәттә, шушы дәвер эчендә шатлыклар да күп булган. Авырлыклар, кайгылар да читләп узмаган. Шулай да, 85 еллык го-



***Әндәрҗан абый һәм Өммегөлсем апа.***

мер бәхетлеләргә генә бирелә. Ә инде шуларның 63 елын яраткан хәләл җефетең белән яшәү икеләтә бәхетлеләргә насыйп була. Әндәрҗан абый да сөйкемле хатыны Өммегөлсемнең янәшәсендә булуына сөенеп туя алмый һәм моның өчен Аллаһы Тәгаләгә шөкер кыла.

Милләттәшебезнең балачагы сугыш чорына һәм аннан соңгы елларга туры килә. Шуңа күрә аның кечкенә һәм яшүсмер чакларының ничек үткәнен күз алдына китерәсездер.

Бөек Ватан сугышына киткән әтисе Мөбарәкҗан 1943 елда Курск дугасында һәлак булган. Ул Орлов өлкәсенең Татариново авылында туганлык каберлегендә җирләнгән.

Әнисе Гыйлемзадә өч баланы берүзе аякка бастырган.

– Әниебез иртәдән кичкә кадәр колхозда эшләде. Үсә төшкәч, без кул арасына керә башладык. Йорт хуҗалыгында әнигә ярдәмче булдык. Шулай, апам, абыем һәм мин бәләкәйдән хезмәттә чыныгып үстек. Кышын – сәнәскә, җәен “уф алла” арбасын тарттык. Урманнан утынлык агач, мал-туарга печән ташый идек.

Әниемә мин бүгенге көндә дә рәхмәтле. Бик тә йомшак күңелле кеше иде ул. Безгә күркәм тәрбия бирде.

Бер генә мисал китерәсем килә. Миңа 7–8 яшьләр булгандыр. Янәшәбездә бер буш йорт бар иде. Без малайлар белән шунда уйнарга кердек. Мин анда унлы лампа таптым да өйгә алып кайттым. Үземчә әнине шатландырасым килде. Янәсе, бездә җиделе генә бит, ә бу унлы лампа! Шунда әнием: “Улым, моны кайдан алдың?” – дип сорады. “Теге буш йорттан. Анда берсе дә яшәми бит”, – дим. Ә ул миңа: “Тормасалар да, каян алдың, хәзер үк урынына илтеп куйган бул. Һичкемгә усаллык эшләмә, беркайчан да кеше әйберенә тиясе булма”, – дигән иде. Әниемнең шушы сүзләрен гомерлеккә истә калдырдым.

Бабабыз үлгәч, әниебез әбине үзебезгә алды. Шулай, безне, балаларын да, үз анасын да бик яхшы карады, тәрбия кылды, – дип искә ала Әндәрҗан бабай.

Җиде сыйныфны тәмамлагач, малай колхозда эшли башлый. Башта су ташучы була ул. Аннары башка төрле эшләргә керешә. Атта кышын терлекләргә – азык, җәен комбайннан иген ташый.

Гыйлемгә омтылышлы Әндәрҗан, мөмкинлек барлыкка килгәч тә, укуын кичке мәктәптә дәвам итеп, анда ун сыйныф тәмамлый. Соңрак Самарда (ул вакытта Куйбышев) осеменатор һөнәрен үзләштереп кайта.

– 1958 елда “Теплый Стан” күмәк хуҗалыгын Борһан әфәнде Әбүзәров җитәкләде. Ул колхозны күтәрде, аны алдынгылар сафына бастырды, авыл халкы тормышын яхшыртыр өчен, олуг эшләр башкарды.

Борһан әфәнде җитәкчелек иткән елларда тегермән, остаханәләр, ашлык тогы, унъеллык мәктәп һәм башка бик күп нәрсәләр төзелде.

Шул исәптән, зур ферма да сафка басты. Мин шунда күп еллар терлекче булып эшләдем. Аннан бригадир хезмәтен дә башкардым. Һәм инде 60 яшемдә лаеклы ялга чыктым, – дип сөйли Әндәрҗан абый.

Хезмәтен яратып, җиренә житкереп, зур көч, тырышлык куеп, җаваплылык белән башкарган милләттәшебез эшендә югары уңышларга ирешә.



*Әндәрҗан һәм Өммегөлсем Гайнетдиновларның яшь чагы.*

1973 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә ул.

– Гомер буе хатыным белән икәүләп фермада көч куйдык. Отпуск алу да булмады. Иртәнге сәгать биштә йокыдан торып, эшкә чаба идек. Авылыбыз иминлеге хакына тырыштык, үз өлешебезне керттек, әлхәмдүлилләһ, – ди хезмәт ветераны, Атказанган колхозчы, социалистик ярышлар алдынгысы, “Хезмәттәге батырлыгы өчен” медаленә һәм күп санлы Мактаунамәләргә ия булган Әндәрҗан Гайнетдинов.

Лаеклы ялга чыккач, милләттәшебез дин юлына баса, намаз укый башлый, Ислам таләпләрен үтәп яши.

Башта биш ел Тупли авылының “Колмаер” мәчетендә мөәзин була ул. Аннары үзен имам итеп билгелиләр. Шулай, тагын сигез ел ике вазифаны да лаеклы рәвештә башкарып килә Әндәрҗан әфәнде.

Ә инде аннары, сәламәтлеге какшау сәбәпле, яшьләргә юл бирә. Шулай да, бүгенге көндә дә Аллаһы йортына йөреп, гыйбадәтләрен кыла, мөселман кардәшләренә дини белем һәм тәрбия бирүгә үз өлешен кертә.

– Дин юлына басуыма иксезчиксез бәхетле мин. Бәлки, әтиемнең догасы кабул булгандыр.

Сөйләгәннәрдән шуны беләм. Бервакыт әти каядыр кунакка барган булган һәм анда Әндәрҗан исемле бер мулла белән танышкан. Ул кеше күңеленә шулкадәр хуш килгән ки, әтием: “Әгәр дә тагын бер малаем туса, аңа Әндәрҗан дип исем кушар идем. Бәлки, ул да шулай дин юлында хезмәт куяр иде”, – дигән. Әтинең шушы сүзләре фәрештәләрнең “Амин!” дигән вакытына туры килгән, күрәсең, – ди язмам герое.

***– Әндәрҗан абый, яшь чакларыгызны исегезгә төшереп алыйк әле. Өммегөлсем апаның нинди сыйфатларын ошатып өйләндегез?*** – дип мөрәҗәгать иттем әңгәмәдәшемә.

– Без аның белән бер сыйныфта укыдык. 20 яшьләребездә очрашып йөри башладык. Ике елдан соң өйләнештек.

Күркәм холыклы, акыллы, дини булуын ошаттым.

Бик тәртипле, төпле гаиләдән ул. Бабасы мөәзин булган. Әти-әнисе дә намаз иялэре, бик дини кешеләр иде.

Өммегөлсем җиде сыйныфны тәмамлагач, әнисе аны да намазга бастырган. Шуннан бирле гомере буе гыйбадәт кылып яши ул.

Әлхәмдүлилләһ, матур тормыш алып бардык. Бер-беребезне хөрмәт иттек, тыңладык, рәнҗетмәдек.

Минем әни безнең белән бергә торды. 93 яшендә вафат булды ул. Хәләл җефетемә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре яусын, әниебезне шулкадәр яхшы карады, аңа карата йомшак мөгамәләдә булды, беркайчан сүзгә килмәде.

***– Ә балаларыгыздан канәгать булып яшисезме?***

– Өч ул, өч кыз үстердек. Гөлсинә, Гөлбану, Рәхимҗан, Галиҗан, Нурислам, Зөләйха тәртипле, тәүфыйклы, акыллы булып үстеләр, битебезгә кызыллык китермәделәр, Аллаһыга шөкер.

Безгә дә булышып үстеләр, Гыйлемзадә әбиләрен дә караштылар, үзен бик яраталар иде.

Кызганыч ки, кайгы җиле безнең капканы да какмыйча калмады. Кызыбыз Гөлсинә һәм улыбыз Нурислам вакытсыз вафат булдылар. Ата-анага балаларын җирләргә туры килмәсен иде дә бит. Нишлисең инде, Аллаһы Тәгалә шулай язган булган.

Улларыбыз, кызларыбыздан бик канәгать без. Кадер-хөрмәттә яшәтәләр, бик зур ярдәм күрсәтәләр. Әлхәмдүлилләһ, балаларыбыз да дин юлында, намаз укыйлар, мәчеткә йөриләр.

Оныкларга бай әби, бабай без. Унбер оныгыбыз, унбер туруныбыз бар. Алар да безгә карата ихтирамлы, яратып, әби, бабай, дип кенә торалар. Нәселебез зур, Аллаһыга шөкер. Барыбыз бергә 38 кеше җыелабыз. Бала-оныкларыбызның татар телендә сөйләшүе дә безнең өчен зур шатлык булып тора.



*Әндәрҗан абый һәм Өммегөлсем апа балалары, кияүләре, киленнәре һәм туганнары арасында.*

Үзләренә барысы өчен дә Аллаһы Тәгаләнең киң рәхмәтләре, саваплары яусын.

***– Гаиләдә ир, ир хатын баш була. Сездә тормыш дилбегәсен кем тотып барды?***

– Өммегөлсем белән бүлешеп түгел, бер-беребезгә булышып гомер иттек.

Кем баш икәнен күрсәтү булмады бездә. Фермада бергәләп көч түктек, балаларны бергәләп күтәрдек. Эштән кайткач, ул өйгә ризык әзерләргә кереп китә, мин маллар карарга чыга идем.

Хатыным мине һәрвакыт ир итте, зурлады. Мин дә аңа тиешле мөнәсәбәт күрсәттем, үзен сакладым-яkладым.

Бер-беребезнең күңелен күреп, киңәшләшеп яшәдек, Аллаһыга шөкер. Араларыбыз яхшы булгач, 63 ел, бер мизгелдәй, сизелмичә үтте дә китте.

***– Хәзер яшьләр арасында аерылучылар күп бит. Сезнең кебек, җәмәгатең белән озак еллар бәхетле гомер итүнең сере нидә?***

– Бер-берең белән аңлашып, тыңлашып яшәргә кирәк. Эшен дә, малын да бүлешмәскә.

Хәзер яшьләрне эти-әниләр үзләре боза. Балалары машина сораса, алып бирәләр, фатир сораса, алып бирәләр. "Үзем тапкан мал түгел, эти тапкан җәл түгел", – дип дөрес әйтәләр. Үзең эшләп, көч түгеп алганның кадерен беләсең ул. Әзергә бәзер яшәүче яшьләрнең холкы бозыла, дип саныйм. Шуңа күрә яшь парлар арасында талаш, мал бүлешү китә. Хәзерге егетләр-кызлар түзеп, аерылышудан оялып тормыйлар бит. Аралары бераз суынды икән, икесе ике якка китеп бара.

Кушылганчы якынлык кылалар, өйләнешкәнче бергә тора башлыйлар. Аннары берсенең кияүгә чыгасы килә. Ә тегесенең ЗАГСка барасы килми, аңа болай да начар түгел. Һаман да шул ук ыгы-зыгы куба, бәхәсләр китә, аңлашылмаучылык барлыкка килә.

***– Әндәрҗан абый, кешеләрдә нинди сыйфатларны хөрмәт итәсез?***

– Аллаһы Тәгаләне яратучыларны сөям. Кем намаз укый, Раббыбызның барлыгын, берлеген таный, шулар белән матур мөнәсәбәттә яшим, әлхәмдүлилләһ.

Бүгенге көндә яшьләрнең дингә тартылуына куанам. Әгәр дә Ислам кануннарын үтәмисең икән, "Мин – мөселман!" – дип гайрәт чәчеп йөрү дөрес түгел, минемчә. Шуңа күрә Раббыбыз кушканнарны үтәп, тыйганнардан тыелып, хәләлне кулланып, хәрамнән ваз кичеп яшәргә тырышырга кирәк.

***– 85 яшь – озын гомер. Узган тормышыгызга борылып карасагыз, аны ничек тасвирлар идегез?***

– Әнием балачактан туры юлга бастырды. Халык арасында эшләдем. Раббыма шөкер, кеше рәнҗетмәдем, үзем дә берсенә дә рәнҗемәдем.

Аллаһы Тәгалә тәүфыйк-һидәят биреп, дингә килдем, Ислам юлында хезмәт иттем, әлхәмдүлилләһ.

Раббым, балаларыбызга дөрес тәрбия биреп, үзебезгә бәхетле картлыкка нигез салырга ярдәм итте.

Газиз туган авылымда гомер кичерәм. Халкыбыз яхшы, тату, ярдәмчел. Бер-беребезне хөрмәтләп көн күрәбез. Авылдашларыма бик рәхмәтлемен.

Шуларның барысы да минем өчен – олуг бәхет. Шуңа күрә тормышым юкка үтмәде, дип әйтә алам, Аллаһыга мең шөкер.

Бу дөньядан тулы Иман белән китәргә язсын.

Милләттәшләребез туган телебезне, динебезне саклап, үстереп яшәсеннәр иде.

Яшьләребез Исламны куәтләүче, татар телендә сөйләшүче кешеләр булып җитлексеннәр иде, дигән теләктә калам.

"Әтиебезнең балачагы авыр елларга туры килгән. "Бер ямаган фуфайка бар иде. Шуны бер көнне – абый, бер көнне мин киеп, кич утырырга чыга идек", – дип сөйли әти.

Әниебез дә 14 яшеннән колхозда сыер савучы булып эшли башлаган. Без фермада үстек, дияргә була. Декрет отпускасы юк иде. Балалары кечкенә булса да, эшкә йөрде әниебез.

Шулай, бик тырышып, нужа күреп, безне, алты баланы, аякка бастырдылар. Кешедән ким-хур булмадык, Аллаһыга шөкер. Артыгы да юк иде, әмма барлыкта үстек. Күп итеп терлек тоттык, кыр хәтле бакчабыз иде. Яшәргә бөтенесе дә җитте.

Эти-әни барыбызны да укытып



Пар канатлы булу - нинди зур бәхет!

чыгардылар. Өчебез – югары, калганнарыбыз урта махсус белем алдык.

"Гыйлем алыгыз. Укыган кешеләр башлы, акыллы була", – дия иде безгә эти. Сүзен тыңладык, тырыштык.

Әтинең безгә бармак та тидергәне булмады. Барысын да сүз белән аңлатып, төшендереп бирә иде.

Бабайлар тәрбиясен күрергә насыйп булмады безгә. Ә мәнә Гыйльмеҗиһан, Гыйлемзадә әбиләребезнең үгет-нәсыйхәтләрен күңелебезгә сеңдереп үстек.

Гыйлемзадә әби күп еллар безнең белән бергә яшәде. Ул бик гыйлемле иде. Безгә кечкенәдән догалар өйрәтте.

Әтиебезгә дә аның барлык яхшы сыйфатлары күчкән.

Әти бик юмарт, миһербанлы, ярдәмчел, гади. Килгән кешенең үтенечен беркайчан да кире какмый, соңгы әйберен биреп җибәрергә әзер.

Аллаһыга шөкер, әтиебезне авылда зурлыйлар, хөрмәт итәләр.

Без әтигә һәм әнигә, төпле һәм күркәм тәрбия биргәннәре, үз үрнәкләрендә үстергәннәре, кеше иткәннәре өчен, бик рәхмәтлебез. Исән-сау, озын гомерле була күрсеннәр", – дип уртаклаштылар Гайнетдиновларның балалары.

# “БАЛАЛАРНЫ ИМАНЛЫ, ИНСАФЛЫ ИТЕП ТӘРБИЯЛӘҮДӘ ИСЛАМ ДИНЕНЕҢ ӘҺӘМИЯТЕ ИСКИТКЕЧ ЗУР”

*«Ана – бөек исем,*
*Нәрсә җитә ана булуга!*
*Хатыннарның бөтен*
*матурлыгы,*
*Бөтен күрке – ана булуда!»*

***Миләүшә Газимова***

– Бөек шагыйребез Һади Такташ язган бу шигъри юллар белән тулысынча килешәм мин, – ди биш бала әнисе, II дәрәҗә «Ана даны» медале иясе – Похвистнево районының Гали авылында яшәүче Дания Йосыпхан кызы Юнысова.

Ундүрт яшьлек кызлары Нәзирәне, унөч яшен тутырган уллары Илнурны, алты яшьлек Айшәне һәм ике яшь тә тугыз айлык игезәкләр – Әхмәт белән Суфияне тәрбияләүче Расих һәм Дания Юнысовлар әти-әни булуның никадәр зур бәхет-сәгадәт икәнлеге турында сәгатьләп сөйли алырлар иде, мөгаен. Балаларын шулкадәр яратып, һәрберсенә тиешле игътибар биреп үстерүче ата-ананың шатлыгы йөзләренә чыккан.

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләм бер хәдисендә: «Балалар – тормыш чәчәкләре. Балалар – Җәннәт күбәләкләре», – дип әйткән. Сабыйлар – ата-ана өчен иң татлы җимеш, Аллаһы Тәгалә биргән иң зур бүләк, – ди Юнысовлар.

– Белсәгез икән, мин һәрвакыт, кияүгә чыгып, күп бала үстерергә һәм каенана-каената белән бергә яшәргә хыялландым бит, – дип, чиксез сөенечен яшерә алмыйча сөйли Дания. – Дөрес, өч нарасый турында гына уйлаган идем (елмая), әмма Раббыбыз безгә бишне бирде! Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылам, теләкләремне чынга ашырды.

Әйе, Юнысовлар, зур гаилә булып, бердәмлектә һәм татулыкта матур гомер кичерәләр. Ашлары да, эшләре дә уртак аларның. Мөхтәр әфәнде белән Миңнерумия ханым, балалары, оныклары белән бергә яшәгәнгә, шатланып туя алмыйлар.

– Берәр кайда китсәләр, өебез шундый тыныч булып кала ки, күңелсезлек, ямансулык баса. Раббым киләчәктә дә бергә гомер итәргә насыйп итсен, – ди Миңнерумия апа.

Килен белән дә аралары яхшы аларның. Дания үзләренә «әтием», «әнием», дип кенә тора. Ә каената белән каенана аңа «кызым», дип эндәшәләр.

– Күп хатын-кызлар: «Каенана белән ничек бергә яшәргә була ди инде?!» – дип, борын җыералар. Ә



*Расих һәм Дания Юнысовлар гаиләсе*

миңа, киресенчә, бу рәхәтлек китерә. Бием (Гали авылында ирнең әнисен шулай дип йөртәләр – авт. искәрмәсе) – йомшак күңелле, эчкерсез кеше. Әлхәмдүлилләһ, сүзгә сүз килгәнебез юк. Алар әти белән безгә гел булышалар. Нарасыйларыбызны карауда да зур ярдәм күрсәтәләр. Үзләренә рәхмәт яугыры, – дип уртаклаша яшь ана.

Кызганычка, Даниянең үз әтисе Йосыпхан 2016 елда вафат булган икән. Әнисе Рәшидә, Аллаһыга шөкер, исән-сау, Похвистневода яши.

– Әти-әниемә булган хөрмәтем, рәхмәтемне сүз белән генә әйтеп аңлатып бирерлек түгел. Алар мине шулкадәр сөеп, назлап, кайгыртучанлык, игелеклелек күрсәтеп үстерделәр! Бигрәк тә әнием, бәгырем, минем өчен өзелеп торды. Хәзер дә шулай, балаларыбызга карата да мәхәббәте чиксез аның, – дип сөйли газиз кешеләре турында Дания.

***– Хәләл җефетегез Расих сезгә нинди мөнәсәбәт күрсәтеп яши?*** – дип кызыксындым язмам героеннан.

– Интернеттан Гөлара Шәрипова иҗат иткән бер шигырь укыган идем. Ул миңа шундый ошады! Сезнең бу соравыгызга шушы шигъри юллар белән җавап бирәсем килә, Миләүшә.

*«Хатын-кызның бәхете – ирдән, диләр,*
*Дөрес сүзләр, күпләр килешә.*
*Бәхет бит ул, әгәр сөйгән ярың*
*Кайгы-шатлыгыңны бүлешсә.*
*Хөрмәт итсә сине чын күңелдән,*
*Авыр чакта булса ир – терәк,*
*Бер сүзсез дә сине аңлый белсә,*
*Бәхет өчен тагын ни кирәк?*
*Тугры булса сиңа, ихлас сөйсә,*
*Балаларга булса чын ата,*
*Андый ирдән, кызлар, хак әйтәмме,*
*Йөрәкләргә сары май ята...»*

Әлхәмдүлилләһ, бу сүзләр ирем турында язылган, диярсең. Мин аның белән бик бәхетле.

Аралашып йөргәндә үк ипле, тыйнак, эшчән икәнлеген абайлап алдым. Эчмәве, тартмавы күңелемә



*Расих әфәнде*



*Дания ханым*

аеруча хуш килде. Өйләнешеп, яши торгач, башка күркәм сыйфатларын да ачтым.

Расих – кайгыртучан, игътибарлы ир. Әти-әнисенә, миңа карата ихтирамлы. Балаларны тәрбияләүдә катнаша, ярдәм итә.

Ул мине күп нәрсәгә өйрәтте һәм хәзер дә өйрәтә.

Тора-бара ныклап дингә кереп китте Расих. Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлады. Аллаһыга шөкер, хаҗ кылу бәхетенә дә иреште.

Бүгенге көндә авылыбызның Урта мәчетендә имам хезмәтен башкара. Шулай ук кичләрен мәдрәсәдә – хатын-кызларга, көндезләрен мәктәптә балаларга дини гыйлем бирә.

Хәләл җефетем мине дә намазга бастырды. Әлбәттә, көчләп түгел, барысын да яхшылап аңлатып, вәгазьләп. Озын итәк киеп, яулык бәйләп йөри башладым. Нәкъ шул вакытта Рәшидә әнием хаҗдан миңа озын күлмәк алып кайткан иде.

Баштагы мәлне: «Кешеләр нәрсә дияр икән?» – дип, мөселманча киенеп йөрергә оялыбрак тордым. Әмма Расих миңа шунда хак сүзләр җиткерде: «Син башкалар ни әйтер, дип уйлама. Иң мөһиме – бер Аллаһы Тәгалә синнән канәгать булсын».

Гомумән, ирем ярдәмендә тышкы кыяфәтем генә түгел, эчке дөньям да, тормышка карашым да үзгәрде. Ул гел акыллы киңәшләрен бирә, мине туры юлдан алып бара. Һәм мин аңа барысы өчен дә рәхмәтлемен.

***– Балаларыгызга нинди үгет-нәсыйхәтләр бирәсез?***

– Нәзирәне хатын-кыз эшләренә өйрәтәм. «Кызыкаем, син – булачак хатын һәм әни. Шуңа күрә



*Расих, Дания һәм аларның игезәк балалары*

аш пешерү серләрен дә, баланы ничек карарга кирәклеген дә белергә тиешсең, – дип әйтәм.

Хәер, ул боларның барысына да өйрәнеп килә инде. Бергәләп ризык та әзерлибез, өйне дә ялт иттереп җыештырып куя. Рәхмәт яугыры, эне-сеңелләрен караша, миңа зур булышлык күрсәтә.

Хәзер бит яшьләр күбрәк телефонда утыра. Шунысы куандыра, безнекеләргә андый җен кагылмаган. Нәзирә җиденче класста укыганда гына, үзенә смартфон алып бирдек. Алай да, ул аңарда утырмый. Китаплар укырга бик ярата. Шигырь сөйләү конкурсларында актив катнаша.

Алтынчы сыйныфта белем алучы Илнурның әле дә телефоны юк. Апасына алган кебек, аңа да җиденче класска күчкәч кенә бүләк итәргә телибез.

Улыбызның спортка мөккибән китүенә бик шатбыз. Ул теннис, футбол уйный, кикбоксинг белән, өйдә турникларда шөгыльләнә.

Аны да тәртипкә өйрәтәм. «Улым, үз артыңнан җыештырырга өйрән. Мин бит берүзем, ә сез бишәү. Әнигә ярдәм итәргә кирәк. Киләчәктә хатыныңа да синең белән җиңел булыр», – дим.

Олыларны хөрмәт итегез, үзләренә сәлам бирегез, әдәпле, намуслы булыгыз, кешеләрне рәнҗетмәгез, үзегездән көчсезрәкләрне яклагыз, дип туглап торабыз улкызларыбызга.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи үә сәлләмнең:

«Пакьлек – иманның яртысы», дигән сүзен истә тотып, чисталык-пөхтәлеккә өйрәтәбез.

Эшкә дә күнектерәбез. Кызлар минем янымда бөтереләләр, Илнур күбрәк әтисенә, бабасына булыша.

Балалар белән һәрдаим шөгыльләнергә кирәк.

Менә алты яшьлек Айшәне укырга өйрәтәбез, математика нигезләрен төшендерәбез.

Кечкенәләре дә янибызда тыңлап утыралар. Аларның башларына да сеңеп бара. Безнең арттан кабатлап, игезәкләр унга кадәр санарга өйрәнделәр инде.

Балаларыбыз татарча да, русча да яхшы беләләр.

***– СөбханАллаһ, Дания, барысына да ничек өлгерәсез соң сез?***

– Юньләп ашау да, юньләп йокы күргәнем дә юк инде (көлә).

Балаларны карарга бик күп вакыт кирәк шул. Әле бит һәрберсенә ярарга да тырышасың. Берсе – аш, икенчесе – ботка, өченчесе коймак ярата... Һәрберсенә аерым әзерләргә.

Тик бу – күңелле мәшәкатьләр. «Әнием мин яраткан ризыкны пешергән!» – дип, битемнән үбеп, кочаклап алулары, шатланулары ни тора! Мин инде андый мизгелләрдә бөтенләй эреп китәм.

***– Балаларыгызга дини тәрбия бирәсезме?***

– Әйе, дин турында сөйләп торабыз. Әтиләре үзләренә вәгазьләр укый, яхшыны – яманнан, хәләлне хәрамнән аерырга өйрәтә, Исламның әһәмиятлелеген, Аллаһы Тәгаләнең барлыгын, берлеген, мәрхәмәтле, бөек булуын аңлата.

Әлхәмдүлилләһ, олылары намаз укыйлар, мәдрәсәгә йөриләр. Һәм без аларны моңа көчләмәдек.

Нәзирәбез гарәпчә укый белә инде. Дингә нык тартыла ул, биш вакыт намазын калдырмый. Үзе теләп, икенче сыйныфтан озын күлмәк киеп, яулык бәйләп йөри.

Әтисе Айшәне үзе белән мәчеткә алып йөри. Аңа гарәп графикасын өйрәтә.

Кызыбыз аягына кигәндә дә, ишек япканда да, ашарга утырганда да «бисмилләһ»не әйтмичә калмый. Әле, җан-фәрман тырышып, кулларын биленә куеп, игезәкләрне дә тәрбияли (көлә).

Ятар алдыннан балаларга кычкырып (вслух) догалар укыйм, нәшидләр көйлим.

Әнием мине балачакта шулай йоклата иде. Аның артыннан кабатлап, догалар ятладым.

Безнең нарасыйларыбыз да нәшид җырлаганда миңа кушылалар, Айшә кайбер догаларны белә инде.

Балаларны иманлы, инсафлы итеп тәрбияләүдә Исламның әһәмияте искиткеч зур. Кечкенәдән күңеленә дин таләпләрен сеңдереп үскән нарасый миһербанлы, шәфкатьле була ул.

Гомумән, Исламда безнең өчен барлык күрсәтмәләр дә бар бит – сабыйларны ничек дөрес итеп тәрбияләргә, аларга нинди мөнәсәбәт күрсәтергә, нинди таләпләр куярга һәм башкалар.

Дингә килгәч, бала тәрбияләү буенча күп нәрсәгә төшендем. Аларга бертигез игътибар, вакыт бүлеп бирергә, әхлак нормаларын аңлатып, сөйләп торырга кирәк.

***– Сез җитди, таләпчән яисә йомшак әниме?***

– Таләпчән булмыйча да ярамый. Әйткәнне тыңлаган балага бик җитди дә була алмыйсың. Күбрәк йомшаклык күрсәтәм.

Нәзирә белән без дус кызлардай, серләшәбез, киңәшәбез, бергәләшеп матур күлмәкләр сайлыйбыз.

***– Нарасыйларыгызның холыклары төрле-төрлеме яисә бер-берсенә охшаганнары да бармы?***

– Бишесенең холкы биш төрле.

Нәзирә йомшак, тыйнак, нечкә күңелле.

Илнур тыныч, бөтен нәрсәне йөрәгенә якын ала.

Айшә баскан җирдән ут чыгара, боерык бирергә ярата, үткен.

Игезәкләр дә икесе ике төрле. Әхмәт миһербанлы, кайгыртучан. Сеңелесе турында гел уйлый. Үзенә берәр тәмләшкә тоттырсам, шунда ук: «Ә Суфиягә кая?» – дип сорый. Менә аңа да бар, дип бирәм дә, янына барып, авызына каптырып та куя әле.

Ә Суфиябез исә хәйләкәр, шук, җитез.

***– Сез хатын-кызларны никахка әзерләү белән шөгыльләнәсез икән?***

– Әйе, кешенең үз эше, яраткан мавыгуы булырга тиеш, дип саныйм. Минем дә күңелем иҗатка тартылды, нәрсә белән булса да шөгыльләнергә теләдем.

Яулыктан йөргәч, интернеттан аны матур итеп бәйләргә өйрәтүче видеороликларны еш караштыргалый идем. Аннан бу юнәлештә үз мөмкинлекләремне сынап карарга булдым. Казанга барып, мөселманча яулык бәйләү ысулларын өйрәнеп кайттым.

Башта Нәзирәгә, аның сыйныфташ кызларына бәйләп карап, шулай әкренләп осталыгымны чарладым.

Тора-бара хатын-кызлар никах туйлары, мәҗлесләр алдыннан миңа яулык бәйләтергә килә башладылар, шулай клиентларым барлыкка килде.

Кайберләре, ә сездә мөселман күлмәкләре юкмы, дип сорыйлар иде. Шуннан мин уйладым да күлмәкләр дә кайтара башладым. Әмма әзерләренең бертөрлерәк булуы ошап бетмәде миңа. Шуңа күрә хәзер, кәләшләрнең ихтыяҗларын, теләкләрен күздә тотып, үлчәмнәрен алып, Казанның бер-ике ательесына күлмәкләр тектерергә заказлар бирәм.

Интернет челтәре аша Санкт-Петербург шәһәреннән чиккән





*Дания газиз әнисе Рәшидә белән*

бизәкләр дә сатып алам. Алар инде тулысынча әзер, күлмәккә тегеп куярга гына кала.

Иремә рәхмәт. Ул, хатын-кызлар үзләрен уңай-хис итсеннәр, кыенсынмыйча киенеп карасыннар дип, миңа эш өчен аерым бүлмә җиһазлады.

Галидән генә түгел, тирә-як авыллардан да, Богырысланнан, Камышлы ягыннан, хәтта Самардан мөрәҗәгать итүчеләр дә бар.

Эшем миңа бик тә ошый.

Кәләшләр күлмәк киеп карарга килгәч, кечкенәләребез:

«Апа нинди мату-у-ур!» – дип хезмәтемә бәя дә бирәләр әле (көлә).

***– Күп балалы ана буларак, хатын-кызларга нинди теләккиңәшләр бирер идегез?***

– «Бу дөньяга һәр сабый үз ризыгы белән туа», – дип юкка гына әйтмиләр. Бу чын мәгънәсендә шулай. Бала табарга курыкмасыннар иде. Сабыең – ул синең дәвамың, синең каның, бәгырь кисәгең бит.

Һәм иң мөһиме – балага дөрес тәрбия бирү мөһим.

Син аны үз үрнәгеңдә үстерергә тиеш. Шуңа күрә, иң беренче чиратта, үзеңне тәрбияләргә кирәк. Ата-ана күркәм холыклы икән, насыйлары да, иншаАллаһ, шундый булыр.

***– Зур, тату гаиләгезнең бәхете кимемәсен, Дания.***

# ИХТЫЯР КӨЧЕ ҺӘМ ТЫРЫШЛЫК – УҢЫШ НИГЕЗЕ



***Кыюлык, тәвәккәллек, максатына ирешү өчен, бөтен көчен куярга әзер булу – бу сыйфатлар моннан берникадәр вакыт элек күбрәк ир-атларга хас сыйфатлар булып санала иде. Заманалар үзгәргән саен кешеләр дә, яшәү темпы да, карашлар да үзгәрә бара. Бүгенге көн хатын-кызлары ир-атлар өчен генә дип саналган эшләрне дә бер авырсынмыйча башкарып чыгалар, кыюлык, максатчанлык буенча да алардан бер дә калышмыйлар.***

*Эльмира Сәйфуллина*

Күптән түгел генә мин илебезнең иң престижлы югары уку йортында белем алучы Самар кызы белән таныштым. Бераз аралашканнан соң, Айтурган Осмонованың ихтыяр көченә, тырышлыгына шаккатым. Бик яшь булуына карамастан, бу акыллы, зирәк, тыйнак кыз урыны белән үзеннән күпкә олы ханымнарга да үрнәк булырлык.



Айтурган - Самарда туып-үскән кыргыз кызы. Балачагыннан туган телен, мәдәниятен, горефгадәтләрен өйрәнеп, яратып үскән бала. Культурабыз һәм телләребез бик охшаш булганга, Осмоновлар гаиләсе ике кызларын да «Яктылык» татар мәктәбенә укырга бирәләр. Башлангыч сыйныфларны ул Гөлфия Рәшит кызы Глушкова җитәкчелегендә укый, ә мәктәпне 2021 елда Ринат Сәгъдиев сыйныфында иң яхшы укучылар рәтендә тәмамлый.

– Гел «бишле» билгеләренә тәмамлагач, димәк, татар телен дә «бишле»гә беләсең? – дип кызыксынам кыздан.



– Кыргыз телендә иркен сөйләшәм, аңлыйм. Рус мохитында яшәп тә, туган телемне онытырга бирмәгән өчен, әти-әниемә бик зур рәхмәт. Татар теле белән кыргыз теле бик якын, охшаш, икенчедән, балачакта телләр өйрәнүе бик җиңел. Шуңа күрә башлангыч сыйныфта ук татар телен әйбәт кенә үзләштерә башладым. Төрле шигырь бәйгеләрендә актив катнаша идем. Бераз акцент белән булса да, татарча яхшы сөйләшәм. «Йолдыз» бию ансамблендә шөгыльләндем, мәктәп театры куйган постановкаларда катнаша идем, мәктәпнең этнографик музеенда татарча экскурсияләр уздыра идем. Ике ел рәттән Казанда узган татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиадада катнаштым. Асия ханым Госманова безне чигү чигәргә, татар халык аш-сулары пешерергә өйрәтте. Гомумән, татар халык мәдәнияте миңа бик ошый, мин аны яратам. Кыргызларның да, татарларның да мөселман булуы да аларның охшашлыгын көчәйтә. Татар телен өйрәнү минем өчен бер вакытта да проблема булмады, мин аны бик җиңел үзләштердем, хәер, башка фәннәрне дә шулай ук, – ди Айтурган.

**– Ә Мәскәү дәүләт университетына керү теләге кайчанрак барлыкка килде?**

– Иң-иң дип саналган уку йор-





тында белем алу теләге минем күңелемдә күптән яши иде. Әмма бу уку йорты Мәскәү дәүләт университеты булыр дигән кыю уй һәм максат әле юк иде. Шулай, ничектер тарих дәресендә без Әби патша (Екатерина II) чорын өйрәнгәндә, мин иң беренче югары уку йорты турында белдем, һәм анда иң беренчеләрдән булып юридик факультет оешкан булган. Әлеге уку йорты бүген Михаил Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университеты дип атала. Иң беренче юристларны нәкъ менә анда әзерләгәннәр, димәк, бүгенге көндә бу юнәлештә анда иң сыйфатлы белем бирәләр, дип уйладым мин шул вакытта. Берникадәр вакыттан мин үземне шушы университет студенты итеп күрә идем. Билгеле инде, моның өчен бик күп тырышлык һәм көч куярга кирәклеген дә яхшы аңлый идем. Чыгарылыш имтиханнарына ныклап әзерләндем һәм уңышлы тапшырдым.

Гаризаны берьюлы берничә югары уку йортына юнәлттем. Алар арасында Самар дәүләт университеты, Казан Федераль университеты, Мәскәүнең һәм Петербургның юридик университетлары һәм, әлбәттә инде, Мәскәү дәүләт университеты иде. Санап үткән уку йортларына мин бик җиңел үттем. Ә менә хыялымның чынга ашуы икеле-микеле иде. Чөнки минем баллар минималь күрсәткечләргә якын иделәр. Шул вакытта әти-әнием, борчылуларымны күреп, миңа ярдәм итәргә булдылар һәм соңгы нәтиҗәләрне көтеп тормыйча, түләүле бүлеккә керергә тәкъдим иттеләр. Моның өчен мин аларга чиксез рәхмәтлемен, хыялымны чынга ашыру һәм әтиәниемнең ышанычын аклар өчен, бөтен көчемне куячакмын, – ди әңгәмәдәшем.

Хәзер Айтурган икенче курста укый. Быел студентлар профиль юнәлеше буенча бүленгәннәр. Безнең Айтурган җинаять-хокук профилен сайлаган. Бу юриспруденциядә иң кызыклы юнәлеш, дип саный кыз. «Юристларның эше көн-төн кәгазьләр, төрле документлар арасында уза, ә мин сайлаган профиль криминологияне өйрәнә һәм һөнәрне күпкырлы мавыктыргыч итә», – дип елмая студентка.

**– Хыял булгач, үзең өчен ниндидер образлар ясыйсың, укуыңны ничегрәк күзаллыйсың. Синең күзаллаулар чынбарлыкка туры килдеме?**

– Тәгаем алганда, әйе. Мөгаллимнәр, белем бирү, уку йорты – барысы да югары дәрәҗәдә. Әмма үземнең укуга карашымны, тырышлык, үҗәтлек кебек төшенчәләрне башкача бәяләргә туры килде. Монда мәктәп программасы гына түгел, Мәскәү дәүләт университетында белем алыр өчен, минем нигездәге тырышлыгымны берничә тапкыр арттырырга туры килде. Үз-үземне тотышым, сөйләм культурасы өстендә эшләдем һәм дәвам итәм. Бу уку йортында бөтен Россиядән иң сәләтле укучылар җыелган, шуңа күрә алар белән бер дәрәҗәдә булырга кирәк, җитешсезлекләреңне барлап, алардан арынырга, белемеңне, тәрбияңне, культураңны үстерү өстендә көн-төн тырышып эшләргә кирәк, – ди Айтурган.

Шулай да, ял итәргә дә онытмаска. Айтурган актив ялны хуплый. Ул буш вакытын музейларда, картина галереяларында һәм тарихи урыннарда уздырырга ярата.

**– Киләчәккә планнарың бармы инде? Диплом алгач, Самарга кайтасыңмы әллә монда ошыймы?**



# ТАТАРЛАРНЫҢ ТАБЫН ӘДӘБЕ (табын йолалары)

*Тормыш итү әдәбе (этикеты) халыкның тарихында, мәдәниятендә, гореф-гадәтләрендә һәм башка үзенчәлекләрендә ачык күренә. Әлбәттә, әдәп кагыйдәләре формалашуга дини, рухи һәм мәдәни йолалар да көчле йогынты ясаган.*

*Фәрид Шириязданов*

Әдәп (этикет) – ул җәмгыятьтә үз-үзеңне ничек тоту кирәклеге турындагы кагыйдәләр җыелмасы. “Этикет” сүзе француз теленнән алынган. Ул Европада Людовик 14 чорында кулланыла башлый һәм кунакларга үз-үзләрен ничек тоту кирәклеге турында язылган карточкалар (этикеткалар) таратудан башлана.

Әдәп кагыйдәләре, борынгыдан татарларның әхлак нормаларына салынып, тормышның тирән катламнарына үтеп кергән. Һәр халыкның әдәп кагыйдәләрендә аның милли төсмерләре чагыла. Татарларның асылы шуларда ачык күренә дә инде.

Үзара әдәпле аралашу һәркемгә үзен кешеләр арасында уңай хис итәргә ярдәм итә. Шуңа да тора-бара әдәп кагыйдәләре гигиена, үзара аралашу, сәясәт, мәдәният, эшлекле мөнәсәбәтләр өлкәсенә, шулай ук тормышның башка тармакларына да үтеп керә. Татарларның йолаларында, бәйрәмнәрендә дә ул зур урын алып тора.

Табын йоласында халкыбызның асылы аеруча ачык күренә.

Татар халкының туклану культурасы, кунакчыллыгы һәм табын әдәбе аның гореф-гадәтләре арасында иң зур урын алып тора. Монда хатын-кызларыбызның булдыклылыгы, фантазия байлыгы аш-су әзерләү осталыгында һәм матур табын кора белүендә аеруча ачык күренә.

Татар халкы тәмле итеп туклана һәм матур итеп кунак та сыйлый белә. Безнең халыкның милли ризыклары гүзәл сәнгать әсәрләре кебек. Шуларны татыганнан соң, кеше хозурлана, һәм ул үзен милли асылына кайткандай хис итә.

Унөченче гасырда Ибн Рәзин әл-Туҗиби үзенең: «Иң әйбәт ашамлыклар һәм иң әйбәт табын» исемле китабында:

«Аш-суны әзерләүгә һәвәслек кешене саранлыктан коткара һәм аңарда юмартлык тәрбияли. Аш-су әзерләү сәнгате белән бергә дөньясы байлыгына бәйләнгән. Ул ризыкны илһамланып һәм күтәренке кәеф белән пешерә икән, моның тәэсире турыдан-туры ашаучыларга да күчә.

Ризык күзне назлый, күңелне иркәли, аппетитны ача, ахырда рәхәтлек, канәгатьлек тудыра, ул – Аллаһының бер серле нигъмәте. Милли ризык гади ашамлык кына түгел, ул халыкның гореф-гадәтләре байлыгын, милли һәм матди культурасын да ачыклап күрсәтә.



Аллаһы Тәгалә аңа бу юлда төрле ачышлар ясау мөмкинлеге, хәтта үз-үзен уздырырлык сәләт байлыгы һәм киң мөмкинлекләр дә биргән!» – дип яза.

Юмартлык табында мул ризыклар булдыру һәм өстәлне бизәү осталыгы белән бәяләнә. Ул шулай ук кунакларга ихтирамлы һәм игътибарлы булу белән раслана һәм кунакчыллык культурасын тәшкил итә.

Ризык әзерләүнең уңышлылыгы турыдан-туры хуҗабикәнең эчке

Ислам дине буенча, кешегә ике төрле әхлакый вазыйфа йөкләнгән:

тән тәрбиясе,

җан тәрбиясе.

Тәнебез көчле һәм сау-сәламәт булсын өчен, ашау-эчүгә нык игътибарлы, сабыр булу, тыела белү кирәк. Монда хәләл ризыклар белән генә туклану да зур роль уйный.

Бу уңайдан: «Кешениләр белән туклана – аның тәне шул матдәләр-

дән тора!» – дигән әйтемне истән чыгарырга ярамый.

Кешедәге әдәплелек һәм башка күркәм сыйфатларны тәрбияләү һәм затсызлыктан саклану ашау-эчү, табындагы сөйләшүләр, мәҗлесләрдәге аралашулар белән дә тыгыз бәйләнгән.

Ашау-эчү тәртибе тормышта әхлакны ныгыту, күңелне баету



чарасы да булып тора. Мәсәлән, ризыкны күршең, кунагың яисә мохтаҗлыкта яшәүче кеше белән бүлешү үзара мөнәсәбәтләрне ныгыта һәм саваплы эш булып санала.

Ризыклану тәртибе халыкның милли сыйфатлары, аның туклану культурасы белән тыгыз бәйләнгән. Ул, милли мәдәниятнең асыл бер өлеше буларак, халык авыз иҗатында да зур урын алып тора. Мәсәлән, «Чәй яны – гаилә җаны», «Хуҗа чәйне кунакларга үзе агыза», «Эчсәң чәй – күңелдә җәй» һәм башкалар.

Халыкның кунакчыллыгы аның йолаларында, бәйрәмнәрендә ачык күренә. Ә йолалар халыкның борын-борыннан килгән ышануларына барып тоташа. Аларның күбесе мәҗүсилек чорыннан ук килгән һәм рухларга табына белү белән бәйләнгән. Рухларны төрле бүләкләр, тәмле ризыклар белән канәгатьләндереп, борынгы бабаларыбыз тук һәм тыныч тормышта яшәү турында хыялланганнар.

Алар ризыкта тылсым көче бар, дип санаганнар. Төрле бәйрәмнәрдә йола табыннары уздырганнар һәм аларны бәйрәм туйлары, дип атаганнар. Мәсәлән, Сабан туе, Бәби туе, Карга туе һәм башкалар.

Җир кардан ачыла башлау белән, алар карга боткасы пешергәннәр һәм Карга туе ясаганнар, чөнки каргалар канат очларында язны алып килә, дип ышанганнар. Ботканың бер өлешен, иминлек, тынычлык, мул уңыш теләп, җиргә салганнар.

Икенче өлешен, елгалар, чишмәләр тулы сулы булсын, яңгырлар яусын өчен, суга салганнар.

Өченче өлешен күккә атаганнар һәм каргаларга биргәннәр. Шуннан соң калганыннан һәркем үз өлешен алып ашаган.

Борынгы бабаларыбызның фантазиягә, хыялларга бай булганлыгы аларның әкиятләрендә, риваятьләрендә, халык авыз иҗатында зур урын алган. Йолалар, ышанулар да шуңа нигезләнгән.

Мәсәлән, беренче буразнага йомырка салу гадәте йомырканы кояш белән чагыштыруга бәйләнгән. Бу йоланы кояш энергиясе байлык һәм мул уңыш китерүенә юраганнар. Яңа җан иясе яралыр өчен, анда бар нәрсә дә тупланган булганга, йомырканы тормыш чыганагы итеп тә кабул иткәннәр.

Хыялларга бай халык булу белән беррәттән, борынгы бабаларыбыз әле табигатьтәге тирән серләрне дә белгәннәр. Мәсәлән, игеннәрнең орлыкларын шыттырган вакытта андагы углеводларның, аксым рәвешенә күчеп, организмга көч-дәрт һәм, чирләрне җиңү өчен, киң мөмкинлек бирә торган матдәләр, антидепрессантлар барлыкка килүен белгәннәр.

Бу күренешне язгы авитаминоздан, ачлыктан тән хәлсезләнгән, чирләр баскан һәм башка авырлыклар килгән вакытта уңышлы кулланганнар. Мәсәлән, талкан ясаганнар, сумалак пешергәннәр.

Җирне, су чыганакларын, күкне изгеләштергән кебек, алар, ризыкка да аеруча зур хөрмәт күрсәтеп, аны серле яшәү чыганагы, дип санаганнар. Бәйрәмнәрдә, йола табыннарында, ризыкны изгеләштереп, аңа зур хөрмәт күрсәтелгән.

Ризыкка хөрмәт белән карау турындагы халык мәкальләре:

«Ризыктан өстен булмыйлар», «Аш, дигәндә атыңнан төш», «Аш турында ямьсез сөйләргә ярамый», «Табындагы ашка төкермә», «Табында өлешеңне калдырма», «Урамда ашарга ярамый», «Төнлә ашарга ярамый, чөнки ашказаны ял итәргә тиеш», «Акыл хезмәтендәгеләр аз ашарга тиеш. Тулы корсак уйларга комачаулый», «Кулларны ашаганчы һәм ашаганнан соң да юарга кирәк».

Ашауга бәйле дини һәм милли йолалар.

Җир йөзендәге барлык җан ияләренә ризык бирүче – Аллаһы Тәгалә, шуңа да ашауны Аллаһыны искә алып башларга һәм ахырда Аңа рәхмәт белдерергә кирәк.

Хәләл ризыкларны гына ашарга.

Өстәл янына, иң беренче булып, мулла утыра.



Бәйрәм табынына, иң элек, өлкәннәр, хөрмәтле кунаклар, аннан соң башкалар утыра.

Ризыкларны уң кул белән ашарга кирәк.

Кулыңа алган ипи кисәген ашап бетерергә кирәк.

Бәйрәм табынында итне олы кеше яисә хуҗа кеше кисә.

Кунак табынына өйдә булган иң тәмле һәм затлы ризыкларны чыгаралар.

Хуҗа ир-ат – кунакларны, хуҗабикә хатын-кызларны кыстый.

Озаткан вакытта, өйдәгеләрне сыйлар өчен, кунакка үзе белән кучтәнәч биреп җибәрелә.

Табынны бизәргә кирәк, ул күңелгә ләззәт бирә.

Кунак алдына кабымлык тәлинкәсе куела. Аның өстенә өчпочмаклап төрелгән тастымал салына.

Майлы кулларны сөртергә салфеткалар куела.

Кунаклар килгәнче, өстәлне җәймә белән каплап торалар.

Ризыклар, иң элек, яше, социаль статусы башкалардан өстен яисә зур хөрмәткә ия булган кешеләргә китерелә.

Кунак итү әдәбе кагыйдәләре.

Кунакларны елмаеп, хөрмәт белән кабул итәргә. Караңгы чырайлы булып, алар алдында балаларны яисә хезмәтчене хурларга ярамый.

Хуҗа кунакларны баскан килеш кабул итә. Ул кунагыннан алда өстәл янына утыра алмый.

Хуҗаның вазыйфасы – ашауэчү вакытында кунакларга хезмәт



күрсәтү һәм, матур сөйләшеп, күңелләрен күрә белү.

Хуҗага бер мәҗлескә бер-берсен яратмый торган кешеләрне чакырырга ярамый.

Хуҗа бервакытта да кунаклардан алда ризыкка үрелми.

Кунак ашаса, хуҗа да аның белән бергә утырырга тиеш. Ул ашап бетерсә, хуҗа да ашавын төгәлләргә тиеш.

Хуҗа үзе тукланган булса да, башкалар аңа иярмәсен өчен, ашавыннан туктарга тиеш түгел.

Кунак әдәбе.

Кунакка үзенең килүе турында алдан хәбәр бирергә кирәк.

Хуҗаларга хөрмәт йөзеннән матур итеп киенеп, кучтәнәчләр алып килү.

Килгәч, ишек ачык булса да, ничектер тавыш биреп, кунак үзенең килүен белдерә.

Ризыктан баш тартырга ярамый, чөнки бу хуҗаларның кунакчыллыгын хөрмәт итмәүгә керә.

Тәкъдим ителгән ризыкны ашап



бетерү – хуҗаларга хөрмәт күрсәтү билгесе.

Өстәл янында көзгегә каранып, үз-үзеңне тәртипкә китереп утырырга ярамый.

Өстәл янында хөрмәтле кешеләр утыра икән, алардан алда ризыкка үрелергә ярамый.

Ашауның чамасын белергә кирәк һәм ризыкны талымларга ярамый.

Өстәл янында башкаларны җирәндерерлек гамәлләр кылырга ярамый.

Ризыкны иснәү гадәтсезлек санала.

Башкаларның тәлинкәләренә карарга ярамый.

Өстеңә тамызмыйча, пөхтә итеп ашарга кирәк.

Зур тәлинкәдәге ризыкны, уртага үрелмичә, үз алдыңнан ал.

Тәлинкә өстендә мышнама һәм авыр сулама.

Ризык кайнар икән – суынганын көт, чөнки ризыкка өрү – әдәпсезлек.

Ризыкны авызга сыярлык һәм иркенләп чәйнәрлек кабарга кирәк.

Бер кисәкне ашап бетермичә, икенчесенә үрелмә.

Бер үк вакытта ашарга һәм сөйләшергә ярамый.

Бөтен бер җимешне тешләп алу – әдәпсезлек, кирәк кадәр кисәкне пычак белән кисеп алырга кирәк.

Башкалар туйгач, ашауны дәвам итмәскә, бирәнлек – кеше өчен оят күренеш.

Киткән вакытта кунак кеше хуҗаларны да үзенә чакырырга тиеш.

Табын янында әңгәмә кору әдәбе.

Сүз башлаганда табын артында утыручыларның дәрәҗәсен истә тотарга кирәк.

Кешегә кушаматы белән дәшәргә ярамый.

Сөйләшкәндә үз-үзеңне тота белергә кирәк. Кыйланырга, үзеңне башкалардан акыллы итеп күрсәтергә, башкалар сөйләменнән хата эзләргә ярамый.

Өстәл янында кешене бүлдермичә, тавыш күтәрмичә, мыскыллап көлмичә, үпкәләтә торган сүзләр әйтмичә сөйләшергә кирәк.

Ашаган вакытта бер-береңә уңай, матур, дустанә мөнәсәбәттә булып, күңелле хәлләр турында гына сөйләшәләр.

Начар сүзләргә иярәнмәскә, алдамаска, ялганлап, ант итмәскә, гайбәт сөйләмәскә, эшли алмаганны вәгъдә итмәскә кирәк.

Сөйләм мәгънәле һәм позитив, тормыш өчен файдалы булырга тиеш.

Кирәкмәгән сүзләр һәм артык күп сөйләргә ярамый.

Кемнедер артык күп мактау икейөзлелеккә әйләнергә мөмкин.

Үзегезгә ышанып сөйләгән серләрне башкаларга җиткерергә ярамый.

Табынга кагылышлы этикетны саклау кеше турында күпне сөйли. Аларны белү һәм дөрес куллану шәхескә карата хөрмәт уята. Ул кешеләргә, бер-берсенә тиз ияләшеп, уртак тел табып, аңлашып аралашырга ярдәм итә.

# ДАМИР ЙОСЫПОВ: «ХЫЯЛЫМА ТУГРЫ БУЛДЫМ»




*«Кукуруз рәтләре буйлап, кояшка таба» картинасы прокатка 2023 елның 16 мартында чыгачак.*

***Очучы Дамир Йосыпов 2019 елның 15 августында двигательләре эшләми башлаган самолетны кукуруз кырына утыртып, 233 кешенең гомерен саклап калган иде. Шул ук ел азагында якташыбызның батырлыгы турында фильм төшереләчәк, дигән хәбәр таралды. Ниһаять, кинофильм прокатка чыга.***

***Элина СӘЙФИ***

*(tvsamara.ru, ural.kp.ru, ren.tv сайтлары язмаларына таянып әзерләнде)*

Март башында Россиянең берничә шәһәрендә «Кукуруз рәтләре буйлап, кояшка таба» фильмын тәкъдим итү кичәләре булып узды. 11 мартта легендар милләттәшебез Дамир Йосыпов Самар тамашачылары белән очрашты һәм тиздән киң экраннарга чыгачак картина турында сөйләде.

Фильм алдарак атап узган вакыйгаларга нигезләнгән. «Мәскәү – Симферополь» рейсын башкаручы Airbus A321 лайнеры Жуковский аэропортыннан күккә күтәрелеп, биеклек җыя башлауга, башта бер двигатель, аннан икенчесе дә туктый. Димәк, самолет төшеп шартларга мөмкин... Очучылар – Дамир Йосыпов һәм Георгий Мурзин пассажир лайнерын аста күренгән кукуруз кырына утыртырга карар кылалар. Шул рәвешле бу ике кыю егет 233 кешенең гомерен саклап калалар. Президент Указы белән экипаж командиры Дамир Йосыповка һәм икенче пилот Георгий Мурзинга «Россия Герое» исемнәре бирелә.







Фильм «Централ Партнершип» кинокомпаниясе заказы буенча төшерелә, режиссеры – Сарик Андреасян, ә төп герой ролен Егор Бероев башкара. Сүз уңаеннан, фильмны төшерүчеләргә төп рольгә нәкъ менә шушы актерны алырга Йосыпов үзе тәкъдим иткән. Чөнки аңа Егор Бероевка бик охшагансың, дип әйткән булганнар.







– Асылда, фильм очучыларның кыюлыгы турында гына түгел, ә тырышлык һәм үҗәтлек нәтиҗәсендә чынга ашкан хыял турында да, – дип аңлата Дамир. – Бу, беренче чиратта, үзенең иң зур хыялын тормышка ашыра алган һәм нәтиҗәдә язмыш әзерләгән





сынауны лаеклы үтәгән кеше тарихы, – ди Герой.

Ул балачагында ук очучы булырга хыялланган һәм әтисе эзләреннән барачагына ышанган. Ләкин Дамир очу училищесына керә алмый һәм юристлыкка укып чыга. Әмма зәңгәр күккә омтылу теләге егеткә тынгы бирми. 33 яшендә Йосыпов, хыялын чынга ашыру өчен, икенче талпыныш ясый һәм укырга керә. Шулай, Дамир үз максатына ирешә һәм граждан авиациясе пилоты булып эшли башлый.

– Бик гыйбрәтле фильм. Ул үз хыялыңа омтылырга, аны тормышка ашыру өчен, кыенлыклардан курыкмыйча, алга атларга кирәклеген күрсәтә. Фильм тормыш кыйммәтләрен яңадан бәяләү, бүгенге көннең, һәр мизгелнең кадерен белү турында, – дип сөйләде Дамир Йосыпов премьерага җыелган Самар халкына.

Дамир Йосыпов картинаны төшерү буенча консультант та булган. Ул самолет кабинасында уйналган барлык күренешләрнең техник яктан дөрес булуын күзәтеп, Егор Бероевка нинди төймәләргә басарга, очыш вакытында кайсы вакытта нинди сүзләр сөйләргә кирәклеген әйтеп торган.

– Минем биографиямә кагылышлы кадрларны режиссерга үзенчә төшерергә мөмкинлек бирдем, әмма самолет очышы һәм очучыларның үз-үзләрен тотышы чынбарлыктагыча булуын таләп иттем, – ди Дамир Йосыпов.

9 мартта Герой милләттәшебез турындагы фильмның премьерасы Мәскәүнең «Октябрь» кинотеатрында узган иде. Тамашачылар залында кукуруз кырына утырырга мәҗбүр булган самолетта очкан пассажирлар да булган. «Алар бертавыштан очучыларның һәм бортпроводникларның кыюлыгы, тәвәккәллеге турында сөйлиләр. Авиалайнер командирының төгәл эше һәм кыюлыгы аркасында гына без исән кала алдык. Эвакуация дә бик тиз оештырылды, бер-ике ми-



нут эчендә без инде җирдә идек, – дип сөйләгәннәр пассажирлар Рен-ТВ журналистына.

Пассажирлар һәм Дамир Йосыпов әле дә аралашалар һәм ел саен 15нче август көнне әлеге кукуруз кырында очрашалар икән. Әлбәттә, бу вакыйгадан соң күпчелек пассажирлар самолетта очудан баш тартканнар. Әмма шул ук көнне кабат самолетка утырып очучылар да булган.

Нәкъ менә эвакуация вакытында яңгыраган сүзләр фильмның исеме итеп алынган. Трап буйлап ике метрлы кукуруз арасына төшеп баскан пассажирларның аптырап торганнын күреп алган бортпроводник Дмитрий Ивлицкий рупор аша: «Кояшка таба, кукуруз рәтләре буйлап барыгыз», – дип кычкырган. Шулай, пассажирлар кыр читенә чыгып җитәләр. Әлеге хәлне кемдер видеога төшереп ала, һәм ул, интернет челтәре аша таралып, популярлашып китә. Шуңа күрә режиссер да, сценарист Алексей Гравицкий да Дамир Йосыповның: «Киноны халыкка таныш сүзләр белән атарга кирәк», – дигән тәкъдимен кабул итәләр.



# ПУТЕШЕСТВИЕ ОДНОГО ЭТНИЧЕСКОГО НАЗВАНИЯ

*В нашем журнале рассказывалось о событиях, происходивших в давние времена в Центральной Азии, в частности, о жужанях и их государственном образовании. В данной статье мы поговорим о соседях жужаней – племенах теле и о распространении указанного этнонима на обширной территории.*

*Михаил Кржижевский*

Если прародиной различных финно-угорских народов является Урал, то колыбель ряда древних тюркских племен – Центральная Азия и Южная Сибирь, в том числе Алтай. Здесь очень разнообразная природа: есть и привольные степи, и причудливые скалы, и горы, поросшие густым хвойным лесом, и обширные озера. Впоследствии народы тюркского происхождения расселились в разных местах. Кто-то выбрал Урал с его покрытыми лесом горными грядами и многочисленными озерами. Другие освоили южные степи, где зимой гуляет вьюга, а летом волнами колышутся на ветру высокие травы. Часть древнеболгарских племен оказалась на Волге – их стали называть волжскими булгарами. Жили они, как известно, и на Самарской Луке, где стоят древние Жигулевские горы, где растут, как на Урале и на Алтае, сосны – выносливые, неприхотливые деревья, вершины которых устремляются к небу, а могучие корни порою можно увидеть и на поверхности земли. О многом могли бы рассказать эти деревья, живущие несколько столетий...

Память о Южной Сибири сохранилась в фольклоре народов Урало-Поволжья. В башкирских преданиях, легендах, сказаниях говорится о том, что их предки пришли с Алтая. К башкирам мы еще вернемся, а сейчас остановимся на древних племенах, известных под общим названием теле. Об этих племенах писали разные знаменитые исследователи, в том числе Л.Н. Гумилев, собравший обширный источниковый и историографический материал о теле. Издавна они жили в восточной части Центральной Азии и к северу от Гоби. Этноним теле восходит, как пишут специалисты, к дили или динлинам – древним племенам, упоминаемым китайскими источниками как произошедшие от хуннов. Родственные другим племенам, называемым сейчас древними тюрками (есть, правда, версия об их монгольском происхождении, но тюркская концепция преобладает), теле долго придерживались традиционного уклада. Каждый род управлялся старейшиной, а родственники, по сведениям историков, жили в мире и согласии друг с другом. Теле кочевали по степи на телегах с высокими колесами и активно занимались скотоводством. Они оказались в составе державы Хунну, основанной в III веке до на-



*Телеуты*



шей эры полководцем Модэ, но довольно рано вышли из ее состава, сохранив при этом свой кочевой быт. В хрониках китайских династий IV–VI веков нашей эры теле упоминаются как гао-гю. Их соседями были жужани, которым теле то вынуждены были подчиняться, то пытались бороться с их господством. Особенно обострились отношения между ними во второй половине V века. В это время старейшина теле Афучжило, не желая подчиняться жужаням, увел всех своих людей (которых было, согласно китайским данным, целых сто тысяч кибиток!) через Алтай на запад, в долину Иртыша. Там указанный вождь принял титул «Великий сын Неба» и основал новое государственное образование, которое, правда, в скором времени было разгромлено эфталитами.

Впоследствии племена теле сыграли важную роль в истории Тюркского каганата. В VI–VIII веках различные их группы расселились далеко на запад, вплоть до Каспийского моря, смешиваясь с другими народами, порой поглощаясь ими, но сохраняя название.

Данный этноним сохранился в Сибири – его носят живущие здесь малочисленные народы: телесы, телеуты, теленгиты, которые до недавнего времени считались подразделениями алтайцев или алтайских тюрок, а сейчас обычно упоминаются как самостоятельные этносы.

Указанный этноним присутствует в форме теляу в родоплеменной структуре башкир, казахов, каракалпаков (в форме тилеукусши), узбеков. Данное подразделение у башкир входило в состав крупнейшего племенного объединения табын, представители которого в основном расселились на Урале и за Уралом, но когда-то имели свои кочевья и на территории нынешней Самарской области, в районе реки Большой Иргиз. Известный исследователь башкир С.И. Руденко на основе документов первой половины XVIII века составил список башкирских волостей, где упоминается и Телевская волость Ногайской дороги, расположенная по реке Яик и речке Мендяк.



*Башкирка в старинной одежде*

Исследователи отмечают самобытность традиционной женской одежды башкир подразделения теляу, особенности их говора.

В этнокультурном плане башкирские и казахские теляу наиболее близки сибирским телеутам, что вытекает, как пишет известный башкирский этнограф Р.Г. Кузеев, как от близости этнонимов (теляу – телеут), так и от ряда исторических обстоятельств. Телеуты явились потомками древних теле, расселившихся на обширной территории, с которыми предки башкир имели этнокультурные связи, вероятно, еще во времена Тюркского каганата. Впоследствии предки телеутов жили

самостоятельно, а потом подчинились монголам. В источниках упоминается телеутская «землица», которая располагалась между набирающим силу Русским государством и слабеющей Джунгарией. Затем телеуты входят в состав России.

Телеуты сегодня живут по большей части на юге Кемеровской области, а также в соседних регионах Южной Сибири. Издавна этот народ занимался скотоводством – разводил лошадей, крупный рогатый скот, свиней. Определенную роль в традиционном хозяйстве играли охота, рыболовство, сбор грибов и ягод. После вхождения в состав России, в результате контактов с осваивающими Сибирь русскими, телеуты стали применять пашенное земледелие и пчеловодство. Получили распространение разные ремесла, в том числе плетение из кожи плеток, арканов и конской сбруи, что сближает их, например, с теми же башкирами.



***Башкирская традиционная одежда***

Старинное жилище телеутов называлось «аланчык» и представляло собой коническую постройку, где в качестве каркаса использовались жерди, покрытые берестой и корой и обмазанные глиной, а сверху натягивались шкуры. Жилище делилось на две половины: справа располагалась женская часть, где хранились предметы рукоделия, хозяйственные принадлежности, а также вешалась детская колыбель, сделанная, по традиции, из черемухи, срубленной в новолуние. Слева была мужская часть, где помещались орудия труда, оружие, кожа. Позднее телеуты стали жить в конических юртах монгольского типа, а потом принялись строить избы.

Основу традиционной женской одежды составляли шаровары и туникообразное платье кунек. Свадебный наряд шился из красной материи, обшивался с изнанки синими лентами, поскольку красный цвет символизировал новую жизнь и способность к деторождению, а синий олицетворял небо, небесный мир. На голову надевали коническую шапочку с кисточкой. Для торжественных случаев надевали шапку под названием киш порук. Одежда украшалась нагрудниками, которые декорировались монетами, вышивкой, бисером, широко применялись накосники, украшенные раковинами каури. Все это роднит традиционный костюм телеутов с одеждой тюркских народов нашего края.

Представляет интерес традиционная прическа данного этноса. Мужчины сбривали все волосы, оставляя лишь прядь на темени, которую заплетали в косу. Девушки носили три косы, а иногда даже больше – главное, чтобы число таких кос было нечетным. Замужние женщины носили две косы.

Основу традиционной кухни составляли мясные блюда из конины, баранины, дичи. К национальным блюдам относится тутмаш: тесто, сваренное в насыщенном бараньем бульоне вместе с овощами. Делали кровяные колбасы, готовили сыр, сметану и другие молочные кушанья. Со временем традиционным блюдом становятся пельмени, которые телеуты делают в форме полумесяца.

В прошлом телеуты являлись язычниками: в их пантеоне присутствует множество божеств, главным считался Бай Ульген, большая роль в обрядах отводилась шаманам. Моления совершались в специальных местах, считавшихся священными, в том числе на вершинах гор. После утверждения христианства некоторые старинные обряды соединились с православными. Так, с Троицей совпал весенний праздник Сомо, когда каждая семья приносила к своей изгороди березку.

В фольклоре значительное место занимают эпические произведения, исполняемые сказителями – кайчы, аккомпанирующими себе на шертме-комысе – струнном музыкальном инструменте.

Таковы некоторые особенности традиционной и современной культуры далекого сибирского народа, этноним которого имеет аналоги и в Урало-Поволжье. В следующих статьях мы расскажем о других этносах Сибири, у которых присутствуют этнокультурные параллели с народами нашего края.



***Экспозиция в Музее археологии и этнографии Республики Башкортостан (г. Уфа)***





# Закуска с помидорами и крем-чиз




Подготовила Гюзэль Абдрафигова

**Ингредиенты:**

- Помидоры ........ 6 шт.
- Творожный сыр... 100 г
- Креветки ..........12 шт.
- Микрозелень

## Рецепт приготовления:

Помидоры порезать пополам, креветки пожарить на оливковом масле с чесноком. Сформировать слоями и украсить микрозеленью.

# Печеночный паштет



**Ингредиенты:**

- Куриная печень ..500 г
- Морковь ..........200 г
- Лук репчатый ......150 г
- Масло сливочное . 100 г
- Соль, перец

## Рецепт приготовления:

***Блюдо может быть приготовлено также из печени индейки, гусиной либо говяжьей.***

На терке натрите морковь.

Мелко порежьте лук.

Разогрейте сковороду со сливочным маслом и обжарьте лук с морковью.

Добавьте кусочки печени и обжарьте со всех сторон до полуготовности.

Добавьте немного кипятка и тушите до готовности печени.

Остудите и взбейте печень с овощами в блендере с куском сливочного масла. Количество масла по вкусу, чем его больше, тем нежнее паштет.

Посолите и поперчите паштет, перемешайте. Готово.

Если вы сразу не съели весь паштет или сделали его заведомо много, то выложите его в стеклянные баночки, залейте сверху растопленным сливочным маслом, накройте крышкой и уберите в холодильник. Масло застынет, и паштет под ним не заветрится.

# Беляши в духовке



**Ингредиенты:**

Тесто:
- Молоко . . . . . . . . . . . . .0,5 л
- Дрожжи сухие . . . . . .10 г
- Соль . . . . . . . . . . . . .0,5 ч. л.
- Сахар . . . . . . . . . . . . .2 ст. л.
- Масло подсол. . . . 50 мл
- Мука . . . . . . . . . . . . . . . . 3 ст.

Начинка
- Говядина . . . . . . . . . .600 г
- Лук репчатый . . . . . 2 шт.
- Соль, перец

## Рецепт приготовления:

В теплое молоко добавляем дрожжи, соль, сахар и потихоньку добавляем муку и масло. Замешиваем тесто. Тесто накрываем полотенцем и ставим в теплое место.

Приступаем к начинке: делаем из филе и лука фарш.

Когда тесто поднимется, выкладываем на стол и начинаем делать наши беляши. Тесто отщипываем и делаем шарики, раскатываем, в середину кладем начинку и защипываем края. Отправляем в духовку на 180 °С на 40 минут.

# Салат «Грибное лукошко»



**Ингредиенты:**

- Картофель. . . . . . . . . 2 шт.
- Морковь. . . . . . . . . . . 2 шт.
- Яйца . . . . . . . . . . . . . . . 4 шт.
- Плавленый сырок 2 шт.
- Куриная грудка копч.. . . . .200 г
- Огурцы мар.. . . . . .3–4 шт.
- Опята . . . . . . . . . . . . .280 г
- Укроп
- Майонез

## Рецепт приготовления:

Грибы отправим на дуршлаг, чтобы стекла лишняя влага. Миску смазываем майонезом и кладем на нее разъемное кольцо. Первым слоем выкладываем натертую на крупной терке отваренную картошку. Разравниваем и смазываем майонезом. Огурцы нарезаем на маленькие кубики. Кладем на картофель. Разравниваем и немного прижимаем.

Сюда на крупной терке натрем отваренные яйца. Разравняем и смажем майонезом.

Мясо нарежем на кубики. Разравниваем и делаем сеточку из майонеза. Сюда на мелкой терке натираем отваренную морковь. Сверху добавим немного майонеза. На морковь на крупной терке натрем плавленый сыр: чтобы он лучше натирался, следует перед этим отправить его в холодильник. Сделаем сеточку с майонез и отправим в холодильник на 1 час для пропитки. Украсим укропом и грибами.

*Гөлназ Таипова әзерләде*

## Әйтегезче, кайсы вакыт яздагыдан ямьлерәк?

# КОЯШ НУРЛАРЫН СИБӘ

Әминә Бикчәнтәева

### МАРТ АЕНДА

*Кар дип, җиргә басасың,*
*Суга кереп батасың.*
*Чыксын инде умырзая,*
*Кар астында ятмасын.*
*Мартлар җитсә, яз җитә,*
*Бураннары булса да,*
*Песи дә чыккан урамга*
*Тәпиләре туңса да.*





Шәйхи Маннур

### КОЯШ, ЧЫК, ЧЫК, ЧЫК

*Яз көннәре килгәндә,*
*Тау өстендә, чирәмдә*
*Утырабыз җыйнаулап,*
*Бишәү түгел, унаулап.*

*Кояш кача болытка,*
*Без калабыз суыкта.*
*Ә безгә җылы кирәк*
*Су керергә тизрәк.*

*Әй, сорыйбыз кояштан,*
*Барыбыз бертавыштан:*
*– Кояш, чык, чык, чык!*
*Синең җылың бик тансык.*

*Чыксаң, без сөенербез,*
*Майлы ботка бирербез.*
*Майлы ботка – казанда,*
*Тәти кашык – базарда.*

*Тәти кашык саф алтын,*
*Кирәкми безгә салкын!*

Бари Рәхмәт

### ЯЗ КИЛӘ

*Яз килә! Яз килә!*
*Сыерчыклар килә .*
*Гөрләшеп, сайрашып,*
*Җырчы кошлар килә.*

*Бик күңелле тышта:*
*Кар эри, боз китә.*
*Чабышып йөриләр*
*Малайлар бер читтә.*

*Эх, суга керсәң, ә!*
*Чупырдап йөрсәң, ә!*
*Ярамый, орышалар*
*Әниләр, күрсәләр.*

*Чыпчыклар түбәдә*
*«Чыр-чыр-чыр» киләләр,*
*Ә сайрый белмиләр*
*Бернинди көйгә дә.*

*Бер тавык: «Кыт-кыт, – ди –*
*Без язга чыктык, – ди, –*
*Йомырка салдым мин,*
*Син дә сал, чыпчык», – ди.*

# СӨЙЛИМ ӘЛЕ БЕР ӘКИЯТ

Фәнис Яруллин

## ИКЕ ТАМЧЫ

*Зур бер агачның яфрагы өстендә ике тамчы сөйләшеп утыра:*

*– Кояш чыгып кыздыра башласа, безгә бик кыен булачак! — ди беренче тамчы.*

*– Икәү бергә кушылыйк та, җиргә сикереп төшик! — ди икенчесе.— Җирдә берни дә юкка чыкмый.*

*Шуннан алар икәү, кулга-кул тотынышып, яфрактан ботакка, ботактан җиргә сикереп төшкәннәр. Алар шундый кызу төшкәннәр, хәтта җирне тишеп, бик еракка җиткәннәр. Шуннан алар җир астындагы су патшалыгына килеп чыкканнар. Монда бөтен дөнья тыныч икән: кошлар да сайрамый, урман да шауламый. Тамчыларга күңелсез булып киткән.*



*– Юк, – дигән беренче тамчы, – мондагы тормыш миңа ошамый. Минем җир өстеннән челтер-челтер агасым, дулкыннарга кушылып чабасым килә.*

*– Ә моннан, җир астыннан ничек чыкмак кирәк? – дигән икенче тамчы.*

*– Бергәләшеп тырышсак, җиңәрбез, җир өстенә чыгарбыз, – дигән беренче тамчы.*

*Шуннан алар тагын кулга-кул тотышканнар, үзләре кебек кыю тамчыларны ияртканнәр дә, ташлар арасыннан кысыла-кысыла алга киткәннәр.*

*Шул рәвешле, алар, караңгы җир астында юл ярып, көннәр, атналар, айлар буе барганнар. Ниһаять, бер калын тауны тишеп, җир өстенә килеп чыкканнар. Аннары сөенә-сөенә алга чапканнар. Бара торгач, зур елгага килеп кушылганнар. Тамчыларның көчләре арткан. Алар теләкләренә ирешкәннәр: елгада турбиналарны әйләндергәннәр, йортларны яктыртканнар. Аннары тагын алга киткәннәр – зур диңгезгә барып кушылганнар.*

*Тырыш тамчылар күп нәрсә күргәннәр, күп дуслар тапканнар, күп эшләр эшләгәннәр, кешеләргә күп ярдәм иткәннәр.*

## МӘКАЛЬ ҺӘМ ӘЙТЕМНӘР

*Кар күп булса, иген уңар.*

*Бакча ясамый, алма булмый.*

*Күз өчен яз яхшы,*
*Авыз өчен көз яхшы.*

*Язгы көн ел туйдыра.*



## ТАБЫШМАКЛАР

*Борынсыз чыпчык боз тишә.*

(Тамчы)

*Лампа түгел – яктырта,*
*Мич түгел – җылыта.*

(Кояш)

*Исе юк, төсе юк,*
*Аннан башка тормыш юк.*

(Су)

*Агач башында йорты,*
*Эчендә яши җырчы.*

(Сыерчык)

*Чуар, йомшак күлмәге,*
*Тотсаң, уңа бизәге.*
*Тоттырмый. Китә очып,*
*Йә кала җирдә посып.*

(Күбәләк)



# ЗАЯЦ В ТРАДИЦИОННОЙ КУЛЬТУРЕ

***Наступивший год, согласно восточным гороскопам, является годом Зайца. В связи с этим есть смысл остановиться на некоторых представлениях о данном животном в традиционной культуре разных народов, в том числе Урало-Поволжья.***

*Михаил Кржижевский*

Заяц – зверь неприхотливый: он обитает и в тайге, и в лиственных лесах, и в степях, и даже в знойных засушливых пустынях. Издавна живет он по соседству с человеком, и у разных народов сложились свои представления о зайцах в традиционной культуре.

Известный этнограф Д. Фрэзер писал о том, что в обрядах различных этносов хлебный дух воплощался в облике того или иного животного, в том числе зайца. В некоторых областях Европы зайцем называют последний сноп. Есть поверье, что в последнем клочке не-



сжатого хлеба сидит заяц, которого должен прогнать жнец, завершивший свою работу позже других.

В сказках и легендах разных народов заяц далеко не всегда «трусишка серенький» (или беленький – в зависимости от времени года), часто он проявляет ум, хитрость, смекалку, находчивость. Таков этот зверь в корейской сказке «Хитроумный заяц» – благодаря своей находчивости он обманул тигра и был объявлен самым старшим среди зверей.

В сказках заяц умеет ценить добро. Свидетельством тому является, например, башкирская сказка «Щедрый заяц», в которой мальчик пожалел ослабевшего зайчонка-сироту, выходил его в своем доме, а затем, когда зайчишка подрос, отпустил на волю. Пришло время, и заяц отплатил добром за добро: узнав, что к семье мальчика приехали гости, а их нечем угостить, он попросил своих лесных друзей помочь, и те принесли много вкусной еды: медведи приволокли бортевые ульи, олени на своих рогах доставили ведра с молоком, волки притащили баранину, лисы – кур и гусей, а другие зайцы принесли корзины с ягодами и орехами. Всё это звери оставили во дворе и ушли своей дорогой в лес, а гости разинули рты от изумления и долго так просидели...

В другой башкирской сказке заяц обманул льва, от которого не было житья зверям: он сказал, что в колодце живет другой, нахальный лев. Решив проучить «конкурента», настоящий лев принял за него свое отражение и прыгнул в колодец… Он просидел там целый месяц, а когда все же выбрался, то стал добрым и больше не обижал зверей.

Одним из старинных родов, входивших в состав башкирского племени тамьян, является куян, т.е. заяц, что, вероятно, свидетельствует о древних тотемистических представлениях. Есть у башкир и личные имена с основой куян – например, Куяныш, от которого получило свое название озеро Куяныш в Кунашакском районе Челябинской области. Другое имя – Куянбай, давшее название деревне Куянбаево в Аргаяшском районе той же Челябинской области. Следует упомянуть Куяново болото в Каслинском районе данной области, село Куянтаево в Баймакском районе Республики Башкортостан и т. д.

В татарской сказке у бедняка сгорел дом, а богатые соседи отказались помочь. Тогда он велел жене сшить ему костюм зайца и объявил богачам, что этот костюм дает возможность руководить зайцами, заставляет исполнять их разные поручения. Поверили жадные богатеи, купили простую одежду за золото. По сюжету этой сказки был создан мультипликационный фильм.

Читайте сказки и дети, и взрослые – ведь они являются важным компонентом традиционной культуры.



# ООО «АКТАШ» предлагает услуги по правовой защите граждан и организаций



## ОКАЗЫВАЕМЫЕ УСЛУГИ:

- Юридическая помощь физическим лицам
- Юридическое абонентское обслуживание компаний
- Представительство в арбитражных судах и судах общей юрисдикции
- Услуги в области взыскания задолженности



За дополнительной информацией обращаться по телефону

**8 (927) 797-82-80**

либо по адресу: г. Самара, проспект Кирова, д. 206.










ГОД ОСНОВАНИЯ 1974
Кулинария
НА РЕВОЛЮЦИОННОЙ

- Праздничные торты и пирожные по индивидуальным заказам
- Готовые изделия из мяса, рыбы, птицы
- Салаты и гарниры
- Охлажденные и замороженные полуфабрикаты
- Большой ассортимент свежей выпечки
- Принимаем заказы на пироги
- Доставка горячих обедов в офис
- Обслуживание банкетов и фуршетов

г. Самара, ул. Революционная, 142
Тел.: 260-10-60, 260-15-60









